Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

09

сентябрь 2020

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Ут эчендә татар кызлары...

72 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

09
(321)
сентябрь 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы житәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Ләйлә Лерон
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Гариф Ахунов

ТАРИХИ МИРАС

4 Тукайның дусты – Мәхмүт Галәү. *Л.Тябина*
10 Югары Курса авылының рухи тормышы. *Э.Сәлахова, Л.Гобәйдуллин*
18 Югары Курсада – «Илдус» мәчете
22 Апаз керәшеннәренең исламга кайтуы. *Г.Закиров*
28 Казанда татар китабын басучы матбагалар. *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
34 Ибраһим Идриснең кабер ташы. *А.Гайнетдинов*

ТАТАР ГАМЕ

36 Илшат Нуриев: «Арчада һәр кеше бай һәм матур яшәргә тиеш!»

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан, «Казан арты» тарих-этнография музееннан, Ахуновлар гаиләсе архивыннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ДИНИ МИРАС

42 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
47 «Балаларыма, җәмәгатемә тимәгез!» *Ш.Максудова*

ӘДӘБИ МИРАС

48 Фин илендә Кәрәкәшле кызы. *Х.Миңнегулов*
54 Фатих малае. *Г.Ахунов*
60 Тукай һәм шагыйрь Сирин. *Ә.Шәрипов*

ФИКЕР ДӘРЬЯСЫ

67 Театр һәм тамашачы. *Р.Садриев*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

69 Мәгъсум Хуҗин вафаты. *Л.Лерон*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

72 Ут эчендә татар кызлары... *Т.Биктимирова*
79 Без бит Арча яклары. *Г.Ахунов*
84 Мөхәммәт Мәһдиев турында истәлекләрем. *Ш.Максудова*

54

87 «Хат язар идем сезгә...» *К.Гыйльметдинова*
91 «Җырланып бетмәгән җырым». *И.Вәлиуллина*
96 Казанда Гали Акышны хөрмәтләү. *Ф.Галимуллин*
100 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

102 Борынгы татар милли музыка уен кораллары. *Р.Гыйләҗев*
108 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*
110 Мөхәммәт Мәһдиев музее. *Л.Лерон*

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Сентябрь*

72

91

Заказ №А-2254. Тираж – 2400 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 31.08.2020. Чыгу көне: 04.09.2020.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: Арча районының Кысна авылындагы Сәмигуллиннар гаиләсе. Шәмсенур апа (сулда) килене Гөлбаһар һәм оныклары Гөлҗәүһәр, Гөлзада, Гөлсара, Нургали (Гөлбаһар алдында) белән. 1955 ел. Фото «Казан арты» тарих-этнография музее фондыннан алынды.

Яшьлек — кеше гомеренең иң матур, иң кадерле чагы, һәркем яшьлеген яшьлеге узгач кына сагына. Әйтергә теләгәнем — яшьлекне һәркемгә дә матур итеп сагынырга язсын иде. Моның өчен адәм баласына тик бер генә нәрсә кирәк — гомер юлдашыңны дөрес сайлый белу.

Гариф Ахунов

Гариф Ахунов хатыны Шәһидә белән

Гариф Ахунов

(18.09.1925-4.06.2000)

***

Үз халкыңның улы булуны аңлау тойгысы ул – үз халкыңның нәрсәгә сәләтле икәнен башка халыкларга мөмкин хәтле тулырак итеп китереп җиткерү дигән сүз.

***

Иң элек без бер нәрсәне онытмыйк: сәнгать иҗатчыдан чама хисе, такт һәм югары зәвыклылык таләп итә.

***

Дөньяда ике могҗиза бар: берсе – чишмә, икенчесе – әлифба.

***

Ярлы янудан курыкмый.

***

Халык җырсыз яши алмый. Җыр безгә үз-үзебезне аңларга, дөньяны яңабаштан ачарга ярдәм итә.

***

Әйе, моң – катлаулы төшенчә. Моң ул – безнеңчә, тембрның төсмере, бизәкләре, җанга ятышлы аһәңнәр, уйчанлык, тылсымлы романтика, кичергән газап-кайгылар, ирешелгән шатлыклар сөземтәсе, күңел зурлыгы, җыйнап кына әйткәндә, моң – халыкның рухи дөньясы.

***

Безнең гасыр давыллы хисләр уята. Сәнгать теленә аларны ничек күчерергә? Үз халкың гына аңларлык итеп түгел, чик баганаларының теге ягында яшәүчеләр, башка континентлар да аңларлык булуга ничек ирешергә? Моңа ирешкән җырчы – бәхетле җырчы.

***

Сәнгать теле ул – барлык илләр, барлык континентлар өчен дә аңлаешлы уртак тел.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Тукайның дусты – Мәхмүт Галәү

Лена Тябина

Киләсе 2021 елда Габдулла Тукайның гына түгел, аның дуслары, фикердәшләре, замандашлары, исемнәре халыкка бик тә билгеле ике шәхес – Фатих Әмирхан белән Мәхмүт Галәүнең дә 135 еллык юбилейлары. Алар өчесе дә 1886 елда дөньяга аваз салган: Ф.Әмирхан – гыйнварда, Г.Тукай – апрельдә, М.Галәү – ноябрьдә. Габдулла Тукай әдәби музее хезмәткәрләре шагыйрьнең замандашларына багышланган әдәби кичәләр, очрашулар һәм интерактив чараларны даими оештыра. Шундый очрашуларның берсе тамашачылар күңелендә аеруча истә калгандыр дип уйлыйм. Бу – 2016 елның 11 ноябрендә танылган татар язучысы, журналист, публицист, тәрҗемәче, реалистик татар тарихи романына нигез салучы Мәхмүт Галәүгә багышлап уздырылган «Тукай дусты – Мәрҗән» дип аталган кичә. Әлеге әдәби кичәдә катнашу өчен, әдипнең Хабаровск шәһәрендә яшәүче оныгы Олег Надыйр улы Галәветдинов һәм Мәскәүдәге оныкчыгы Анастасия Олег кызы Галәветдинова Казанга махсус кайтты.

М.Галәүнең төрмә архивында сакланган соңгы фотосы. Мәскәү. 1937 ел

Тукай һәм Мәрҗәни

Мәхмүт Галәү Габдулла Тукайның замандашы һәм фикердәше генә түгел, якташы да. Мәгълүм ки, ул туып-үскән Ташкичү авылы шагыйрьнең балачагы узган Кырлайдан берничә чакрым ераклыкта гына урнашкан.

Шагыйрьнең тормышы белән тирәнтенрәк кызыксынучылар Мәхмүт Галәү истәлекләре белән, һичшиксез, таныш. Алар беренче тапкыр «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы май санында дөнья күргән, соңрак «Тукай турында замандашлары», «Тукай турында хатирәләр» һәм «Тукай турында истәлекләр» исемле әдәби-фәнни җыентыкларда кабат-кабат басылган. М.Галәү Казанда «Болгар» номерларында Тукай яшәгән 40 нчы бүлмәгә кереп йөри. Г.Тукай аны, Мәрҗаниләр нәселеннән булуына ишарә итеп, «Мәрҗән» дип атый, шагыйрьлегеннән иптәшләрчә көлеп, аны үз итеп тәнкыйтьли. Мәхмүт Галәүнең революциягә кадәрге китаплары һәм «Шура» журналындагы тәүге шигырьләре дә «Мәрҗәни» яки «Мәхмүт Мәрҗәни» имзасы белән басылган. Тукай турында истәлекләренең беренче җөмләләреннән үк Мәхмүт Галәүнең әдәби талантын, язу стиленең үзенчәлеген тоясың: *«Казанда Харитонов типографиясендә эшләгән чагым. Көндез, эштән туктап, ике сәгать ял итәбез. Аш ашар өчен «Болгар»га йөрим»*. Дәвам итеп укысагыз, шагыйрьнең үзен күз алдына китерерсез: *«Син ашап утырган чакта ишекнең югаргы пыяла өлеше аркылы кыска чәчле баш түбәсе, җыерчыклы маңгай һәм елтыраган күзләр күреп каласың. Бик яхшы беләсең: бу – Тукай»*. М.Галәүнең алты-җиде битлек әлеге истәлекләре гади хатирәләр генә түгел. Анда әдип иҗатын туплау мәсьәләсе дә кузгатыла. *«Моңарчы әле Тукай турындагы бик күп истәлекләр, материаллар мәйданга чыгарылмый ята. Хәтта шагыйрьнең хатлары, кульязмалары да төрле кулларда таркау килеш йөриләр. Үзем дә Тукай турында күптәннән инде тулы, зур истәлек язарга җыенып йөрсәм дә, моңар чаклы шул эшне эшли алганым юк. Менә хәзер шагыйрь Габдулла Тукайның тууына илле ел тулу уңае белән югарыдагы кечкенә истәлек кисәген яздым. Бу алдагы зур эшләрнең башлангычы булсын»*, – дип яза ул.

> **«**
> **«Син ашап утырган чакта ишекнең югаргы пыяла өлеше аркылы кыска чәчле баш түбәсе, җыерчыклы маңгай һәм елтыраган күзләр күреп каласың. Бик яхшы беләсең: бу – Тукай».**

М.Галәүнең тәрҗемәи хәле: яңа сәхифәләр

Язучының тормышы да, әдәби мирасының язмышы да гаять катлаулы, фаҗигале. Ул – революциягә кадәр үк билгеле журналист һәм язучы, 1907 елда Оренбургта үзенең хосусый «Белек» нәшриятын оештыра. Хезмәт юлын 1903 елда Әстерхан шәһәрендәге башлангыч мәктәп укытучысы буларак башлап җибәрә. 16 яшеннән әдәби иҗат белән шөгыльләнә, цензура япканчы, «Туп» журналын чыгаруда катнаша. Педагогик һәм әдәби талантын берләштереп, мәктәп балалары өчен хрестоматияләр төзи. Алар – ике кисәктән торган «Төрки уку», (Оренбург, 1911) һәм «Мәктәп балаларына махсус шигырьләр» (Оренбург, 1912). Бу җыен-

тыкларда Г.Тукайның мәсәлләре һәм шигырьләре урын алган. 1915-1918 нче елларда М.Галәү рәсемле «Кармак» журналы чыгара. Оренбургта Кәримов-Хөсәеновлар нәшриятында хәреф җыючы, корректор, машиналарны җайлаучы, җаваплы чыгаручы булып эшли. А.Пушкинның «Буран», Л.Толстойның «Хуҗа Морат», «Крейцер сонатасы» әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Ике шигырь җыентыгы бастыра, «Через три часа по чайной ложке» (*М.Галәү биографиясе рус телендә язылган, бу әсәрнең татарча исемен таба алмадык. –* ***Л.Т.***) дигән комедия яза. Революциядән соң Уфа һәм Оренбургта халык мәгарифе өлкәсендә һәм төрле нәшриятларда эшли. Шул елларда аның ике драма әсәре – «Пугачев явы» трагедиясе һәм «Салам-торханнар» пьесасы дөнья күрә, спектакльләре Мәскәү татар театры сәхнәсендә куела.

М.Галәү 1925 елда, СССР халыкларының Үзәк нәшрияты чакыруы буенча, Мәскәүгә күчеп килә, 1925-1926 нчы елларда шул нәшрияттә консультант булып эшли. Аңа, наширлек эшен яхшы белүче буларак, китап басу буенча милли кадрлар хәзерләячәк «Үзәк полиграфия хезмәткәрләре мәктәбе»н оештыру бурычын йөклиләр. М.Галәү – 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 1930-1937 нче елларда «Мосфильм» киностудиясендә татар һәм башкорт теленә кинолибреттолар тәрҗемәчесе булып эшли, бер үк вакытта СССР Әдәби фондында да хезмәт итә. СССР халыкларының Үзәк нәшриятында һәм Татар китап нәшриятында чыккан күп санлы дәреслекләрнең мөхәррире һәм корректоры була. Мәскәүдәге Критик-библиографик институт белән хезмәттәшлек итә.


РСФСР

СВИДЕТЕЛЬСТВО О СМЕРТИ

II-А № 954293

Гр. Галлутдинов (фамилия, имя, отчество) Махмуд Галлутдинович

умер (ла) 12/XI 1938 года двенадцатого ноября тысяча девятьсот тридцать восьмого года (прописью и цифрами год, месяц и число)

возраст 52 года

Причина смерти —

о чём в книге записей актов гражданского состояния о смерти 1957 года апреля месяца 11 числа произведена соответствующая запись за № 25

Место смерти: город, селение (Москва)

район — область, край,

республика —

Место регистрации: Отдел ЗАГС Кировского р-на (наименование и местонахождение бюро ЗАГС)

Дата выдачи „13“ апреля 1957 г.

м. п. Заведующий бюро записей актов гражданского состояния

Гознак. 1946.

Шәхес культы елларында ул репрессиягә дучар була һәм төрмәдә атыла. Әдипнең исеме 1957 елда гына аклана. М.Галәү әсәрләренең язмышы да фаҗигале. Кызганыч ки, «Канлы тамгалар» дилогиясенә кергән «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнарының кульязмалары һәм татарча текстлары сакланмаган. «Болганчык еллар»ны – Гайшә Шәрипова, «Мөһаҗирләр»не ул үзе рус теленә тәрҗемә итә, 1931 һәм 1934 нче елларда алар китап булып басылалар. Безнең көннәрдә укучылар әлеге әсәрләрне татар телендә Яхъя Халитов һәм Рәис Даутов тәрҗемәсендә укый.

Анастасия Галәветдинова тапшырган мирас

Максатыбыз М.Галәү биографиясен укучыга җиткерү генә түгел, ә аның бик кызыклы, әле тар даирәдә генә билгеле булган архивы турында бераз мәгълүмат бирү дә. ТР Милли музее фондына әдипнең Мәскәүдә яшәүче оныкчыгы Анастасия Галәветдинова гаилә архивында сакланган берничә фотография һәм документлар тапшырды. Фотосурәтләргә Анастасия һәм Олег Галәветдиновлар аңлатма да бирделәр.

М.Галәү хатыны Зәйнәп белән.
1920-1930 нчы еллар

***

Беренче фотода – Мәхмүт Галәү сөекле хатыны Зәйнәп Хәсәнова белән. Әдипнең өченче хатыны Зәйнәп Гәрәй (?) кызы (Гиреевна) Хәсәнова кем булган соң? Ул 1901 елда Оренбург шәһәрендә эшче гаиләседә туган. 1925 елның 17 февралендә Оренбург шәһәрендә М.Галәүгә кияүгә чыга. Гаилә архивында аларның язылышуы турындагы таныклыкның 1957 елда бирелгән копиясе, З.Хәсәнованың автобиографиясе саклана. Тиздән аларның гаиләсе Мәскәүгә күчә. Бу вакытта Зәйнәп М.Галәүнең беренче ярдәмчесе була. Язучы үзенең фикерләрен аңа, стенография буенча белгеч буларак, әйтеп яздыра, соңыннан бу язмаларны үзе эшкәртә.

1937 елның 22 сентябрендә М.Галәү кулга алынгач, 28 ноябрьдә Зәйнәпне дә кулга алып, халык дошманы хатыны буларак, 8 елга хөкем итәләр, хезмәт-төзәтү лагерена җибәрәләр. Ул халык дошманнарының туганнары һәм хатыннары өчен тәгаенләнгән лагерьларның берсенә – АЛЖИРга («Акмолинский лагерь жен изменников Родины») эләгә. 7 елдан, ягъни 1944 елда УДО буенча азат ителә, ләкин иреккә чыкканнан соң да, янә 2 ел шул лагерьда ирекле яллы эшче, ягъни «вольнонаемная» буларак эшли. Гаилә архивында З.Хәсәнованың бу турыда документлары да саклана.

Мәхмүт белән Зәйнәпнең 1928 елда туган кызы Ләләне, әнисе кулга алынгач, Иркутск шәһәрендәге балалар йортына озаталар. Галәветдиновларның гаилә архивында балалар йортында тәрбияче булып эшләгән Клавдия Телегинаның Зәйнәпкә хаты һәм Ләләнең өлгереш табеленең (1938 ел) фрагментлары саклана. Тәрбияче үз хатында Ләләнең бик пөхтә, сакчыл булуы, яхшы укуы, шуның өчен бүләкләнүе турында язган. Ул аның балалар йортында яшәгәндә бер генә тапкыр – ике генә көн авыруын, сәламәтлеге яхшы булуын хәбәр итә. Әлеге хаттан бер юл китерәм: *«И вообще, у Вас растет хорошая девочка»*.

1956 ел… Тукайның һәм Мәхмүт Галәүнең юбилей еллары. Исән булсалар, икесенә дә 70 яшь тулган булыр иде. Яңа елны үзенчәлекле хаттан башлап җибәрә Зәйнәп

Хәсәнова: 1956 елның 3 гыйнварында СССРның Генераль прокуроры исеменә ире Мәхмүт Галәүнең эшен яңадан карау турында хат яза. Әле КПССның XX съездында (ул 25 февральдә уза) Н.Хрущев «шәхес культы» турында доклад укыганчы ике ай алдан яза ул бу үтенеч-шикаятьне! Шулай итеп, Зәйнәп ханым М.Галәүне реабилитацияләү буенча эшне башлап җибәрә, документлар җыя, төрле оешмаларга һәм инстанцияләргә хатлар, гаризалар яза, гаилә архивын туплый. 1956 елның 20 июлендә М.Галәүнең реабилитациясе буенча эш ачыла, соңрак ул СССР Язучылар союзында торгызыла, аның әдәби мирасы буенча комиссия төзелә. Ләкин Зәйнәпнең 1957 елның 29 августында СССР Министрлар Кабинетына «тов. Бельченко»га җибәрелгән үтенече җавапсыз кала: М.Галәүне кулга алганда НКВД хезмәткәрләре тарафыннан алып кителгән әдәби архив кире кайтарылмый... Бу вакытта Зәйнәп Казан шәһәрендә – Щапов урамындагы 31 нче йортның 18 нче фатирында яши.

Зәйнәпнең үлеменнән (1969 елның 4 феврале) соң бу документлар кызы Ләләдә саклана. М.Галәүнең икенче хатыны Фатыймадан туган улы Надыйр, аның хатыны Валентина Ивановна һәм оныгы Олег Ләлә белән хат алышып торалар. Ләлә 1983 елда вафат була, Электросталь шәһәрендә җирләнә. Аның тормыш иптәше Иван да 1989 елда бакый дөньяга күчә. Иванның Беларусьта яшәгән туганы Анна, 1990-1991 нче елларда бер тартма материалларны Олег Галәветдиновлар гаиләсенә тапшыра. Чынлап та, могҗиза бит бу архивның сакланып калуы! Г.Тукай әдәби музее тамашачылары, очрашу вакытында әлеге бәһасез архивтагы төп нөсхә документлар белән танышып, күчермәләрен алып, фотога да төшерде.

***

Икенче фотода Мәхмүт Галәү, Зәйнәп Хәсәнова һәм яшүсмер кыз. Ул Мәхмүт Галәүнең беренче хатыны Хәдичәдән туган кызы Диләрә – Деляра. Фотоларның төшерелү вакытын якынча гына билгеләп була: 1920-1930 нчы еллар. Мәхмүт

М.Галәү хатыны Зәйнәп һәм кызы Диләрә белән. 1920-1930 нчы еллар

Анастасия Олег кызы Галәветдинова карт бабасының туган авылы Ташкичүдәге мәктәп музеена да документлар бүләк итте. Фотода ул Ташкичү мәктәбе директорының урынбасары Мәсхүт Зариф улы Гарифҗанов белән. 2016 ел

Галәүнең киеме ике фотода да бер үк, ләкин Зәйнәпнең киеменә һәм бизәнү әйберләренә карап, фотосурәт төрле вакытта төшерелгән дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Мәхмүт Галәү төрмәдә үз кулы белән язган анкетасында Диләрә, Надыйр һәм Ләлә исемле балалары барлыгын әйтә. Беренче баласы Диләрә турында мәгълүмат аз. Надыйр Зәйнәпкә язган хатында Диләрә турында сораша. Шул ук хаттан Диләрә белән Зәйнәпнең элемтәдә торуы билгеле: Зәйнәпнең адресын Надыйрга Диләрә җибәрә. Галәветдиновларда Диләрә турында башка мәгълүмат юк.

***

Мәхмүт Галәүнең соңгы фотосурәте Мәскәүдә кулга алынгач ясалган һәм «Шәхси эш»ендә сакланган. 2009 елда язучының Хабаровск шәһәрендә яшәүче оныгы Олег Надыйр улы Галәветдиновка ФСБның Хабаровск өлкәсе буенча идарәсе бинасында М.Галәүнең архивта сакланган җинаять эше белән танышырга рөхсәт бирәләр. Шәхси эштәге фото безгә язучының соңгы мизгелләрен дистә еллар узгач җиткерде. Олег Надыйр улы Галәветдиновның тормыш иптәше – рус теле һәм әдәбияты укытучысы, милләте буенча якут Мария Александровнаның шул вакыйгадан соң иҗат иткән нәсереннән берничә юл китерәм: *«...мы были поражены тем, что увидели. Он, конечно, узнаваем, и в то же время другой! Глаза! В них боль... 71 год прошел с момента съемки, но их грустная энергетика поражает в самое сердце...»*

Анастасия Олег кызы һәм Олег Надыйр улы Галәветдиновлар Г.Тукай әдәби музеена, фотолардан тыш, Мәхмүт Галәүнең исеме аклану – реабилитациясе белән бәйле документларны да тапшырдылар. Алар арасында Мәхмүт Галәүнең ақлануы турындагы белешмәнең 1957 елның 16 апрелендә Мәскәү Дәүләт нотариаль конторасында расланган күчермәсе дә бар. СССР Югары Суды Хәрби Коллегиясе, Мәхмүт Галәветдинов эшен 1957 елның 9 мартында янәдән карап, яңа шартларны исәпкә алып, җинаять составы булмау сәбәпле, үлгәннән соң акларга дигән карар кабул итә. Белешмә 1957 елның 14 мартында бирелгән.

Әгәр зур һәм батыр йөрәкле Зәйнәп Хәсәнова үз вакытында Мәхмүт Галәү белән тормышын бәйләмәсә, аның архивын булдырмаса, төрле гаиләләрдә үскән балаларын таныштырып тормаса, язучы хакындагы күп документлар һәм аның фотолары безгә килеп җитә алыр идеме икән?!. ■

Югары Курса авылының рухи тормышы

Эльмира Сәлахова, Ленар Гобәйдуллин

Югары Курса мәчетенең проектлары. ТР МА. 2 нче ф., 14 нче тасв., 147-148 нче эшләр

Курса исемле авыллар хәзерге Арча районында дүртәү: Югары Курса, Урта Курса, Түбән Курса һәм Курса-Почмак. Түбән Курса белән Югары Курса икесе ике авыл булса да, халык арасында озак вакытлар бер авыл кебек кабул ителгән. 1794 елгы җир бүлү документларында да аларның җир кишәрлекләре бердәм итеп бирелә. Югары, Түбән һәм Урта Курса авылларының зиратлары борынгыдан ук уртак. Бу да күрше авылларның тарихи бердәмлегенең билгесе.

Мәчет – авылның рухы

Югары Курсада заманы өчен халык шактый күп яшәсә дә (1859 елда – 923 кеше, 1908 елда – 1360*), инкыйлабка кадәрге чорда анда бер генә мәхәллә булган. Мәхәлләнең кайчан оешу вакыты билгеле түгел. Гадәттә, авылга нигез салыну белән мәхәллә тормышы да җайланган. Е.И.Чернышевның «Селение Казанского ханства» исемле мәкаләсендә ул Казан ханлыгы чоры авылы буларак билгеле. Шунлыктан мәхәлләнең, мәчет-мәдрәсәнең башлангычы да, авыл тарихы

* Чагыштыру өчен: 2015 елгы мәгълүмат буенча, нибары 184 кеше яши.

шикелле, ханлык чорыннан ук килә. Бу елларда мәчетләр, авыл халкының матди мөмкинлекләреннән чыгып, агачтан гади итеп эшләнгән була.

Курса авылының безгә мәгълүм булган таш мәчете – тарих һәм архитектура ядкяре соңгы классицизм стилендә корыла. Ул 1835 елда 2 нче гильдия сәүдәгәр, тире заводы хуҗадашы, Урта Азиядә һәм Русия ярминкәләрендә чимал сәүдәсе белән шөгыльләнгән **Габделкәрим Муса улы Апанаев** (1813-1873) һәм аның туганы, шулай ук 2 нче гильдия сәүдәгәр **Гобәйдулла Муса улы Апанаевлар** (?-1870) химаясенә бина кылына. Мәчет төзү өчен алынган документлар мәхәлләдә сакланган була, әмма, вакытлар узу белән, алар югалган. Бу турыда метрика язмаларында телгә алына.

Ике катлы бинаның өске өлеше гыйбадәт кылу өчен көйләнгән, ә аскы каты хуҗалык әйберләрен саклау максатыннан кулланылган. Мәчет төрле елларда үзенең беренче кыяфәтен үзгәрткән. 1863 елның азагында, мәхәллә халкының артуын исәпкә алып, бинаның төньягы өч тәрәзә аралыкка зурайтыла. Бу чыгымнарны да игелекле эшкуар Габделкәрим Апанаев күтәрә. 1880 елда мәчеткә ремонт ясала, түбәсе алыштырыла һәм манарасы төзекләндерелә.

Курсавиның тугры дәвамчылары

Авылның безгә мәгълүм булган беренче имамы – **Рәфыйк бине Таиб әл-Курсави**. Ул XVIII гасырның беренче яртысында яшәгән атаклы имам **Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети (Мортаза хаҗи)** шәкерте була. Рәфыйк хәзрәт мәдрәсәсендә **Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле, Вәлид бине Сәгыйд әс-Сәгыйди** кебек дин әһелләре белем алган. Галим кыска төннәрдә болгар халкына ястү намазы уку кирәклеге хакында китап та яза. Ястү намазының шарты туры килмәсә дә, ягъни җәйге озын көннәрдә шәфәкъ нуры таралмаса да, аны уку фарызлыгы хакында XIX гасырның икенче яртысында «Нәзурәтел хак»та **Шиһабетдин Мәрҗани** язачак фикерләр Казан арты авылларында бер гасыр алдан әйтелә.

Курса авылы **Габденнасыйр Курсави** (1776-1812) имамлык иткәндә танылды. Ул атаклы Мәчкәрә мәдрәсәсендә, аннан Бохарада белем ала. Мәгълүм ки, **Габденнасыйр Курсави** – татар җәмгыятенә яңа фикер белән килгән шәхес. Замандашлары да, аннан соң яшәгән галим-голәмә дә аны кабул итеп бетермәгән. Казан галимнәре дә Габденнасыйр Курсави чакырылган мәҗлесләрдә катнашмаган. Хәтта Шиһабетдин Мәрҗанинең атасы Баһаветдин хәзрәт тә аны яратмаган. *«Атабыз мәрхүм әмир Хәйдәрнең мелла Габденнасыйрны үтерми калдыруына үкенүен сөйли иде»,* – дип яза тарихчы аның турында. *«Ул кечкенәдән үк фикер йөртүгә сәләт күрсәтә, каләме белән саф гөлбакча барлыкка китерә, үзен затлылык белән каплый һәм Ватанының –* ***Казан өлкәсендәге Курсаның данын күтәрә.*** *Гыйлеменең нурлы кояшы иң югары нок-тага җиткәч, ул, Ватаны Курсада шәкертләр тәрбияләп, китаплар язды. Кыскасы, мелла Габденнасыйр бу мәмләкәттә булган галим-голәмәдән һәм үз гасырындагы башка кешеләрдән галимрәк, алдан күрүчәнрәк, турылыклырак булган»,* – дип тә бәя бирә. Каюм Насыйри аның турында: *«Аның өчен фәнни чыганаклар бар нәрсәдән өстен иде... Гомумән, ул дөреслекне сөюче галим иде»,* – дигән. Габденнасыйр Курсави гарәп телендә язылган уннан артык хезмәт калдыра. Ул, кырыс холыклы, үткен телле булуы аркасында, үзен галим дип санап йөргән кешеләрнең хәтерен калдырган, аларның дошманына әйләнгән. Кимчелекләрне төзәтү юлын Г.Курсави Коръән һәм сөннәткә кайтуда, шуңа нигезләнеп һәр укымышлы кешенең мөстәкыйль фикер

йөртергә хокуклылыгында һәм тәкълидкә, ягъни борынгы галимнәр фикеренә каршы көрәштә күрә.

Габденнасыйр Курсави, Бохарадан туган авылына кайткач, Мәчкәрәдәге җизнәсе **Габдулла бине Габдессәлам Үтәгәнев** һәм апасы **Мәрхәбә бинте Ибраһим**ның уллары **Гобәйдулла, Муса** һәм **Мөхәммәтҗан**нарның матди ярдәме белән зур мәдрәсә нигезләп, күп шәкертләр җыеп, гыйлем өйрәтүгә керешкән. Димәк, Курса мәдрәсәсе салынган вакыт якынча XVIII гасыр азагында, Әби патша – Екатерина IIнең татарларга мәчетләр төзү рөхсәте биргән, азрак дин ирекен кайтарган еллардан соң булган дип уйларга мөмкин.

Сабаның өченче мәхәллә мәчете имамы, шагыйрь, дини китаплар авторы, 1812 елда иҗат ителгән «Адәм угълы» назирәсе авторы **Җамалетдин бине Шәмсетдин бине Хисаметдин әс-Сабави** (1780-1866), хәзерге Башкортстандагы Эстәрлебаш мәдрәсәсе мөдәррисе, мулла **Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрле**, Каһирә университетында фарсы теле мөгаллиме, шагыйрь **Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла әл-Наласави** (1933 елда вафат) да Курсави шәкертләреннән була. Атаклы шагыйрь **Һибәтулла Салихов**ның остазы, хәзерге Оренбург өлкәсенең Түбән Чебенле авылы мулласы, ишан **Дәүләтша бине Гаделша** да Курсада укый.

Габденнасыйр Курсави 1808 елда кабат Бохарага киткәч, аның урынында олы абыйсы – **Габделхаликъ бине Ибраһим әл-Курсави** (?-1843) кала. Урта Азиядә сәүдә кәсебе белән шөгыльләнгән бу хәзрәт зур мал-мөлкәт тупларга өлгерә, дини белемне дә яхшы үзләштерә. Бохара шәһәрендәге мәдрәсәдә суфилар борадәрлеге Нәкышбәндиянең күренекле вәкиле Ниязколый әт-Төрекмәнидә белем ала. 1812 елда энеләре Габденнасыйр һәм Габделкәримнәр белән хаҗ сәфәренә кузгала. Шунда Габденнасыйр әл-Курсави Төркиянең Өскедар каласында вабадан вафат була. Габделхаликъ Истанбул, Каһирә шәһәрләрендә яши. Мисырда Диарбәкер* мөфтие, **мелла Әбү әс-Согуд**тан Коръәнне яттан өйрәнә. Ватанына кайткач,



Югары Курса авылының 1910 елгы метрика дәфтәреннән бер бит. Метриканы тутыручы мулла – Мөхәммәдгариф Уразгильдиев. ТР ДА. 204 ф., 177 тасв., 1103 эш.

* Диарбәкер – хәзерге Төркиянең Сүрия, Гыйрак, Иран чикләренә якын бер җире.

имам-хатыйп указын алып, шәригать гыйлеменә өйрәтүче остаз буларак көн күрә. Ш.Мәрҗани бу кеше турында: *«Изге ниятле, диндар, шәригать юлына тугрылыклы һәм башкаларны да тугры юлга өндәүче буларак шөһрәт казана»,* – дип язган. Габделхаликъ хәзрәт хәдисләрне туплап китап яза. Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр Курсада яши, шул авыл зиратында җирләнә. Габделхаликъ мулланың Габденнасыйрдан кала башка энеләре **Габделкәрим бине Ибраһим** һәм **Габдерәшит бине Ибраһим**нар да заманының укымышлы кешеләреннән булып, берсе – Каһирәдә, икенчесе Бохарада бакый дөньяга күчә.


№ 138 8
МЕТРИЧЕСКАЯ КНИГА
Казанской губерніи
Казанскаго уѣзда
Верхние Курсы
Къ мечети.
на 1910 годъ.
ИЗЪ ОРЕНБУРГСКАГО
Мухамеданскаго Духовнаго Собранія.
УФА
Электро-Типографія „Восточная Печать"
1909.

Бу елларда Курса авылында хәзерге буын укучылары яратып укый торган «Ногмани» тәфсиренең авторы **Ногман бине Әмир бине Госман** да яши. Тумышы белән Эстәрлетамак өязенең Сәмән авылыннан булган әлеге хәзрәт Габденнасыйр Курсавида белем ала. Остазының кардәше Габделхаликъ хәзрәтнең кияве дә була ул. 1812 елда Габденнасыйр Курсави хаҗ сәфәренә киткәч, Ногман хәзрәт Курсада аның урынына калып, шәкертләр тәрбияли, шул ук вакытта Коръән тәфсирен дә яза башлый.

Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» исемле хезмәтендә **Фәхреддин бине Бикмөхәммәд бине Рәхмәтулла бине Мәскәү**нең 1830 ел ахырында Бохарадан кайткач Курсада имам булып торуы, соңрак Мамадыш өязенең Шайтан Елга авылына (хәзер Саба районының Урта Саба авылы) китеп, шунда мулла хезмәтенә керешүе турында мәгълүмат бар. Тумышы белән Казансу буендагы Әйшә авылыннан булган бу хәзрәт турында Ш.Мәрҗани: *«Галим вә фазыйль, язуга оста, хисап вә үлчәү гыйлемнәрен яхшы белә иде. Гүзәл холыклы, тыйнак, тәкәллефсез бер зат иде»,* – дип язып калдырган.

Габделхаликъ әл-Курсавиның вафатыннан соң, Курса мәхәлләсен аның шәкерте, шул ук вакытта кияве дә булган **Хәсән бине Хәмид әл-Курсави** (якынча 1810-1872 нче еллар) җитәкли. Хәсән мулла чыгышы белән атаклы Чистай сәүдәгәрләре Уразгилдиевләр нәселеннән. Мәчкәрәдә – **мелла Габдулла бине Яхъя**дан, Кече Сонда – **мелла Фәхреддин бине Садыйк**тан, Чистай шәһәрендә мелла **Исхак бине Сәгыйд**тән белем алган. Остазы Габделхаликъ әл-Курсавиның ышанычын яулап, аның Газизә исемле кызына өйләнгән. Имам итеп тәгаенләнгәч, ул Курсада хөрмәтле остазга әйләнә. 1913 елгы документта Курса мәдрәсәсе вафат булган мулла Уразгилдиев заманында төзелгән, инде шактый иске бинада урнашкан дип күрсәтелә. Димәк, XIX гасыр уртасында әлеге уку йорты өчен яңа бина салынган булса кирәк. Ш.Мәрҗани Хәсән әл-Курсави турында: *«Шәригать таләпләренә тугрылыклы, әдәп саклаучы кеше иде. Яшенә карата киенә белеп яшәде, сөннәт*

«

Ш.Мәрҗани Хәсән әл-Курсави турында: «Шәригать таләпләренә тугрылыклы, әдәп саклаучы кеше иде. Яшенә карата киенә белеп яшәде, сөннәт һәм шәригать мәсьәләләре белән кызыксына иде. Аз сүзле, күбрәк дәшми торуны кулай күрүче, гайбәттән һәм кешене җәберләүдән тыелучы, бәхәсләрне килештерергә тырышучы иде...» – дип язган.

һәм шәригать мәсьәләләре белән кызыксына иде. Аз сүзле, күбрәк дәшми торуны кулай күрүче, гайбәттән һәм кешене җәберләүдән тыелучы, бәхәсләрне килештерергә тырышучы иде. Дөньясы киң иде. Кигән туны бәрәннән, тышкы һәм башка киемнәре милли, киемнәренең озынлыгы балтырдан иде, җиңенең озынлыгы баш бармактан озын булмады. Юлда йөргәндә дә, шәһәрдә булганда да, кыска догалар укый иде. Башкарган эшләре яхшылыкта булды», – дип язылган. Р.Фәхреддин Хәсән әл-Курсавиның үз шәехе Габделхаликъ бине әл-Курсави янына җирләнгәнлеге турында әйтә.

Хәсән ишанның вафатыннан соң, 1872 елда Курса авылының имам-хатыйбы һәм мөдәррисе итеп аның шәкерте **Гатаулла бине Мөхәммәд** (1819-1894) билгеләнә. Ул Лаеш өязенең (хәзерге Балык Бистәсе районы) Кече Әшнәк авылында дөньяга килә. Казандагы Апанай, хәзерге Арча районындагы Кышкар (**Ягъкуб бине Яхъя әл-Кышкарый**да), Мөндеш (математик һәм астроном, **мелла Фәйзулла бине Мортаза бине Мөхәммәдкол әл-Мөндеши** (1780-1850)) мәдрәсәләрендә укый. 1849 елдан – Казан өязенең Олы Кавал, 1859 елдан Мамадыш өязенең Норма авылында мулла булып тора. **Гатаулла бине Мөхәммәд** чоры Курса мәдрәсәсенең иң нәтиҗәле эшләгән еллары була. Аның шәкерте булу зур мәртәбә санала. Гатаулла хәзрәт мәдрәсәсендә ел саен җитмештән артык шәкерт белем алган. Остазының шәехе Габделхаликъ әл-Курсави туплаган хәдисләр җыентыгын «Китаб әр-Рикак» («Сафлык турында китап») исеме белән Казанда бастырып та чыгара. Озак еллар бу китап мәдрәсәләр өчен уку әсбабы булып тора. Картлык көнендә ул үзенең улы, имам-мөдәррис Габделхак хәзрәт янына, Курсадан ерак булмаган Казиле авылына күченә һәм шунда 75 яшеннән үтеп бакый дөньяга күчә.

Гатаулла хәзрәттән соң, 1895 елда Курсага мулла итеп Хәсән бине Хәмиднең улы – **Мөхәммәдшакир Уразгилдиев** (1861-1908) билгеләнә. Ул Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсендә һәм Бохарада укып кайта. Әмма Мөхәммәтшакир хәзрәт Курсада озак эшләми, 1897 елның февралендә, бай сәүдәгәрләр чакыруы буенча, Казанга күчә һәм Печән базары мәчете мәхәлләсендә имамлык хезмәтенә керешә. Хасталыгы сәбәпле, туган авылы Курсага кайтып, 1908 елның 22 февралендә вафат була. Аның турында Р.Фәхреддин: *«Мәдрәсә тоту, укыту белән шөгыльләнмәсә дә, гыйлеме бар, әхлагы гүзәл, мөлаем бер зат иде. Уфа шәһәрендә торган вакытыбызда өебезгә күп мәртәбәләр килеп, озак вакыт утырыр иде, бер дә гайбәт сөйләгәнен яки бер кемсәдән шикаять иткәнен ишетмәдем»*, – дип язып калдырган.

Курса зиратында мулла **Габделбәдигъ Габделгазиз улы**ның (1866-1901) кабер ташы бар. Ташына язылган мәгълүматка караганда, ул «Мичән вә Түбән Курсада 36 сәнә имамәт вә тәгълиме дин әйләде». Архив документында Габделбәдигъ хәзрәтнең хәзерге Мамадыш районындагы Югары Бөрсет авылында туганлыгы

әйтелә. Ул Саба районының Яңа Мичән авылында икенче мулла вазыйфасын башкара, ә 1892 елның 22 сентябреннән башлап гомеренең азагына кадәр Курса авылы имамы булып тора.

Ир балалар өчен җәдид мәктәбе

Авыл мәгарифен яңа ысулга куючы **Мөхәммәдгариф Хәсән улы Уразгилдиев** була. 1870 елның 25 июлендә Югары Курсада дөньяга килгән бу хәзрәт башлангыч белемне үз авылындагы атаклы мәдрәсәдә – Гатаулла хәзрәт Мөхәммәдевтә ала. 5-6 ел дәвамында Мисырда да белем эсти. Аннан туган ягына кайтып, 1891 елдан Курсада эшли, агасы Мөхәммәтшакир Казанга киткәч, төп имам итеп билгеләнә. Биредә аның белән бер үк вакытта мәзин булып Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте – 1870 елда туган **Габдрахман Мөхәммәдҗан улы** да хезмәт иткән.

1898 елда Курса мәдрәсәсендә 4 сыйныф ибтидаи *(башлангыч)*, 4 сыйныф рөшди *(урта)* вә 2 сыйныф игъдади *(югары белем алуга хәзерләү сыйныфлары)* – барлыгы 10 сыйныф эшли.

XX гасыр башында авылда 25 яшькә чаклы ир-егетләрнең барысы да укый-яза белгән. Шәкертләр өчен махсус кыйраәтханә (китапханә) ясалган. Андагы әдәби һәм фәнни китаплар шәкертләргә фикерләрен ачарга, заман яңалыклары белән танышырга ярдәм иткән. Мәдрәсәгә күрше-тирә авыллардан килеп укучы шәкертләрнең дә саны арта. Урын җитмәү сәбәп булса кирәк, югары белем алуга хәзерли торган игъдади ике сыйныф бетерелә. Уку йортын ремонтлау, киңәйтү мәсьәләсе актуальләшә. Казан сәүдәгәре **Габделвәли Йосыф улы Чукин** үзе вафатыннан соң Курса мәдрәсәсен төзәтү чыгымнарына 200 сум акчасын васыять итеп калдыра, алга таба башка химаячеләр дә акчалата ярдәм күрсәтеп тора. Ирләр мәктәбенә 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, Ш.Мәрҗанинең шәкерте **Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсафа улы Галикәев** (1847-1919) тә ел саен акчалата ярдәм иткән.

Укулар, гадәттә, көзге эшләр кими башлагач, 1 октябрьдән башланган. Курса имамы Гариф Уразгилдиев, мәдрәсәгә шәкертләр җыюы хакында газетага белдерү биргәндә, тору урыны безнең өйдә, дип язган. Игътибар итегез: авыл мулласы, балаларга белем бирү белән бергә, аларның көнкүреш, яшәү шартларын булдыруны да үз өстенә алган.

Курса мәдрәсәсендә Коръән һәм хәдис гыйлеме укытылган. Ислам тарихы күренекле журналист **Фатих Кәрими**нең (1870-1937) 1913 елда «Кәримевләр һәм Хөсәеневләр» басмаханәсендә чыккан «Мөхтәсәре тарихы исламия» китабы буенча алып барылган. Шәкертләр **Солтан Рахманколый**ның (1888-1916) 1912 елда язган «Мөнтазыйм кыйраәт» китабыннан хикәяләр укыганнар, **Ягъкуб Хәлили**нең (1877-1938) 1913 елда дөньяга таралган «Гыйлем халь» дигән китабы нигезендә ислам дине таләпләренә туры килгән сату-алу һәм башка шәргый кагыйдәләрне өйрәнгәннәр. Мәдрәсәдә 1911 елда «Милләт» басмаханәсендә басылып чыккан «Гарәп-фарсы-татар теле сүзлеге»ннән дә файдаланганнар, арифметика да укытылган.

Курса авылы, гадәти белем бирү үзәге генә булып калмыйча, 20 нче йөз башында гади халыкка яңа белем җиткерү үзәгенә дә әйләнә. 1916 елның 5 гыйнварында татар агрономы Госман Данбулатов, мәдрәсә бинасына игенчеләрне җыеп, иген игү турында лекция укый. Халык аның чыгышын бик яратып тыңлый.

Кызлар мәктәбе

Курсада кызлар мәктәбе дә Гариф хәзрәт Уразгилдиев тырышлыгы белән 1908 елда ачыла. Хәзрәтнең үз йортында эшләп килгән бу мәктәптә Хәсән хәзрәтнең остазбикәсе Фатыйма абыстай укыта. Ул 1913 елның 7 октябрендә дөнья куя. «Кояш» газетасының 1913 елгы 12 ноябрь санында әлеге мәктәп турында Мөхәммәтфатих Яхинның кечкенә мәкаләсе басылган. Анда: *«Әүвәлге ике елда бер микъдара мөгаллимә китертеп укытылган иде. Соң елларда хәзрәтнең мөхтәрәмә рәфика (хатыны) вә мәхдүмәсе (кызы), ханымнар вә шуннан укып чыккан ике кыз мөгаллимәлек кылалар. Хәзрәтнең әүвәлге йорты мәктәп өчен тар булганлыктан, яңадан зур итеп тәгъмир кыйлдырылды (төзелде). Соңра, шәкертләр күбәеп, ул да тарлык кыйлгач, борадәре (туганы) Закир мәхдүмнең йортын иҗарәгә (арендага) алып, берничә сыйныфны шунда урнаштырылды. Бу көннән, Курсаның үзеннән башка, Мамадыш вә Казан өязләренең күп авылларынннан кызлар, хәтта хатыннар килеп, һәр ел йөз чамасында шәкерт, 4 сыйныф ибтидаи вә 4 сыйныф рөшди – җәмгысе 8 сыйныф булып укыйлар. Горефтә (элек) укыла торган дәресләрдән башка кул һөнәрләре дә өйрәтеләдер. Шуннан укып чыккан кызларның хәзер дә үз авылларында мөгаллимлек кыйлганнары бардыр»*, – дип әйтелгән.

Матди чыгымнарының күп өлешен мулла үз өстенә алган. Моның өчен ул ел саен 1000 сум акча тоткан, шуның өстенә, урыс теле мөгаллимәсенә дә, үз кесәсеннән акча түләп, дәресләр бирдерткән. Әлбәттә, кайбер татар байлары да, мөмкинлекләренә күрә хәер-садакаларын биреп, мулланың бу эшенә терәк була. Мисал өчен, ирләр мәдрәсәсенә даими ярдәм итеп торган Казан бае Мөхәммәтсадыйк Галикәев 1916 елда мәктәптә укучы һәр кызга (ә анда 50 кыз бала) берәр күлмәклек ситса иганә итә, моннан тыш, ел саен 100-150 сум акчалата да ярдәм кулы суза. Шулай да кызлар мәктәбе матди кыенлык кичергән, анда уку да түләүле булган. Бу турыда М.Яхинның алда искә алынган мәкаләсендә: *«Укучылардан алуы да читен, чөнки халкымыз һаман да гыйлем юлында акча тотуның фарыз икәнен аңлап җитә алмый. Укытуны акчасыз булганда гына тиеш дип белә. Әүвәлге елларда алынып килгән 2-3 сумны бу ел 5 сум иттереп ала башлагач, күп кешеләр, хәтта имамнардан күбесе, кызларын китермәс булганнар. Бу исә киләчәктә бер гаиләдән тәрбия кыйлачак яки, ихтимал, киләчәктә бер мәхәлләдә булган йөзләрчә кызларны тәгълим кыйлачак (укытачак) кызларымызның надан калуы, димәктер. Әгәр һиммәт ияләре бу мәктәпкә иганә кыйлсалар, иганәләре бик урынлы булыр һәм дә мәктәпне ислах кыйла (камилләштерә) төшәргә мөмкин булыр иде»*, – дип язылган.

Мәчет бинасы – совет чорында да мәгариф үзәге

Мәчет бинасының совет чорындагы язмышы ничек булган соң? Алда язылачак мәгълүматны без Арча шәһәрендәге «Казан арты» тарих-этнография музееннан алдык.

Авыл кешеләренең сөйләвенә караганда, 1930 нчы елларда Курса мәчетенең манарасын кисеп төшерү зур фаҗига була, бу көнне халык ярсып елаган. Манараны кисүчеләр үзләре дә якты дөньядан фаҗигале үлем белән киткән, дип сөйлиләр. Шул елларда мәчетнең астын тирәнәйтеп, элекке хуҗалык кирәк-яраклары өчен яраклаштырылган урыннан беренче катны булдыралар, анда 3 бүлмә, коридор, икенче катта да 3 бүлмә һәм коридор ясыйлар. Тора-бара михраб урынын, мәчет

Тарихи мәчетнең хәзерге күренеше. Янында өр-яңа «Илдус» мәчете төзелеп килә. 2016 ел

түшәмендәге әвәләп ясалган затлы үсенте-чәчәк орнаментларын, заллар интерьеры элементларының полихром буяуларын юк итәләр. Әлеге бинада җидееллык мәктәп оештыралар. Бу бай тарихлы уку йорты тарихына тукталып тормыйбыз. Биредә мәктәп 1984-1985 нче елларга кадәр, Урта Курса авылына күчкәнче эшли. Анда, алты авылдан килеп, 200-300 бала белем ала. Бер класста икешәр сменада 30ар бала укыган, диләр. 1985 елдан соң ике бүлмәдә тегү фабрикасы урнаша. Совет чорында өстәп төзелгән янкорма мәчетнең әүвәлге күренешен тәмам боза. Хәзер анда медпункт эшли.

1990 нчы елларда әлеге бинаның төньяк өлешендә совет чорында төзелгән агач янкормасы өстенә манара куела. Шуны да искәртик: янкорма астында борынгы манара нигезе хәзерге көнгә кадәр сакланып калган. Яңа мәчет төзелгәнче, җомга һәм гает намазлары биредә укылган, кечкенә генә класс бүлмәсенә 80-85 кеше сыйган.

Тарихи урын бу... Бүген авыл һәм район халкының бар теләге – әлеге тарих һәм архитектура һәйкәлен төзекләндерү. Яңа төзекләндерелгән бинада «Курсавилар һәм авыл мәгарифе» музее, мәдрәсә оештырырга, башлангыч мәктәп һәм китапханәне, хәтта тарихи әһәмияте булмаган янкорманы сүтеп, медпунктны да шунда күчерергә мөмкинлек булыр иде.

Музей өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. 1964 елда Югары Курса авылында мәшһүр шагыйрь Госман Бакировлар нәселеннән булган мәктәп директоры Гыйният Бакиров музей оештыра, бай экспонатлар туплый. Хәзерге көндә бу музейда ике меңнән артык экспонат исәпләнә. Анда авыл тарихының бай һәм затлы мирасы тупланган. Гарәби язулы китаплар, эш кораллары, милли киемнәр, нумизматика материаллары – аеруча кызыклы экспонатлардан. Заманында әлеге музей аерым бинада, Шакир бай йортында була. Байның йорты 2000 нче елларда сүтелә, әмма аның складлары хәзерге көндә дә бар. Гыйният ага Бакиров оештырган Төбәкне өйрәнү музее 1985 елда Урта Курса авылы мәктәбенә күчә. Аңлашыла ки, бу бай мирас киләчәктә «Курсавилар һәм авыл мәгарифе» музеен оештырырга, Курсавилар мирасы белән кызыксынучыларны Югары Курса авылына җәлеп итәргә нигез булырга мөмкин. ■

Югары Курсада – «Илдус» мәчете

*25 июль көнне Арча районының Югары Курса авылында яңа мәчет ачылды. Аны төзү эшендә иганәче **Илһам Хисамиев** зур көч куйган. 2014 елда нигез салынып, затлы итеп эшләнгән, «Илдус» исеме бирелгән гыйбадәтханәдә ирләр һәм хатын-кызлар өчен махсус заллар, уңайлыклары булган тәһарәтханә, уку сыйныфлары бар. Игътибарыгызга мәчет ачылышы тантанасында катнашучыларның чыгышын тәкъдим итәбез.*

Равил хәзрәт Зөфәров, ТР Диния нәзарәте рәисенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча киңәшчесе:

– Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Аллаһы Тәгалә ошбу йортны сәгадәт әйләсен иде. Бу тормышыбызның нуры, гыйлем учагы, Раббыбыз Аллаһка сөекле-якын гыйбадәт урыны булса иде. Аллаһы Тәгалә күп нигъмәтләрен насыйп итә. Кардәшләребез әлеге мәчетне төзү эшенә киң күңел, олы йөрәк белән алынганнар һәм ошбу хезмәтне башкарып чыкканнар. Нинди гүзәл-ямьле, нинди матур Аллаһ йорты төзелде, җәмәгать! Инде шушы гүзәл йортта бергәләп сафларда булып, Аллаһыны искә алып, хәер-дога белән, илебез, якыннарыбыз өчен яшәсәк иде.

Иганәче
Илһам Хисамиев

Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан Республикасының баш казые:

– Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Бүген Курса халкы өчен эш башлана гына. Бу мәчет сездән бик зур җаваплылык таләп итә. Монда биш вакыт азан әйтелеп, намаз укылырга тиеш. Хәтерлисездер, элек Татарстанда 17 генә мәчет бар иде. Казанда – берәү. Шулвакыт Кукмарадан ерак түгел Саз-Тамак исемле авылдан аягы зәгыйфь Ибраһим абзый култык таягы белән һәр җомга станциягә килер иде дә, поездга утырып, Казандагы «Мәрҗани» мәчетенә барып, намазын укып, шундагы хәзрәтләрнең вәгазен магнитофонга яздырып алып кайтыр иде. Хәзер һәр авылда мәчет янәшә. Югары Курса авылы районда иң күп мал асрый торган авыл дип беләм. Кайчакта кешеләрне җомгага чакырам: «Дүрт үгеземне карыйсым бар, хәзрәт, килеп булмый», – диләр. Мин әйтәм: «Абыстай белән сиңа дүрт үгез нәрсәгә соң?» Ул: «Малайның безне карамаска дип алган ипотекасы бар, шуны түлим», – ди. Абзар юлын мәчет юлына алыштырсак, Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән, малайлар да янда калыр. Мәчет безнең өскә зур җаваплылык өсти. Эш арасында намаз укырга түгел, ә намаз арасында эш эшләргә кирәк! Мәчет бар, Аллаһы Тәгалә тарафыннан анда йөрергә мөмкинлек бирелгән икән, шушы нигъмәтнең кадерен белик. Аллаһы Тәгалә: «Минем биргән нигъмәтемә шөкер итсәгез, арттырып бирермен», – дигән. Шушы мәчет динебезгә, күңелләребезне пакьләүгә хезмәт итсен иде.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры:

– Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Курса җирендә фикер, гыйлем ияләре дөньяга килеп, халкыбызны дөньяга таныткан. Хәзер Арчада да мәчетләрне гаять гүзәл итеп сала башладылар. Әлбәттә, ул зәвык белән кешеләрне тарта торган итеп эшләнгән икән, аның эчтәлеге дә булырга, анда йөрүче кешенең иманы артырга тиеш. Бу – беренче чиратта, авыл халкының бурычы. Икенчедән, төзүчеләрнеке. «Мәчетне төзедем дә, халыкка тапшырдым һәм эш бетте», – дип уйларга ярамый. Бүген генә Урта Курса авылында мәчетне төзеткән Вәдүт хаҗи белән күрешкәндә, ул Аллаһ йортын чистартып, шунда тәртип салып йөри иде. Мәчетне төзегән кеше беркайчан да үз хезмәтенә битараф булмый, аның киләчәген дә тәэмин итә.

Марат Хафизов һәм Ленар Гобәйдуллин фотолары

Әмир хәзрәт Миңнемуллин, Арча районы мөхтәсибе:

– Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Мәчетләр ул – рухият, ә хәзрәтләребез – шушы рухиятне тапшыручы кешеләрдер. Бүген районыбызда 86 нчы мәчет ачыла. Бер кыйссаны искә төшереп үтәсем килә. Бервакыт Сабын кайнату фабрикасының хуҗасы килә дә Зәйнулла хәзрәткә әйтә: «Хәзер мәчетләр күп, әмма кешеләрнең хәле үзгәрми», – ди. Шулвакыт мулла: «Менә урамда бер бала пычракта уйнап утыра, ни өчен ул чиста түгел? Син бит Сабын кайнату фабрикасының хуҗасы!» – дип җавап бирә. Тегесе: «Ул безгә килсә, чиста булыр иде», – ди. Зәйнулла хәзрәт исә: «Син үз соравыңа җавапны үзең таптың», – дип әйтә. Бу – авылга бәрәкәт, сәгадәт алып килүче мәчетләр. Мәчетләргә йөрик, әлеге рухиятне үз эчебезгә кертсәк иде. Мәчетне төзүчеләрдән Аллаһы Тәгалә разый булсын! ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Апаз керәшеннәренең исламга кайтуы

Габделфәрт Закиров

1917 елда төзелгән Апаз мәчетенең рәсеме

Арча районында үзенең рухи дөньясы белән башкалардан аерылып торган авыл бар. Минем туган авылым Апаз ул. Татарстан Республикасы Милли архивында сакланган документлар нигезендә авылымның тарихына бәйле кайбер кызыклы мәгълүматларны «Безнең мирас» журналы укучылары белән дә уртаклашасым килә.

Апазның «иске керәшен»нәре

1700 нче еллардан башлап Апазово-Рождественское авылында иске керәшен татарлары яшәгән. Барысы да православие динен тоткан, татар телендә сөйләшкән һәм үзләрен керәшен дип йөрткән. Электән үк: «Динебез – урыс дине, ә телебез – татар теле», – дип әйтә торган булганнар алар. Үзләренең гореф-гадәтләре, милли

йолалары, кием-салымнары, җырлары, көйләре, бәйрәмнәре белән ислам динендә булган татарлардан аерылып торганнар. Бабаларымның кайчан чукындырылганлыгы һәм Апаз авылына кайдан килеп урнашканнары билгесез. Фәкать «иске керәшен» дигәннән генә аларның Казан ханлыгы рус дәүләте тарафыннан җимерелгәннән соң, ягъни XVI гасырның урталарында чукындырылганлыклары аңлашыла. Ә инде язма чыганакларда авыл беренче мәртәбә 1678 елда телгә алына.

Кеше аз булган авылларда чиркәү төземәгәннәр. Хисап документларына күз салсак, Апаз авылында чиркәү 1720 елда дәүләт акчасына төзелгән. Димәк, бу елга чаклы авылда халык саны чиркәү тотарлык булмаган. 1782, 1795, 1834, 1858 нче елларда уздырылган халык санын алу исемлекләрендә барлык кешеләр дә «старокрещенные татары» дип теркәлгәннәр. Халык саны елдан-ел арта барган. 1782 елда – 190 ир-ат; 1795 елны 88 хуҗалыкта – 215 ир-ат һәм 218 хатын-кыз; 1834 елны 94 хуҗалыкта – 299 ир-ат һәм 298 хатын-кыз; 1858 елны 94 хуҗалыкта 393 ир-ат һәм 418 хатын-кыз яшәгән.

Якын-тирәдәге башка авылларда чиркәү булмау сәбәпле, күрше авыллардагы православие дине кешеләре дә Апаз авылына килгән. Авыл кешеләре әби-бабаларыннан калган гореф-гадәтләрне, йолаларны төгәл үтәп яшәгән. Хәтта өйләнешкәндә кызларны якын-тирәдәге керәшен авылларыннан – Югары һәм Түбән Әзәк, Чепья, Субаш һәм Сәрдәбаштан алып кайтканнар.

Апаз үзенең базары, чиркәве, мәктәбе белән якын-тирәдәге авыллардан гына түгел, башка өлкәләрдән, шәһәрләрдән дә бай сәүдәгәрләрне, укытучыларны җәлеп иткән. Шулай итеп, апазлылар күп милләт кешеләре белән аралашып яшәгәннәр. Әле мин бала вакытта да авылда базар эшләп торды. Бирегә мари, удмурт һәм рус авылларыннан килгән кешеләрнең күбесе татар телендә бик яхшы аралаша иде.

Башка авылдан килгән яшьләр өйләнешкәндә, Апаз авылы кешеләре чиркәүдә шаһит булып та катнашкан. Чиркәүдә күп кенә күрше авыллардан, шәһәрләрдән килгән кешеләрнең дә яңа туган балаларын чукындырганнар, өйләнешкәннәрне, үлгәннәрне исәпкә алып, метрика кенәгәләренә теркәп барганнар. Апазның керәшен зиратында авыл кешеләрен генә түгел, башка авыллардан алып килгән мәетләрне дә чиркәүдә алар рухына дога укытып җирләгәннәр. Себергә күчеп баручыларны да, юлда вафат булсалар, Апаз зиратына дәфен кылганнар. 1835-1845 елгы чиркәү метрикаларында Псков, Владимир, Смоленск, Калуга, Пермь һәм башка губерналардан Себер юлына чыккан, әмма төрле сәбәп белән якты дөньяны калдырып киткән кешеләрнең исемнәре теркәлгән.

Татарстан Милли архивында Апаз чиркәвенең 1752, 1774, 1791 нче еллардагы һәм 1792 елдан 1915 елга кадәр булган метрика кенәгәләре саклана. 1752 елгы метрикада авыл кешеләренең милләте күрсәтелмәгән. Ә аннан соңгыларында барлык кешеләр дә «старокрещенные татары» дип теркәлгәннәр.

Ислам диненә кайту

1802-1827 нче елларда Казан губернасының берничә өязендә керәшен татарларының әкренләп ислам диненә күчү процессы башлана. Бу хәрәкәт «яңа керәшеннәр», ягъни XVIII гасырда чукындырылган татарлар арасында актив бара. Чукынганнарына нибары бер гасыр чамасы гына узу сәбәпле, алар ислам дине йолаларын да онытып бетермәгән булалар әле. Изге Синодның 1830 елның 31

маенда чыккан карарында чиркәүләрдәге службаны башка милләт телләрендә дә алып барырга диган тәкъдим, алай гына да түгел, 1846 елны Россия патшасы Николай Інең чиркәүләрдә службаны татар теленә күчерергә диган Указлары да керәшен татарларының ислам диненә күчүен туктата алмый.

Бу хәрәкәт 19 нчы йөзнең икенче яртысында тагын да активлаша. 1864-1865 нче елларда Казан, Лаеш, Мамадыш, Спас һәм Чистай өязләрендә яшәүче керәшен татарлары әкренләп ислам диненә кайта башлый. Ә Зөя һәм Тәтеш өязләрендәге керәшеннәрнең барысы да диярлек ислам динен кабул итә. 1880 нче елларда Апаз авылы белән тыгыз элемтәдә торган Югары һәм Түбән Әзәк авылы кешеләре дә ислам диненә күчеп бетәләр.

Тирә-яктагы мөселман авыллары йогынтысында Апаз халкы да ислам диненә кайтырга омтылып карый. Әмма биредә вазгыять бөтенләй башкача була. Әйткәнемчә, алар «иске керәшеннәр», ягъни 2-3 гасыр эчендә инде шактый буын алмашынып, ислам йолалары онытылган була. Шулай да Апаздагы «иске керәшен» татарлары намазга басмасын өчен дәүләт тарафыннан нинди чаралар күрелгән соң? 1867 елда биредә тирә-якта иң беренче керәшен мәктәбе ачыла, анда укымышлы, ике телне һәм, әлбәттә, православиенең асылын белгән татар егетләре әзерләнә башлый. Аларга татар теленә тәрҗемә ителгән христиан дине китаплары китерелә. Моның өстенә, 1871 елдан башлап авыл чиркәвендә служба атнага ике тапкыр татар телендә алып барыла башлый. Апазның побы Александр Миропольский да татарча бик яхшы белүче, үгет-нәсыйхәт эшендә шактый әзерлекле кеше булган.

Шуңа да карамастан, 1880 елда Апаз авылында ислам диненә кайту башлана. Апаз керәшеннәре: «Без ислам диненә чыгабыз», – дип сөйләшмәгәннәр, ә: «Без татарга чыгабыз», – дип әйтә торган булганнар. Бу елларда Апаз авылында 1026 керәшеннең 26сы ислам диненә күчә. Иң беренче булып «татарга чыгу»чылар менә бу кешеләр булган:

1. Андрей Егоров – Әмир Бикчәнтәев;
2. Ефим Иванов – Яхъя Ибраһимов;
3. Ефим Игнатьев – Кәрим Ибраһимов;
4. Алексей Васильев – Фәйзулла Зәйнуллин;
5. Емельян Тимофеев – Ямалетдин Якубов;
6. Михаил Борисов – Закир Зарифов;
7. Алексей Емельянов – Миндубай Ямалетдинов.

1880-1883 нче елларда ислам диненә бик нык өндәп йөрүче берничә кешене хөкем итеп, 12 елдан 15 елга кадәр вакытка Иркутск өлкәсендәге Усоль авылына сөргенгә җибәрәләр. Алар – Иван Афанасьев, Григорий Осипов (Йосыпов), Яков Васильев (Зәки Зәйнуллин). 1909 елда бу кешеләр Казан губернаторына, яңадан ислам диненә чыгарга рөхсәт сорап, прошение язып җибәрәләр. Аларның гаризалары берсенеке – 1909 елның 17 сентябрендә, икенчесенеке 1910 елның 11 июнендә канәгатьләндерелә.

1881-1882 нче елларда авылда 250дән артык кеше ислам диненә күчә. Ләкин 1883 елда, Апаз чиркәвенең побы А.Миропольскийның тырышлыгы белән, 240 кеше яңадан православие диненә кайтарыла.

1900 елда А.Миропольский Апаздан китә. Поп итеп Василий Никитин исемле керәшен татарын куялар. Әмма ул эчәргә ярата. Нәтиҗәдә, 1907 елда аны эшеннән алалар. Николай IIнең 1905 елның 17 октябрендә игълан иткән дин ирекe турындагы манифестыннан файдаланып булса кирәк, ислам диненә күчәргә теләүчеләр саны бик нык артып китә. Попның эчкечелеге, эшенә салкын каравы һәм тирә-як

1880 елдан Апаз мәктәбендә укытучы булып эшләгән Емельян Филиппов үзенең кызы Мария һәм хатыны Мария Саввовна белән. 1884 ел

авыллардагы мөселманнарның йогынтысы бу процессны аеруча тизләткән. 1905-1906 нчы елларга 96 Апаз кешесе Казан губернаторына прошение яза. Архивта 1907 елны төзелгән исемлек саклана. Бу исемлектә һәрбер кешенең православный һәм мөселман исемнәре, шунда ук нәсел тамгалары теркәлгән. 1910 елга кадәр тагын 86 кеше гариза язып җибәрә.

Бу вакыйгалар ислам диненә күчкән кешеләр белән ислам диненә чыкмаган керәшеннәр арасында каршылыклар тудыра башлый. Хәтта бер гаилә эчендә дә бәхәсләр куера. Мәсәлән, Семен Никитин ислам динен кабул итәргә карар кыла, ә хатыны риза булмый. Шулай итеп, Мария Степанова 1908 елда Казан архиепископына иреннән аерылышырга рөхсәт сорап гариза яза һәм, иреннән аерылып, Сәрдәбаш авылына кайтып китә.

1907 елда Трофим Михайловның кече улы Алексей Трофимов, туганнарыннан рөхсәт сорамыйча, Казан губернаторына гариза язып җибәрә. Гаризасында: «Минем әби-бабайлар, әти-әни күптән инде ислам динен тоталар, христиан динен тотмыйлар, һәрвакыт үзләренең дини йолаларын ислам динендә башкаралар, шуңа күрә миңа рус диненнән чыгарга рөхсәт бирегез», – дип яза. Казан дини академиясе каршындагы миссионерлар курсында укып, 1904 елдан бирле Апаз чиркәвендә эшләүче абыйсы Федор Трофимов бу хәлне белеп гарьләнә һәм шул ук елны Казан губернаторына үзләренең кем икәнлекләрен, нинди дин тотканнарын, әти-әнисенең православие динендә булуларын, әтисенең чиркәү старостасы икәнлеген исбатлап хат яза.

Хатында, энемнең бер сүзе дә дөрес түгел, ди. Соңрак Алексей Трофимов, әти-әнисе, абыйларыннан үгет алганнан соң, үзенең «хатасын аңлый» һәм губернаторга, башта язган хатын ертып ташлавын сорап, кабат үтенеч җибәрә.

Минем бабай Федор Прокофьев 1906 елның 30 гыйнварында Апаз чиркәвендә Анна Федорова дигән кыз белән никахлаша, ә үзе, шул ук елның 8 ноябрендә исламга күчүне сорап, гариза яза. 1911 елгы исемлектә безнең гаиләдә күптән ислам динен тоталар дип язган кешеләрнең 3 яшьтән 8 яшькә кадәр булган балалары гына чукындырылмаган, ягъни чиркәү метрикасына теркәлмәгән.

1880 елларда ук «без татарга чыктык» дип йөргән кешеләр: Андрей Егоров (Әмир Бикчәнтәев), Ефим Иванов (Яхъя Ибраһимов), Ефим Игнатьев (Кәрим Ибраһимов), Алексей Васильев (Фәйзулла Зәйнуллин), Емельян Тимофеев (Ямалетдин Якубов), Михаил Борисов (Закир Зарифов) губернаторга 1906 елда гына гариза язганнар, чөнки аларга православие диненнән чыгарга рәсми рөхсәт булмаган. Ә прошениеләре 1911 елда гына канәгатьләндерелгән.

Шунысы кызык: Апаз авылы керәшеннәренең Казан губернаторына җибәргән гаризалары барысы да бертөрле эчтәлектә, хатасыз язылган, әйтерсең, алар русча бик яхшы белгән. Соңрак бу хатларның Апазда яшәүче Казан мещаны Давид Васильев һәм Пенза мещанкасы Ирина Богдановаларның ярдәме белән язылганлыгы ачыкланды.

1911 елның июль аенда Апаз авылында 1366 кеше яшәгән. Чиркәү хисабы буенча, шул елның 1 июненә чиркәүгә йөрүчеләр 704 ир-ат һәм 662 хатын-кыз саналган. Берничә елдан соң 293 ир-ат һәм 269 хатын-кыз православие динендә калган, 411 ир-ат һәм 393 хатын-кыз ислам диненә күчкән. 162 кеше православие диненнән элек үк чыккан булган.

Апаз керәшеннәренең күпләп ислам диненә күчүенә күршедәге Каратай мулласы Низаметдин Фәхретдинов һәм шул авыл мөселманнары да сәбәпче була. Поплар сүзе белән әйткәндә, алар халыкны «мөселманлыкка кайтырга котырткан». 1905-1910 нчы елларда Казан губернаторына прошение язганнарга мөселманча исемнәрне Каратай авылы мулласы кушкан. Бу исемнәрне алар үзләре сайлап алганмы, әллә мулла абзыйның уена нинди исем килсә, шуны кушканмы – анысы безгә билгесез. Нәтиҗәдә, 1907 һәм 1911 елгы исемлекләрдә генә дә 33 – Миңлебай, 36 – Ибраһим (Ибрай), 51 – Сәрбиҗамал, 29 – Мәчтүрә, 36 Фатыйма исеме бар. Мондый бертөрле исемнәрнең күплеге авылда кушаматлар барлыкка килүгә сәбәпче булган. Ә иң кызыгы – бу кушаматлар хәзерге көнгә кадәр килеп җиткән.

Ислам диненнән чыгып, кире православиегә кайтучылар да булган. Мәсәлән, Григорий Федоров, Андрей Семенов, Михаил Иванов, Александр Егоров шушы

А.С.Миропольский үзенең укучылары белән

елларда яңадан православиегә күчкән. Ислам диненә кайтучылар саны күбәйсә дә, чиркәү метрикаларында 1905 елны – 28 бала, 1914 елда 36 бала теркәлгән, ягъни чукындырылган.

XX гасыр башында Апаз авылы керәшеннәренең ислам диненә чыгуларын туктатырлык һәм тоткарларлык мөмкинлекләр калмый, хәтта дәүләт тә бу эштә ярдәм кулын суза алмый. Мәсәлән, 1907 елның 29 гыйнварында, Кече Лызи побы Емельян Филиппович Филиппов йогынтысында, Апазда «татарга чыгарга теләмәгән» Фрол Степанов губернаторга: «Ислам диненә чыккан татарлар ислам диненә чыкмаган керәшеннәрне кысырыклый башладылар, шуңа күрә, керәшеннәрне саклар өчен, Апаз авылына бер генә булса да полиция уряднигын җибәрүне сорыйм», – дип гариза язган. Әмма бу прошение үтәлмәгән.

Апазда мәчет салу

1917 елның апрель аенда Апаз авылы мөселманнарының бер-бер артлы ике җыены уза. Шунда алар мөстәкыйль мөселман мәхәлләсе оештыру турында карар чыгаралар, мулла итеп Габдерәүф Мөхәммәтсафа улы Хәмзин дигән кешене сайлап куялар. Ул Спас өязендәге Яңа Камка (Мәүләшә) авылыннан була.

Җыенда ике катлы мәчет төзү мәсьәләсе дә карала. 1917 елның 21 апрелендә авыл кешеләре исеменнән староста Фәйзулла Зәйнуллин, Миндубай Нуриев, Әхмәтҗан Әмиров, Гарифулла Насыйбуллин, Мөхәммәтҗан Нуриев, Хәким Ибраһимов, Сәфиулла Мөхәммәтҗанов, Закир Ибатуллин, Кәрим Ибраһимов, Ибраһим Исмәгыйлев, Фәйзрахман Абдуллин, Ибраһим Мортазиннар имзалаган ике беркетмә (беренчесендә – 16 апрельдә 97 кеше, икенчесендә – 21 апрельдә 104 кеше катнашкан) һәм мәчетнең проект-смета документлары Балтач волосте идарәсендә теркәлеп, 22 апрельдә Казан губерна идарәсенә тапшырыла. 14 июньдә бу документлар Казан губернасының төзелеш бүлегендә карала. Анда Казан өязенең милиция начальнигына мәчетнең төзелеш урынын тикшерергә дигән күрсәтмә бирелә. 15 июньдә бу урын тикшерелә һәм, төзелеш уставына туры килмәү (ә чынбарлыкта чиркәүгә якын булу) сәбәпле, проект расланмыйча кала. Әмма 1917 елгы хөррият җилләре һәм дин иреге турындагы канун Апаз халкын бу эштән туктата алмый: мәчетне авылның нәкъ үзәгенә – базар мәйданына салып куялар. Кызганыч, гыйбадәтханә буларак, ул бик аз вакыт кына эшләп кала. Илдә гражданнар сугышы, мәчет, чиркәүләр белән көрәш башлана.

Шулай итеп, чукындырылудан соң 3-4 гасыр чамасы вакыт узгач, Апаз халкы ата-бабалары диненә кайта. Бик күп кешеләрнең ислам диненә чыгуына карамастан, авылда 1950 нче елларга кадәр дә керәшен гаиләләре бар иде. Хәтта XIX гасыр ахырында һәм үткән гасыр башында туган әби-бабайларның исламга күчтем дип санаганнары да керәшен бәйрәмнәрен искә алды, мөселман бәйрәмнәрен дә уздырды. Минем әтинең әнисе Наталья Кузьмина (Хәтимә Гайнуллина) һәм аның әнисе Анна Никифорова, мөселман диненә күчкәннәр дип саналсалар да, үзләрен үлгәч керәшен зиратына күмәргә кушканнар һәм шунда җирләнгәннәр.

Хәзерге көндә Апаз авылында үзенең керәшен әби-бабаларын белгән кешеләр бармак белән генә санарлык. Керәшен зираты да совет чорында көтүлеккә әйләнгән иде. Ун ел элек, Апаз авыл советы рәисе Рәис Закиров тырышлыгы белән аны, тимер баганалар утыртып, тимер челтәр белән уратып алдылар, ә җитәкче булып Ренат Сабитов килгәч, челтәрне профнастилга алмаштырдылар. ■

Татар китабы

Казанда татар китабын басучы матбагалар

(XIX гасыр ахыры-XX гасыр башы)

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев

Казандагы рус типографияләренең һәммәсендә дә татар китаплары басылган. Соңрак татар матбагалары да ачылган.

Перов матбагасы. 1879-1900 нче еллар арасында Иван Семенович Перов типолитографиясендә 36 татар китабы 518500 данә тираж белән дөнья күргән. Ә 1901-1910 нчы елларда анда 31 китап 373080 данәдә басылган.

Вечеслав матбагасы. Казандагы рус матбугаты цензоры Георгий Михайлович Вечеслав 1881 елда типография ачкан. 1882 елда ул, гарәп хәрефләрен дә койдыртып, татар китаплары бастыра башлаган. Бу матбагада 1882-1894 нче елларда 225 исемдәге татар китабы 1,5 миллион тирәсе гомуми тираж белән басылып чыккан. Вечеслав басмаханәсендә дөньяви китаплар, аеруча фольклор әсәрләре, матур әдәбият, тарихи эчтәлектәге әсәрләр нәшер ителгән. Бу типографиядә, И.Н.Харитонов эшли башлагач, китаплар полиграфик яктан югары сыйфатлы итеп (яхшы кәгазьдә, матур шрифтлар белән, бизәк-нәкышләр кулланып) басылган.


القسم الثانى من كتاب مستفاد
الاخبار فى احوال قزان وبلغار
للامام العلامة المحقق الشيخ شهاب الدين المرجانى القزانى رحمه الله
لقد كان فى قصصهم عبرة لاولى الالباب
كل علم ليس فى القرطاس ضاع ۞ كل سر جاوز الاثنين شاع
(اول مرتبه باصلوى)
بو كتاب قزان اونيوبرسيتيتنك طبع خانه سنده باصمه
اولنمشدر تاشكندلك هم قزانى محمد شريف احمدجان اوغلى
باكبروفننك خراجاتى ايلان ١٩٠٠ نچى يلده
КАЗАНЬ
Типо-Литографія Императорскаго Университета.
1900 г.

Шиһабетдин Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». Казан, 1900 ел

Чиркова матбагасы. Мария Арефьевна Чиркова варислары типографиясе үзенең башлангычын 1840 елда ачылган Л.Шевиц матбагасыннан һәм аннары Алабуга сәүдәгәре Н.Коковинныкы буларак танылган басмаханәдән алган. XIX гасырда татар китаплары нәшер итү буенча бу басмаханә университет типографиясеннән генә калышкан. 1870-1880 нче елларда анда татар китаплары гына басылган диярлек. Ә XIX гасыр ахырында, башка типографияләрнең дә ачылуы һәм үзендә матбагачылык эшен камилләштермәү сәбәпле, Чиркова басмаханәсендә татар китапларын нәшер итү кимегән. Шунлыктан 1906 елда бу типографиядә татар китапларын бастыру тукталган.

Әлеге басмаханәдә 1901-1905 нче еллар аралыгында 171 исемдәге татар китабы 2481990 данә тираж белән басылган.

Домбровский матбагасы. Казан шәһәрендәге теш табибы Бронислав Людвигович Домбровский типографиясендә татар китаплары аеруча күп басылган. Ә.Кәримуллин ачыклавынча, Вечеслав типографиясен Домбровский сатып алган. 1894 елда ачылуыннан алып 1910 елга хәтле анда барлыгы 622 татар китабы 4616050 данә тираж белән басылган. Монда дини китаплар һәм кадими мәдрәсәләр өчен дәреслекләр күп чыккан.

Бу матбагада 1894-1900 нче елларда татар китаплары уңышлы гына чыгып килсә дә, 1901-1907 нче елларда басмалар саны чагыштырмача аз булган. Сәбәбе – матбагачылык эшендәге үсеш һәм үзгәрешләрне исәпкә алмыйча, китапларны элеккечә кыйммәт бәягә, иске шрифтлар белән начар сыйфатлы кәгазьдә бастыру. Бу типография 1917 елга кадәр эшләгән.

Антонов матбагасы. 1894 елның декабрендә ачылган Леонид Петрович Антонов типолитографиясендә санаулы гына татар китаплары чыгып килгән. Ә 1911-1913 нче елларда анда татар китаплары 76 исемдә 295000 данә гомуми тираж белән нәшер ителгән. Антонов матбагасының ул еллардагы эшчәнлеге «Мәгариф» нәшрияты белән тыгыз бәйләнештә барган.

Кәримевләр матбагасы. Бертуган Мөхәммәтҗан һәм Шәрифҗан Кәримевләр мәшһүр татар тарихчысы һәм дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкертләре булган. Алар Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтенең беренче томын ике тапкыр (1885 һәм 1897 нче елларда) нәшер иткән.

«Менә сиңа шәп җырлар».
Казан: Кәримевләр матбагасы, 1914 ел

Кәримевләр 1890 нчы еллар башында Казанда, Мәкәрҗә, Минзәлә һәм Сембер ярминкәләрендә китап сәүдәсе эшен җәелдереп җибәргәннәр. 1898 елда алар китап сәүдәсе фирмасын оештырганнар, 1899 елның гыйнварында типография ачарга рөхсәт алганнар.

1900 елның 1 мартында эшли башлаган бертуган Кәримевләр матбагасы шул елда барлыгы 36 исемдәге китапны 433100 данә тираж белән нәшер иткән. Ә 1901 елда әлеге басмаханә, 97 исемдә (гомуми тиражы – 195510 данә) китап нәшер итеп, татар китабы бастыру буенча беренче урынга чыккан. Бу типография Казанда 1905 елга кадәр бердәнбер татар матбагасы булган.

1901-1917 нче еллар арасында Кәримевләр матбагасында барлыгы 1700 исемдәге китап басылган һәм аларның гомуми тиражы 20 миллион данәгә якын булган. Бу шул ук чорда Казанда басылган татар китапларының өчтән бер өлешенә туры килә. Китапларның күпчелеген алар үз хисапларына нәшер иткәннәр.

Бертуган Кәримевләр, үз типографияләре белән берлектә хәреф коюны оештырулары, үтемле дини китаплар, халык яратып укыган кыйссалар һәм фольклор әсәрләрен бастырып, китап сәүдәсе белән актив шөгыльләнүләре нәтиҗәсендә, китапчылык эшендә югары уңышларга ирешкәннәр. Шулай ук аларның арзанлы һәм түбәнрәк сыйфатлы кәгазьдә вак шрифт белән бастырып, китапның сәнгати эшләнешенә зур таләпләр куймаулары да басмаларның арзан бәягә сатылып, күбрәк таралышына ярдәм иткән.

Кәримевләр матбагасында чыккан китаплар эчтәлек ягыннан бөтен төр китапларны да, ягъни матур әдәбият, дини китаплар, фольклор әсәрләре, дәреслекләр, фәнни-популяр хезмәтләр, тәрҗемә әсәрләр, балалар әдәбияты һ.б.ны үз эченә алган.

Харитонов матбагасы. Казандагы Иван Николаевич Харитонов басмаханәсе татар китаплары бастыру белән шөгыльләнгән рус типографияләре арасында күренекле урын алып тора. Иван Харитонов 10 яшеннән Казан университеты типографиясендә хәреф җыючы булып эшли башлаган. Ул анда рус һәм европа телләрендәге, шулай ук татар, монгол һәм яһүд телләрендәге текстларны җыярга өйрәнгән. Типография эшендә зур осталыкка ирешкән Харитонов, Казандагы башка басмаханәләрдә дә эшләп, бай тәҗрибә туплаган. 1888 елда ул Г.М.Вечеслав типографиясенә идарәче булып урнашкан. Бу типография И.Н.Харитонов тырышлыгы белән тиз арада алдынгы сафка чыккан.

تیاترو مجموعه‌سی
جلد: ۱۱ — کتاب: ۱۳
«بانکروت»
پیه‌سه ۳ پرده‌ده
علی اصغر کمال
ناشرلری:
احمدگرای حسینی و شرکاسی
قزان.
Казань.
Лито-Типографія И. Н. Харитонова.
1912.
بهاسی ۲۰ تین

Галиәсгар Камал «Банкрот».
Казан: Харитонов матбагасы, 1912 ел

Харитонов Мәскәү һәм Петербургтагы типографияләрнең эше белән танышып кайткан һәм 1896 елда үз типографиясен ачып җибәргән. Харитонов типографиясе тиз арада уңыш яулаган. Башта анда 5-6 гына кеше эшләсә, 3 елдан эшчеләр саны – 40-50гә, ә 1909 елда 130 кешегә җиткән.

1902 елда И.Харитонов, Көнбатыш Европа илләренә барып, матбагачылык һәм полиграфия тәҗрибәсен өйрәнгән. Үз басмаханәсен чит ил типографияләре үрнәгендә камилләштергән. Шул ук 1902 елдан алып Харитонов матбагасында да татар китаплары басыла башлаган. Бу типография берничә елдан татар китапларын иң күп бастыра торган матбагаларның берсенә әверелгән. Анда 1902-1916 нчы еллар эчендә 700 исемгә якын татар китабы 3300000нән артык данәдә басылып чыккан. Эчтәлек ягыннан караганда, аларның күбесен матур әдәбият әсәрләре тәшкил иткән. Иң күбе татар әдипләренең (Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Р.Фәхреддин, Ф.Халиди, Г.Ильяси, Г.Рәхим, С.Җәлал, Н.Думави, З.Бәшири, К.Бәкер һ.б.) китаплары булган. А.С.Пушкин, Л.Н.Толстой, Н.В.Гоголь, И.С.Тургенев кебек авторлар әсәрләреннән тәрҗемәләр дә байтак басылган. Шулай ук татар һәм рус фольклоры әсәрләре, төрле фәннәр буенча уку китаплары, дәреслекләр, сүзлекләр дә дөнья күргән.

1916 елда Харитонов типографиясе бертуган Әхмәдуллиннарның «Өмид» матбагасы белән берләшкән һәм «Сабах» фирмасы карамагында эшләвен дәвам иткән.

XX гасыр башында Казандагы 20 типографиядә барлыгы 5154 исемдәге татар китабы басылган һәм аларның гомуми тиражы 39 миллионга якын булган. Бу чорда басылган барлык татар китапларының 75-85 проценты Казанда чыккан. Ә Казандагы басмаханәләр арасында беренчелекне бертуган Кәримевләр типографиясе тоткан.

Вараксин варислары матбагасы. Казан шәһәренең шәрәфле гражданы Владимир Васильевич Вараксин типохромолитографиясендә 1904-1916 нчы елларда 27 татар китабы 118470 данә гомуми тираж белән басылып чыккан.



Коръән.
Казан: Университет матбагасы, 1900 ел

Ермолаева матбагасы. Казан шәһәрендәге татар китапларын бастыруга зур өлеш керткән типографияләрнең берсе Инна Вениаминовна Ермолаева матбагасы булган. Бу типолитография сәүдәгәр В.М.Ключников тарафыннан 1881 елда ачылган. 1906 елның март аенда Ключников үз типографиясен кызына – И.В.Ермолаевага тапшырган. Ермолаеваның ире дә Казандагы А.М.Петров типографиясен сатып алып, ике матбаганы берләштергәннәр. Беренче елда анда 13 исемдәге татар китабы чыккан, шуларның 9ы цензура эзәрлекләвенә дучар булган. Бу типографиядә революцион һәм демократик рухтагы басмалар күп чыгуны гаеп итеп, 1906 елның ахырында аның хуҗалары Ермолаевлар җавапка тартылган һәм Казаннан сөрелгән. Тик алар 1907 елның язында кире кайтканнар. Ләкин губерна идарәсе, бу матбагага карата дошманлыгын саклап, 1909 елның апрелендә типографияне яптырган.

Ермолаева типографиясендә барлыгы 70 исемдәге татар китабы чыккан, шуларның 40ы «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан нәшер ителгән. Китапларның күпчелеге дәреслекләр, уку китаплары, русчадан тәрҗемә әсәрләр, сүзлекләр һәм фәнни-популяр китаплар булган.

Губернатор тарафыннан даими эзәрлекләнү нәтиҗәсендә, 1909 елда ябылган И.В.Ермолаева типографиясен дворянка Надежда Мариусовна Чижова сатып алган. Галим Ә.Кәримуллин язуынча, типография хуҗасының алышынуы шартлы гына булып, наширләр һәм барлык заказчылар элеккечә үк калган. 1909-1910 нчы елларда бу типографиядә 37 исемдәге китап 140500 данә гомуми тираж белән басылып чыккан.

1910 елда Чижова матбагасын В.З.Еремеев сатып алган. 1911 елда әлеге типография В.Еремеев һәм А.Шашабрин Сәүдә йорты грифы белән танылган. Бу исем астындагы типографиядә 1910-1915 нче елларда 62 исемдәге татар китабы 377140 данә гомуми тираж белән нәшер ителгән. Беренче Бөтендөнья сугышы башлану белән бәйле рәвештә кәгазь кыйммәтләнгәч, анда китаплар бастыру кимегән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Ермолаева – Чижова – Еремеев һәм Шашабрин Сәүдә йорты матбагасында барлыгы 169 татар китабы 710340 данә тираж белән басылып чыккан.

Шәрәф матбагасы. 1905 елда Россиядәге сәяси һәм иҗтимагый үзгәрешләр тәэсирендә барлык милләтләргә матбугат иреге бирелгән. Ягъни татарлар да газета-журналлар чыгару, типографияләр ачу, наширлек һәм китап тарату ширкәтләре төзү, китапханәләр оештыру хокукына ия булган. Ләкин чынлыкта матбугат ирεген тормышка ашыру җиңел бармаган. Хакимият цензура, жандармнар, чиновниклар башбаштаклыгы кебек төрле киртәләр корган.

Шактый тоткарлыклардан соң, 1906 елның 13 ноябрендә, бертуган Гыйльметдин һәм Борһан Шәрәфләр үз матбагаларын ачалар. Шәрәф матбагасы Владимир Емельянович Казаков йортындагы «Болгар» номерларында урнаша. Г.Шәрәф 1903-1904 нче елларда Петербургта Шәрык типографияләренең иң күренеклеләреннән булган Ильяс Бораганский басмаханәсендә матбагачылык эшенә өйрәнгән.

1906 елның ике аенда бу типографиядә 13 исемдәге китап чыккан. 1907 елда – 52 һәм 1908 елның беренче яртысында 41 исемдәге китап дөнья күргән. Анда күбесенчә әдәби, фәнни-популяр эчтәлектәге китаплар басылган, шулай ук революцион әсәрләр дә нәшер ителгән.

Әлеге типографиянең даими наширләре Казандагы «Мәгариф» һәм «Сабах», Троицкидагы «Хезмәт» кебек нәшрият һәм китапханәләр булган.

Гайнетдин Әхмәрев «Казан тарихы». Казан: «Бәянелхак» матбагасы, 1910 ел

1908 елның 30 июнендә Шәрәф матбагасы Казан губерна идарәсе тарафыннан ябылган. Шул елның ноябрь аенда аны Галимирза Саинов сатып алган. Типография башта яңа хуҗаның исеме белән Саинов матбагасы дип йөртелә, аннан соң «Үрнәк» дип атала башлый. 1908 елның ноябреннән 1911 елның гыйнварына кадәр «Үрнәк» типографиясендә гомуми тиражы 480665 нөсхәдән торган 152 исемдәге китап бастырылган. Шуларның 79 исемдәгесе – матур әдәбият, 12се – дини китаплар, калганнары – дәреслекләр, фәнни-популяр китаплар, календарьлар һәм бүтән басмалар. Заманының алдынгы фикерле яшь әдипләре Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, М.Гафури, Н.Думави китаплары, рус әдипләреннән А.С.Пушкин, Л.Н.Толстой, М.Горький, Н.В.Гоголь һ.б. әсәрләренең татарчага тәрҗемәләре басылып чыккан. «Үрнәк» типографиясендә басылган китапларның яртысына якыны типографиянең үз хисабына нәшер ителгән.

Матбаганың эшчәнлеге дәүләт өчен зарарлы дип бәяләнеп, патша хөкүмәте тарафыннан 1911 елның февралендә ябылган. Типография урнашкан йортның хуҗасы В.Е.Казаков 1911 елның язында «Үрнәк» матбагасын үзенә сатып алган. Ләкин, Г.Саинов чорындагы кебек үк, бу юлы да басмаханәнең чынбарлыктагы хуҗасы Г.Шәрәф булып калганлыгы ачыклангач, шул елның 26 июнендә типография тагын

ябылган. Казаков карамагында дип исәпләнгән 1-1,5 ай эчендә бу матбагада 14 исемдәге (гомуми тиражы – 49500 данә) китап басылган.

1913 елда «Мәгариф» китапханәсе җитәкчеләреннән Мөхәммәтәмин Мостафин ачкан «Мәгариф» типографиясе Казаков басмаханәсенең турыдан-туры дәвамы булган. Анда 1913-1917 нче елларда барлыгы 147 исемдәге татар китабы басылган, аларның гомуми тиражы 530350 данәгә җиткән.

«Бәянелхак» матбагасы. Казан сәүдәгәрләре Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләр үзләре нәшер иткән «Бәянелхак» газетасын (1906-1914) бастыру өчен 1907 елда махсус типография ачканнар. Анда 1907-1912 нче елларда басылган 75 исемдәге китапның гомуми тиражы 220100 данә тәшкил иткән.



Габдулла Тукай «Балалар күңеле». Казан: Өмид матбагасы, 1911 ел

«Бәянелхак» матбагасында дини һәм әдәби китаплар, фәнни-популяр әсәрләр басылган. Бертуган Сәйдәшевләр басмаханәләре өчен шрифтларны Мәскәүдәге Гербек типографиясеннән алдырганнар.

«Милләт» матбагасы. 1908 елның сентябрендә «Идрисов, Галиев вә шөрәкясе»нең типографиясе ачылган. Шул вакыттан алып бу ширкәт «Милләт» исеме белән эш йөрткән.

Бу матбагада 1908-1916 нчы елларда барлыгы 256 исемдәге татар китабы 1376015 данә гомуми тираж белән басылып чыккан. «Милләт» матбагасында күпчелеге мәктәп һәм мәдрәсә дәреслекләре, балалар өчен күптөрле уку китаплары, дини китаплар, шулай ук фәнни хезмәтләр дөнья күргән.

Ибраһим Идрисов, типография ачылганчы, үз улы Мөхәммәтне Петербург, Мәскәү һәм Истанбулга матбагачылык эшен өйрәнергә җибәргән. «Милләт» типографиясе ачылгач, анда матур шрифтлар хәзерләнгән. «Милләт»нең шрифтлары һәм китап бастыру сыйфаты югары дәрәҗәдә булган. Барлык шрифт төрләренең үрнәкләрен гравер, татар китап сәнгатенең танылган остасы Мөхәммәт Идриси әзерләгән. Ул шулай ук төсле географик карталар сызган һәм рәсемнәр ясаган. «Милләт»тәге кебек хәрефләр күптөрлелеге бер типографиядә дә булмаган. Анда коелган гарәп шрифтлары Казан, Уфа, Әстерхан һәм Урта Азия басмаханәләренә дә сатып алынган.

«Өмид» матбагасы. Китап сәүдәсе һәм нәшрият эшчәнлеге белән XIX гасыр ахырыннан шөгыльләнеп килгән бертуган Габделвәли һәм Мөхәммәтгали Әхмәдуллиннар 1908 елда «Сабах» ширкәтен оештырганнар. Алар 1911 елның җәендә үзләренең «Өмид» типографиясен дә ачканнар. Бу матбага тиз арада үсеш алган, анда хәреф кою, литография һәм цинкография дә булдырылган. «Өмид»тә басылган китаплар югары сыйфатлы булган. 1911-1917 нче елларда бу басмаханәдә 401 исемдәге татар китабы 1347575 данә тираж белән басылып чыккан. Аларның шактый өлеше фәнни-популяр басмалар булган. Шулай ук әдәби һәм тарихи әсәрләр дә дөнья күргән. ■

Яңа Татар бистәсе мирасы

Ибраһим Идриснең кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Шагыйрь, педагог, нәшир, сәүдәгәр Ибраһим Сөләйман улы Идрис 1857 елның 11 маенда хәзерге Татарстан Республикасының Арча районына кергән Наласа авылында дөньяга килгән. 1897 елда ул Казанга күченгән һәм көнкүреш товарлар, китаплар белән сату иткән. И.Идрис, 1907 елда дин галиме Галимҗан Баруди белән берлектә сәүдә йорты оештырып, китаплар сата башлаган. 1908 елда исә үзенең «Милләт» дип аталган нәшриятын ачкан. Анда 1917 елга кадәр 1,3 миллионнан артык данә белән 256 китап чыккан. Бу китаплар дин, әдәбият, тарих, медицина, ислам фәлсәфәсе һәм башка темаларга багышланган. Нәшриятта календарьлар, каталоглар да басылып чыккан.

И.Идрис педагогикага караган мәсьәләләр белән бик кызыксынган. Иҗат җимешләренең берсе буларак, 1900 елда М.Чиркова варислары басмаханәсендә аның «Тәрбияле ата» исемле хезмәте дөнья күргән. Үгет-нәсыйхәт формасында төзелгән әлеге китапта үрнәк ата булу өчен иң беренче чиратта игътибар ителергә тиешле мәсьәләләр кыскача аңлатылган.

Берничә елдан соң бу китап, байтак тулыландырылып һәм өлешчә үзгәртелеп, «Тәрбияле ата яки кыйраәт төрки», «Тәрбияле ата яки тормыш дәресе» исемнәре белән кабат басылып чыккан.

И.Идрис педагог кына түгел, шагыйрь буларак та билгеле. Аның 1914 елда «Кыз балаларга нәсыйхәт» дип аталган шигырьләр җыентыгы дөнья күргән. Анда шагыйрьнең «Уку», «Ислам дине», «Мәдех», «Пакьлек бәяне», «Сәламәтлек», «Авыруга сабырлык», «Ашамак бәяне» һ.б. әсәрләре урын алган. И.Идрис үз китапларының титул битенә шигъри юллар язып куюны гадәт иткән.

Ул 1944 елның 31 мартында вафат булып, Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнгән. Өстән караганда өчпочмак формасында ясалган кабер ташында мондый сүзләр язылган:

Беренче ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгааләә
2) Милләт
3) көтебханәсенең
4) сахиб вә нәшире
5) Ибраһим
6) бине Сөләйман
7) Идрис
8) Наласа авылында
9) туган
10) 87 йәшендә вафат
11) 31 март 1944 сәнәдә
12) рахимәһүллааһү Тәгааләә
13) рахмәтән вәәсигаһ».

Икенче ягы (уеп язылган):
1) «Йөрдем атсыз талмады айакларым
2) эшләдем эш тынмады бармакларым
3) мәхрүм итмәңез догадан
4) дустларым тармакларым
5) Ибраһим Идрис».



Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Беренче ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) «Милләт»
3) китапханәсенең
4) иясе һәм нәшире
5) Ибраһим
6) бине Сөләйман
7) Идрис
8) (Наласа авылында
9) туган)
10) 87 яшендә 1944
11) елның 31 мартында вафат.
12) Аллаһ Тәгалә аны киң
13) рәхмәте белән рәхим кылсын».

Икенче ягы:
1) «Йөрдем атсыз – талмады аякларым,
2) Эшләдем эш – тынмады бармакларым.
3) Мәхрүм итмәгез догадан,
4) Дусларым, тармакларым.
5) Ибраһим Идрис».

Күргәнебезчә, И.Идриснең кабер ташында да үзенең шигыре язылган. «Йөрдем атсыз – талмады аякларым, эшләдем эш – тынмады бармакларым» сүзләре әлеге олы шәхеснең тормыш юлын, иҗтимагый эшчәнлеген һәм иҗатын тулысынча тасвирлап бирә. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Илшат Нуриев: «Арчада һәр кеше бай һәм матур яшәргә тиеш!»

(Арча муниципаль районы башлыгы ***Илшат Габделфәрт улы Нуриев*** *белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире* ***Ләбиб Лерон*** *әңгәмәсе)*

– Арча – күз өстендә каш булырлык район. Электән үк, республикабыз күләмендә зур чаралар узганда, кунакларны бирегә алып киләләр иде. Заманында Россиянең беренче Президенты Б.Н.Ельцин да Арча Сабан туенда катнашты. Районның күрсәтерлек казанышлары булмаса, һич кенә дә аны бирегә алып килмәсләр иде. Арчадан язучылар, геройлар, галимнәр, сәнгать эшлеклеләре дә күп чыккан. Бу җәһәттән Сез Арчаны ничек бәялисез?

– Арча элек-электән мәгърифәтле район. Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал кебек классикларыбыз Арча районында туган. Без инде бу күренешне, Казан яулап алынганнан соң, халкыбызның затлы нәселләре бу якларга күчеп килүе белән аңлатабыз. Аннан элегрәк тә Арча татар дәүләтләренең иң төньяктагы ныгытма-кальгасы булган. Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани кебек дөньяга мәгълүм шәхесләр безнең районныкы. Татар әдәбиятының классиклары Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов һәм Мөхәммәт Мәһдиев – Арча кешеләре. Аларның әсәрләрен укый башласаң, иҗади осталыкларына, талантына таң каласың! Аннары танылган 70кә якын язучы һәм шагыйрьнең дә тормыш юлы Арча төбәге белән бәйле бит әле!

Ә һәвәскәр әдипләребез утызлап. Болар – әле без белгәне, күпмедер дәрәҗәдә тупларга өлгергәннәре генә. Районыбыздан чыккан җырчылар, сәнгать әһелләре дә күп. Шамил Әхмәтҗанов, Гөлзада Сафиуллина, Габделфәт Сафин, Рөстәм Закиров һәм башкаларны татар яшәгән җирдә белмәгән кеше юктыр. Айдар Фәйзрахманов – татар милли моңнарын җыр, фольклор мирасын җыеп, чит илләрдә таныткан шәхес.

Дөрес, һәр районда төрле кеше яши... Әмма үзем Арча районында туып, хезмәт юлымны биредә башлаган кеше буларак әйтә алам: халкым бик тырыш! Миңа каршы килеп, кемдер: «Татар халкы кайда эшчән түгел инде ул!» – дип әйтергә мөмкин. Әмма, туган җиремне яраткангадырмы, алар бездә аеруча булдыклы, акыллы кебек тоела миңа.

Күптән түгел бер очрашуда булдым. Шунда бер абзый: «Авылда кеше калмады», – ди. Икенчесе: «Бездә халык укымышлы, шуңа бетте инде ул. Укыган кеше гел алга китә, шул сәбәпле, шәһәргә күчеп беттеләр», – дип өсти. Яшерен-батырын түгел: авылларда елдан-ел өлкәннәр генә калып килүе, кеше кимүе күңелемне бик борчый. Дөрес, авыл хуҗалыгы техникасы да елдан-ел камилләшә. Без үскәндә, бер «ДТ-75» тракторында гына алты кеше эшләде: дүрт плугарь, ике тракторчы бар иде. Ә хәзер 10 «ДТ-75» хезмәтен бер «New Holland» («Нью Холланд») тракторы алмаштыра. Бу – 60 кеше урынына бер кеше эшли дигән сүз. Ул тракторлар компьютерга көйләнгән, уңай шартлар булсын өчен, кондиционерлары куелган. Безнең әтиләрнең төшенә дә кермәгән техника бит бу!

Шулай да, авылда эш калмады, дип әйтеп булмый. Иренмәсәң, 5-6 сыер асрап та, матур яшәргә мөмкин. Президентыбыз Р.Н.Миңнехановка рәхмәт: җирдә эшлим дигән кешегә бүген нинди генә акчалата ярдәм күрсәтелми. Сыер, ат, кәҗә, сарык алганга һәм асраганга субсидия бирәбез. Хәтта тавык, каз, үрдәк асраган кешегә дә матди ярдәм күрсәтелә. Фермерлык эшен башлап җибәрә икән, 5 миллионга хәтле акча ала. Эшен дәвам иткән фермерга – 7 миллион, гаилә фермасы төзүчеләргә – 30 миллион, кооператив оештыручыларга 70 миллионга чаклы субсидия бирәбез. Яхшы итеп үз эшен генә башкарсын! Кайсы илдә мондый күренеш бар?! Бер генә дәүләттә дә моның кадәр акча таратмыйлар. Илдә акча кытлыгы, кризис, диләр. Акча кытлыгы түгел, ә җирдә эшләргә теләүче кешеләр кытлыгы башланды сыман тоела миңа!..

> **Акча кытлыгы түгел, ә җирдә эшләргә теләүче кешеләр кытлыгы башланды сыман тоела миңа!..**

Беркөнне Казаннан бер танышым шалтырата: «Илшат Габделфәртович, минем Арчада бер туганым яши, эш белән ярдәм ит әле», – ди. Минем янга таза гына гәүдәле егет килеп керде. Казан ветеринария академиясен бетергән, «XL»дә сакчы булып эшли, 24 мең хезмәт хакы ала икән. Мин аңа ферма мөдире, зоотехник, мал табибы кирәк булган авылларны санап чыктым. «30 мең хезмәт хакы түлибез, үзең теләгән эшне сайла», – дидем. Бу әйтә: «Ю-у-ук! Мин авылда эшләмим!» – ди. Аны да аңларга була. Ул бит Казанда бер көн эшли, ике көн ял итә. Әле аның «эш»ен эш дип тә әйтеп булмый бит... Ә авылда җиң сызганып эшләргә кирәк! Аяныч, шундый хәлгә калдык. Дөрес, бу проблема бездә генә түгел. Күрше районнарның халкы да Казанга йөреп эшли.

«Мин Арчамның, язучылары һәм шагыйрьләре, җырчылары һәм артистлары, фән кешеләре һәм игенчеләре белән бергә, башка хезмәт казанышлары белән дә бөтен Татарстанда дан тотып яшәвен телим, туганнар!»

Гариф Ахунов,
Татарстанның халык язучысы

Аллаһка шөкер, быел район тарихында беренче тапкыр тәүлегенә 200 тонна сөт сава башладык. Ашлык буенча да соңгы 5-6 елда беренче өчлектән төшкәнебез юк. Республикада үскән һәр өч бәрәңгенең берсе – Арчаныкы! Бүген Президентыбыз механизаторларга зур игътибар бирә, комбайнчыларны акчалата бүләкли. Үзебез дә игътибарсыз калдырмыйбыз. Эш кешесенә игътибар итсәң, аның күңеле була. Кайчакта җылы сүздән генә дә күп нәрсә тора. Сүз – көчле корал. Әмма без соңгы вакытта аның мәгънәсен югалтып барабыз. Сугыш вакытында идеологиянең көче нинди зур булган! Җирдә тырышып хезмәт куйган якташларыбызның батырлыгын һич кенә дә онытырга ярамый...

– Сез – Республикабыздагы иң зур районнарның берсендә җитәкче. Хезмәтне бәяләп кенә калмыйча, халыкның рухи, эчке дөньясын да бик яхшы тоярга, аңларга, белергә кирәк бит әле.

– Бик күп нәрсә гаиләдән тора. *«Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас»*. Бу – күренекле мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин сүзләре. Әнием Сәлимә укытучы, тәрбияче, китапханәче булып эшләде. Әтием Габделфәрт тә гаять тәртипле кеше иде. Аның үз гомерендә бер генә мәртәбә дә аракы эчкәнен күргәнем булмады. Туры сүзле, шаян кеше иде мәрхүм. Безнең белән әтинең апасы да торды. Ул да үрнәк булырлык, гаять итагатьле, бик тәртипле, намаздагы кеше иде. Гаиләдә балага тәрбия ничек бирелсә, аның киләчәге дә шуңа бәйле. Хәзер авылларда эш юк дип зарланалар. Ә әти безне бик нык эшләтте. Өч сыер, дүрт-биш бозау, ике ат, ике тай, егермеләп сарык, йөзләгән каз-үрдәк асрый идек. Абыйга һәм апага да шул ук хезмәт эләкте. Әти-әни безне, беренчедән, хезмәткә өйрәтте. Икенчедән, укытучылар – өчебез дә югары белем алдык. Өйдә ялганлау, ялагайлану дигән нәрсә юк иде.

Остазларыма, аеруча якташым Җәүдәт Ибраһим улы Фәйзрахмановка рәхмәтлемен. Казан авыл хуҗалыгы институтында аның кул астында диплом эше яздым, диссертация якладым. Район читендәге гади генә Носы авылында туып-үсеп, үз хезмәте белән профессор, ректор дәрәҗәсенә ирешкән булдыклы, игелекле кеше ул.

Татар телен саклау өчен, татар телендә сөйләшергә сорала. Дөрес, русчасын да белү кирәк. Бөтен кеше дә сәләтле булып бетә алмый. Капкаңны атлап чыгу белән, беренчедән, акчалы булу, икенчедән, рус телен белү мөһим. Башка телләрне дә өйрәник, шуның белән бергә, үзебезнекен дә онытмыйк!

Кызганыч, җәмгыятебездә мәктәпнең, укытучыларның роле кимеде. Пандемия вакытында гына, аеруча икеөч баласы булган кеше, укытучының кадерен белә башлады. Гомумән, без үскәндә, укытучыларның җәмгыятьтә роле зур иде. Авыллардагы ипи чиратын хәтерлисездер. Шунда берәр укытучы килеп чыкса, халык аны чиратсыз уздыра иде. Бу – язылмаган закон булды. Колхоз, хөкүмәт аңа печән, салам, утын белән ярдәм итә иде...

Өченчедән, бөтен җәмгыять бер юнәлештә булырга тиеш. Күптән түгел бер авылдан «жалоба» белән килделәр. Мәктәп бакчасына тирес кайтарганнар да, балаларга шуны тараттырганнар икән. Үпкәләтмәс өчен, бу әти-әнигә нәрсә дип җавап бирергә дә кыенсындым! Югыйсә үзләре дә яхшы белә: халкыбыз гомер буе җирдә хезмәт итеп, үзенә хәләл ризыкны шуннан тапкан!..

– Тукай сүзләре белән җавап бирәсез инде: «Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш...»

– Юк шул, алай дип әйтү мөмкин түгел! Канун нигезендә баланы эшләтергә ярамый! Ата-ана, үзе дә сизмәстән, сорыкорт үстерә. Умартачылык эшен бераз белсәң, анда башка кортлар җыйган балны ашап кына ята торган кортлар була...

– Югыйсә хезмәт тәрбиясе килә- чәкнең нигезе бит инде! Без бит – мәктәпнең иске, ярылып беткән агач бураларын юып үскән буын.

– Без мәктәптә укыганда ук трактор, комбайн йөртеп үстек. Кайбер яшүсмерләр «права»лары булмаган килеш тә машина йөртә, ашлык ташый иде. Алар авылда элита, кәттә егетләр саналды. Машинада җилдереп узып киткәндә, күп кызларны кызыктырып калалар иде. Яшь малайлар, алардан көнләшеп, мин дә машина йөртсәм, ашлык яки печән ташысам иде, дип хыялланып үсте. Гомумән, техника җене кагылган малайлар күп иде. Ә хәзер балаларга көрәк, сәнәк тә тоттырып эшләтергә ярамый!.. Техника, машина-трактор турында сүз дә булырга мөмкин түгел! Болай итеп, без кемнәрне үстерәбез?!.

– Миңа калса, хезмәт тәрбиясен узган буында гына Хезмәт Геройлары үсә ала. Күптән түгел шагыйрь һәм галим Рифат Җамалның туган авылы Миржәмдә булган идем. Мари-Эл Республикасы чигендәге кеп-кечкенә татар авылында өч герой туып үскән!

– Арча районы 10 геройны биргән төбәк тә әле. Шуларның алтысы – Социалистик Хезмәт Геройлары. Габдерахманова Стэлла Зәки кызы – Татарстан Республикасында бердәнбер Герой укытучы, хәзерге көндә Яңа

Кенәр авылында яши. Илсур Шәйхетдинов һәм Дания Галимовалар күптән түгел генә вафат булдылар.

Илсур Шәйхетдинов уникаль тормыш юлы узган кеше иде. Көнбатыш Себер сазлыгы аша газ торбасы салу эшен өч бригада башкара алмагач, бу эшкә Илсур абыйны – аның җитәкчелегендәге татарлар төркемен җибәрәләр. Әлеге төркем зур диаметрлы торбаларны эретеп ябыштырып, сазлык аша беренче поляр буе трассасын уздыра.

Социалистик Хезмәт Герое Мирбат Хәстиев «Известия» колхозы рәисе булып эшләгән чорда Казанбаш һәм күрше-тирә авылларда мәдәният йорты, клублар, мәктәпләр, балалар бакчалары төзетә, ел саен дистәләрчә гаилә өй туйлары уздыра. Хуҗалык югары уку йортларына, техникумнарга үз стипендиатларын җибәрә. Мирбат ага шәхси үрнәге белән күп җитәкчеләрне тәрбияләп калдырды.

Хәзерге вакытта районыбыздан чыгып, зур уңышларга ирешкән шәхесләр байтак. Барыгызга да билгеле җитәкчеләр: Марат Готыф улы Әхмәтов, Рафис Тимерхан улы Борһанов, Ленар Ринат улы Сафин, Илдар Нурзада улы Сибгатуллин – безнең район кешеләре. Яшьләр эшләре буенча министр Дамир Фәттаховның әтисе Илдус та – Арчадан. Фатих Сәүбән улы Сибгатуллин – минем авылдаш – Апаздан. Симетбаш егете, «Таттелеком»ның элеккеге директоры, хәзер ТР Дәүләт Советы депутаты Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин да районыбыз өчен зур эшләр башкарды. Ул Ташкичүдә – Шиһабетдин Мәрҗани, Иске Кишеттә Гани Сафиуллин музейларын булдырды, мәчетләр төзетте, күпме чишмәләрне төзекләндерде, һәйкәлләр ачты, гомумән, халыкка күп игелекләр кылды.

Рөстәм Нургали улы Миңнеханов та җитәкче буларак хезмәт юлын Арчада башлаган. Биредә кайсы гына бинага барып кермә – барысына да аның хезмәте кергән. Арча балалар сәнгать мәктәбен дә, Арча шәһәре тарихындагы беренче мәчетне дә ул салдырган. Аллаһка шөкер, хәзерге көндә районда мәчетләрнең саны 90га җитеп килә. Республикабызда иң күп мәхәлләле район саналабыз.

Әйткәнегезчә, Мирҗәм авылыннан гына да ике Социалистик Хезмәт Герое – Дания Галимова һәм Галимулла Әсхәдуллин, бер Советлар Союзы Герое Нәкыйп Сафин чыккан. Әлеге авылда ике фән докторы туып үскән. Шуларның берсе – Рифат Җамал. Беркөнне әлеге авылны Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та искә алды. Бу – Татарстан читендәге кеп-кечкенә генә авыл бит!

– Киләчәккә уй-планнарыгыз ничек?

– Әйткәнемчә, тәүлегенә 200 тонна сөт җитештерә башладык. Кемдер: «Балтач һәм Кукмаралар күбрәк җитештерә бит», – дип әйтер. Әмма районда «Вамин»ның банкротлыгы беткәнгә әле өч кенә ел. Яткан җирдән торып, тезләнә башладык кына әле! Аллаһка шөкер, районга инвестор буларак шушы як кешеләре кайтты. Әлбәттә, аларның инвестиция куәте Мөслимдәге «Август», «Зәй» агрофирмаларыныкы кебек көчле түгел, ләкин бу егетләр – шушы халыктан чыгып, үз хезмәтләре белән җирдән күтәрелгән кешеләр. Арча – авыл хуҗалыгы районы. Уңай күрсәткечләр киләчәктә дә булыр дип уйлыйм.

Районда социаль объектлар бик күп төзелде. Соңгы алты елда тугыз балалар бакчасы ачылды. Татарстанның бер генә районында да моның кадәр санда балалар бакчасы салынганы юк! Соңгы елларда гына да ике мәктәп төзедек. Арча педагогика көллиятенең яңа тулай торагы корылып килә, тагын бер спорт комплексы салырга хыялланып йөрибез.

Дөрес, шәһәрдә балалар саны артуы күңелле күренеш булса да, авылларда кимүе күңелне бик борчый. Бу юнәлештә башкарасы эшләребез байтак. Авыллардагы яшьләрнең активлыгын арттырырга кирәк. Әйткәнемчә, бүген идеяләр, җирдә, туган туфракта эшлим дигән кешеләр кытлыгы бар. Әллә, дөрестән дә, шул мәгърифәтле, укымышлы булу сәбәпле, күзе ачык кеше читкә китәме? Бер Арча егетенә әйтәм: «Кайт инде Арчага, бер предприятие сал әле», – дим. Ул әйтә: «Мин үземнән чыккан энергия һәм хезмәт белән Казанда, Арчага караганда, акчаны ике тапкыр күбрәк эшлим бит», – ди. Шуңа карамастан, Арчада хезмәт куючы үзебезнең тырыш егетләр бар. Авылны кайгырту, эш урыннары, социаль объектларның санын арттыру – бүгенге һәм киләчәктәге мөһим юнәлешебез. Иң зур хыялларымның берсе – районыбызда һәр кеше бай һәм матур яшәргә тиеш! Аның рухи да, матди дә байлыгы булсын!.. ■



«Арча ягындагы авылларны культура-сәнгать, гыйлем тарихына бәйле торган бик күп җепләр бар. «Казан арты», дигәч, татар халкының культура, фән дөньясында эз калдырган кешеләре искә төшә...»

Мөхәммәт Мәһдиев,
Татарстанның халык язучысы

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Токио. XX гасыр башы

Акора музее

Мин беркөнне Япониянең бай хәйриячеләренең һәм хөрмәтле кешеләренең берсе булган Кихаҗира Акора җәнапларының өендә кунак булдым. Бу япон кешесе олы яшьтәге (75 яшьләр тирәсе булыр) һәм бик үзенчәлекле шәхес иде. Чыгышы буенча ул Иҗиго өлкәсендәге Сибата шәһәреннән, хәзерге вакытта Токиода яши. Мин бу шәхес белән театрда танышкан идем һәм менә өенә кунакка да чакырылдым.

Акора җәнаплары мәктәп-фәлән күргән кеше түгел, гомер буе сәүдә белән шөгыльләнгән, бар булган байлыгы үз көче белән эшләп табылган табыштан гыйбарәт икән. Һичшиксез, Аллаһы Тәгаләнең бүләге булган акыл иясе икәнлеге йөзендә чагыла иде. Без бу кешенең өендә чәйләр эчтек, бер сәгатьтән артык сөйләшеп утырдык. Әңгәмәбезнең ахырында ул миңа болай диде:

– Борынгы әсәрләр белән кызыксынасызмы? Әгәр теләсәгез, әнә тегендә кечкенә генә бер музей кебек җиребез бар, күрсәтә алам.

– Бик шат булыр идем.

Шуннан соң бакча эчендә торган бик зур бинага таба киттек. Акора-Сан:

– Бу – минем өем, элек монда яши идем. Бервакыт борынгы әсәрләр белән кызыксына башладым, яшь идем әле. Җыя торгач, шулкадәр күбәйде ки, хәтта үзебезгә яшәр өчен урын да калмады. Аннары инде хәзер яши торган өебезне салдырдым. Бу

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

өйне борынгы әсәрләргә калдырып чыгарга мәҗбүр булдым. Монысы инде хәзер музейга әйләнде, дияргә була.

Музей ишегенә килеп җиткән идек. Акора җәнаплары, миңа ишекне күрсәтеп: «Бу ишек такталарына игътибар итегез әле, кап-кара. Тик каралыгы буяудан түгел, табигый төсе шундый. Кара агач бу, Япониядән башка җирдә үсми», – диде.

Ишек янында, бездән алдарак килеп, бер яшь кеше көтеп тора иде. Ул нидер әйтте. Шунда ук ишек тә ачылды. Кыска гына буйлы бер хатын безне ишек янында, идәнгә үк иелеп, сәҗдә кылган кебек сәламләде.

Акора җәнаплары: «Гафу итегез, мин бераз мондагы эшләремне карыйм, дигән идем. Менә бу ханым Сезгә музейны күрсәтер», – диде һәм хатынга ниләрдер әйтте.

Хатын алдан китте. Баскычның беренче басмасында торган һәйкәлне күрсәтеп: «Ике мең еллык һәйкәл бу», – диде. Баскыч басмасы саен бер һәйкәл куелган иде. Хатын: «Болары Тибеттан китерелгән, болары – Кытайдан», – дип күрсәтеп уза, акрын гына атлый, акрын гына сөйләп бара. Бер рәсем каршысында туктап, хатын: «Бу кеше – бик атаклы шәхес. Чоток Тайси. Ул моннан бер мең ике йөз ел элек идарә ысулы турында эзләнә, уйлана һәм шураның (советның) зарурлыгын исбат итә. Шул заманнарда ук, Җийоги Эн дип аталган Шура мәҗлесе ача. Япониядә тимердән балта һәм китмән ясау да – бу кешенең иҗаты», – дип сөйләп бирде.

Без биредә дүрт залдан, ике-өч коридордан үттек. Бар җир борынгы әсәрләр белән шыгрым тулы. Моннан тыш, әле тагын берничә кечкенә бүлмә дә бар иде. Алары да тулы: алтын һәм көмештән ясалган әйберләр, кораллар, кылыч, мылтык, ядрәләр. Моннан сигез йөз ел элек керамикадан ясалган бер бомба да бар иде хәтта.

Биредәге әйберләрне санап бетерерлек түгел иде. «Менә бу бик мөһим», – дия-дия, хатын үзе белгәннәрне сөйләп бара. Кечкенә бүлмәләрнең берсендә, пыяла шкаф эчендә, кечкенә генә фарфор тартмачык тора иде. Хатын, аның каршысында туктады да: «Моның нәрсә икәнен мин белмим, тик бервакыт Кытайдан килгән бер мөселман генерал: «Безнең динебездә бу мөкатдәс санала», – дип әйткән дә, шуннан соң Акора-Сан бу тартмачыкны шулай аерым пыяла шкафка бикләп куйды. Тик ник изге икәнен белгән кеше юк», – диде.

Тартмачык үзе мөкатдәс түгел – бу ачык билгеле, эчендә берәр нәрсә бармы икән әллә? Хатын белми. Мин тартмачык эчендә «Коръән» китабы булырга тиеш дип фараз кылдым.

Моннан тыш, музейда бик зур пыяла шкафлар эчендә күп санлы кызыл тартмалар, сандыкка охшаш нәрсәләр, тагын әллә ниләр бар иде. Хатын, боларны күрсәтеп: «Болар бер төр каты кәгазьдән ясалган бик борынгы нәрсәләр икән. Борынгы җисемнәр белгече булган бер инглиз кешесе дөньяда боларның ише юклыгын әйткән», – диде.

Акора җәнапларының музее турында Аурупада да беләләр икән. Кайбер әйберләре Париж күргәзмәсендә күрсәтелгән һәм, нәтиҗәдә, Акораның музее Ошату медале белән бүләкләнгән.

Уку да күрмәгән бу кешенең мондый музей оештыруы шаккаткыч иде. Әйберләрне тәртипкә салу, урнаштыру эшен дә үзе башкарган. Үзенең туганы булган бер хатынны бирегә җитәкче итеп куйган. Һәркөн тузаннарын сөртеп, арулыкны күзәтеп, тәэмин итеп тору өчен ике хезмәтче алган. Арулыкка килгәндә, бу музей хөкүмәт музейларыннан да арурак, бар җирендә тәртип иде. Музей өстендә бер кирмән бар, аннан торып караганда, бөтен Токио уч төбендә кебек күренә иде.

Музейның өченче катында ял итү өчен билгеләнгән бер бүлмә бар икән. Биредә бераз ял иттек, чәй китерделәр. Шулвакыт хатын, миңа бер дәфтәр сузып: «Рәхим итеп, менә бу дәфтәргә уй-фикерләрегезне язгызчы. Акора җәнаплары бик канәгать



Сахалин, Курил утраулары һәм Япониянең бер өлеше кергән карта. XX гасыр башы

булыр иде», – диде. Дәфтәр бик матур һәм зур иде. Мин андагы язуларны карап чыктым: төрле-төрле милләттән бик күп кешенең имзасы бар иде. Америка, Англия, Франция һәм башка бик күп илләрдән килгән кешеләр язу язып калдырганнар. Руслардан бары тик бер Малирански* исемле кешенең имзасын күрдем. Мөселманнардан да миннән башка кеше язу калдырмаган иде.

Без биредә утырганда, мин хатынга болай дип сорау бирдем:

– Акора җәнапларының тагын нинди хәйрия эшләре бар?

Хатын, үзе янындагы тәрәзәдән бер мәктәп бинасын күрсәтеп:

– Бик күптәннән башланган хәйрия эше – менә бу мәктәп, фәкыйрь гаиләләрнең балалары өчен махсус ачылган лицей. 500гә якын укучысы бар, шунда яшәп укыйлар. Бөтен чыгымнарын ул күтәрә. Моннан бер-ике ел элек, өйләнешеп яшәүләренә илле ел тулган көннең истәлеге булсын дип, Курада һәм Авасакидә лицейлар төзетте, бөтен чыгымнарын күтәрде. Гомеренең 75 нче елы истәлеге итеп, туып-үскән җире Сибата шәһәренә торбалар аша су китертте. Башка нәрсәсе юк. Сугыш вакытында гаскәргә биш йөз мең йен бирде.

– Бу музейның каталогы юкмы? Ник каталогын төзетмисез? – дип сорадым.

– Үзе яшәгәндә каталогның кирәген күрми. Ул бик юмарт кеше. Музейны карарга килгән кешеләрнең берсе берәр нәрсә сораса, һич каршы килми. Ул кеше алырга теләп сорамаса да, бары тик игътибар белән караса, кызыксынса да, үзе шунда булса: «Ошаттыгызмы?» – дип сорый. Аннары биреп җибәрә. Шуңадыр, ахры, улы, берәр хөрмәтле кунак килсә, һәрвакыт берәр эш таба, атасын музейга җибәрми. Бүген дә менә, Сезгә булган зур илтифатын күреп-аңлап алуга, сәүдә эшләре белән бәйле мөһим эш барлыгын сылтау итеп, алып китте. Ул Сезне һич кенә дә буш кул җибәрмәс иде.

Акора җәнаплары зур дәрәҗәле, олы җанлы һәм бик мөлаем кеше. Аның бөтен фикере японлык һәм япон милләтенә хезмәт итүгә юнәлгән, күрәсең. Хәтта аның юмартлыгы да япон милләтен бөеклекләргә күтәрү өчен иде булса кирәк.

Бу музейны дүрт сәгать буе карап йөргәч, чыгарга дип ишеккә килдек. Хатын, ахры, хәбәр биреп өлгергән, Акора җәнаплары безне ишек янында көтеп тора иде инде. Аңа рәхмәтләремне белдергәннән соң, саубуллаштык. Акора җәнаплары: «Без Сезгә Аурупа кешесенә караган кебек карамыйбыз. Вакытыгыз булса, тагын рәхим итеп килегез, бик шат булырбыз», – диде.

---

*Гарәп хәрефләре белән Малирански рәвешендә язылган бу фамилиянең Мелиоранский (мәсәлән, Платон Михайлович Мелиоранский (1868-1906) – Көнчыгышны һәм төрки дөньяны өйрәнгән галим) дә булуы бик мөмкин. Ләкин бу галимнең Япониядә булуы турында мәгълүматыбыз юк (тәрҗ. иск.).

Мин Акора җәнаплары белән тагын берничә тапкыр күрештем. Бу шәхес аяклы тарих кебек иде: Японияләнең элеккеге эчке сугышларында үзе катнашкан, бик күп күргән-кичергән, бик күп вакыйгалардан хәбәрдар. Күп вакытын мәктәпләрендә үткәргән. Акора җәнаплары янына кайчан гына килсәм дә, ул һәрвакыт өстенә милли кием, аякларына шулай ук милли аяк киемнәре булып саналган артсыз башмак кигән була иде.

Беркөнне киемнәр турында сүз чыккач, ул болай диде: «Берара Аурупа киемен кия идек, хәзер кирәге калмады. Моннан соң инде бөтенләй килешмәс тә. Без Японидә миллият мәсьәләсен күтәреп чыкмасак, булмас. Миллият тә бары тик сүздә генә сөйләнсә, булмас. Японлыкның бөтен көче – миллияткә бәйлелектә. Без руслар белән булган сугышта да, корал көченнән бигрәк, миллият көче белән җиңеп чыктык».

Акора җәнапларының хәйрия эшләре турында бераз алдарак әйтеп үткән идем инде. Тик шунысы кызык: үзенең әйтүе буенча, ул Японияләнең иң бай капитал ияләре арасында да түгел икән. Игътибарымны җәлеп иткән нәрсә – аның зиһен, хәтер көче иде. Беркөнне сүз арасында Микадо династиясе турында сораган идем. Ул миңа Микадоның бабаларын, «фәлән улы фәлән улы фәлән», дип санап китте, аларның тәхеткә утырган елларын, хөкемдарлыклары кайчанга кадәр дәвам иткәнлеген һәм вафат булган елларын, шул рәвешле 2569 еллык династия тарихын сөйләп бирде.

Бу хакта башкалардан да ишеткәнем булды, тик күбесе елъязмага карый-карый сөйләгән иде, ә ул яттан, бернигә карамый сөйләде.

Япон императорларының шул 2569 елны эченә алган дәвердәге каберләре дә билгеле, һәммәсенең өстенә затлы биналар салынган. Токиода Конт Акимотаның өендә боларның рәсемнәре бар, миңа күп тапкырлар күрсәттеләр.

Японнар Микадоны бик изгеләштерәләр. Бер кешенең нәселе 2569 ел бервөзлексез сакланып барсын әле, ышануы да кыен. Менә шул сәбәпле, бу шәхес илаһи зат итеп кабул ителә, изгеләштерелүе дә шуның белән бәйле.

Җир тетрәү һәм утраулар

Япониядә җир тетрәү бик еш була икән, чөнки дөньяда Япониядәге кадәр янартаулары булган башка бер ил юк. Тик ничек булгандыр, Япониядә яшәвемнең беренче-икенче айларында җир тетрәү турында бер хәбәрем дә булмады.

Беркөнне төнлә йоклап ята идем, йорт бер тапкыр чайкалды, ләкин, йокылы булганга, бик аңлап бетерә алмадым. Йокы аралаш үземне поездда барам икән дип уйладым, поезд рельс алыштырды, ахры, дидем. Бертуктамый селкенәм: йорт анда-монда чайкала икән. Ул арада күрше бүлмәдән: «Ай, лампаларны карагыз», – дигән тавыш ишеткәч кенә, аңлап алдым: җир тетри икән. Ул төнне, чынлап та, җир бик көчле чайкалган, тик мин бик аерып бетерә алмаганмын. Иртәгесе көнне газеталарда бик күп хәбәрләр язылды, бар кеше дә шул хакта гына сөйләште. Шул көннән башлап кына ныклап игътибар итә башладым: җир чайкалмаган көн бик сирәк була икән. Ә инде җир чайкалмый калган төн бөтенләй дә булмый икән, дисәм дә, дөреслеккә туры килер. Кайбер көннәрне хәтта көнгә берничә тапкыр чайкалганы да була, эш-мәшәкать белән беленми генә икән. 1889 елда (бу ел японнарда «хәрәкәт елы» буларак мәшһүр икән) 1014 тапкыр җир тетрәү булган.

Бераз алдарак та искә алып үткән идем: Япония мәмләкәте бөтенләе белән утраулардан гыйбарәт. Бу утрауларның иң зуры – Нихон утравы, аны кайчак Хонҗу дип тә атыйлар. Бу утрауның мәйданы 113000 квадрат километрны тәшкил итә,

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Токиода җир тетрәү. 1891 ел

Фудзи янартавы. XX гасыр башы

биредә 15 миллионлап кеше яши. Кырык алты өлкәгә бүленгән. Мәмләкәтнең башкаласы һәм дәрәҗәле торак урыннары да әлеге утрауда урнашкан. Бу утрауның төньяк тарафында шактый салкын була, Никата, Иваки, Иваҗиро, Йешиго кебек җирләрдә кышын боз ката. Көньякка таба барган саен, һава уртачалаша бара. Биредә елның бик көчле яңгырлар ява торган вакытлары бар.

Зурлыгы ягыннан утрауларның икенчесе – Хоккайда утравы. Аны Изо дип тә йөртәләр. Төньякта урнашкан бу утрауның мәйданы якынча 70000 квадрат километр. Биредә биш миллионга якын кеше яши. Бу җирләр кыш айларында тулысынча боз белән каплана, пароходлар йөри алмый, бик көчле суыклар була. Бер яктан руслардан алынган Сахалин утравы белән дә бәйләнеше булган.

Хоккайда утравы да шактый төзек, һавасы суык булса да, бик ышанычлы.

Ә менә Чикоко утравы, үзәккә якын урнашкан булса да, бик үк төзек түгел. Тимер юлы да юк, дип әйтергә була. Яр буе өлкәләреннән калганнары утырып йөрү, йөк ташу чараларыннан бөтенләй мәхрүм. Шунысы бик гаҗәп: бу утрауда сирәк кенә чайкалулар хис ителсә дә, зур җир тетрәүләр булмаган. Хонҗу утравында нәкъ Чикоко биеклегендә урнашкан Авасаки шәһәренең исә бөтенләй җимерелеп беткән вакытлары да булган.

Японияда җир тетрәүләр бик еш булганга, йортлар һәм биналар аны күздә тотып салынган. Нинди генә көчле җир тетрәүләр булса да, үлем-җетем сирәк була икән. Хөкүмәт тә, бу җәһәтне игътибарга алып, электр белән яктыртуны җәелдерә бара. Инде хәзер үк ул авылларга кадәр барып җиткән.

Тайвань утравын бик тырышып төзиләр, төзекләндерәләр. Шулай ук, әлегә рәсми яктан илнең яшәү җирлеге итеп игълан ителмәгән булса да, Пратас утравында да бик зур төзелешләр бара.

Японнарның сәясәтләре, куллану тәртипләре шундый – башта төзү.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

«Балаларыма, җәмәгатемә тимәгез!»

Габдерахман хәзрәт

Наилә Ахунова архивында саклана торган әлеге кечкенә генә язмада Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы герое Габбас хәзрәтнең прототибы, Шәһидә Максудова-Ахунованың әтисе Габдерахман хәзрәтнең һәм гаиләсенең фаҗигасе сурәтләнә.

Әнинең әтисе Ризван бабай ачлык елда – 1921 елда вафат булган. Ачтан үлгән диясе килми, чөнки аның балалары – Банат, Һаҗәр, Мәрхәпҗамал, Йөзлекәй, Әхмәтясәви, Разетдин, Заһирә һәм Хәят әби исән калганнар бит, ә бабай үлгән, чире булгандыр аның. Аннан ул аучы булган, мылтыгы да булган, үлеменә ачлык та, чире дә сәбәпче булгандыр инде. Янәшәдә генә Ахун абзый, Сөләйман абый, Суфияттәй бала-чагалары белән исән калганнар, бер Ризван бабай гына үлгән – чире булгандыр, чире! Аучы башы белән ачлыктан үлмәс иде. Әнкәй ул чакта әткәйдә – Габдерахман хәзрәттә кияүдә булган инде. Алар да бит кодаларының ачлыктан үлгәнен карап тормаслар иде, ничек тә ярдәм итәрләр иде. Кем белә? Кем белә?..

Әткәй ул чакта – 40 яшьтә, Тәти әнкәй – 55 яшьтә, үземнең әнием 25 яшендә була. Тәти әнкәй дигәне – әткәйнең беренче, олы хатыны. Әткәйне, Кыдырлы авылына алып барып, хаҗга киткән җирендә вафат булып калган абзыйның тол калган хатынына йортка керткәннәр. Әткәй, егерме биш яшендәге Иж-Бубый мәдрәсәсендә укыган егет булган. Тәти әнкәй бояр Заһитовлар нәселеннән, баласы булмаган, ул – 40 яшендә иреннән тол калган хатын.

Беренче тапкыр мине Тәти әнкәй алып китте Казанга 1932 елның җәендә, әткәй асылынып үлгәч. Тәти әнкәй үзе Казанда Маһирә апада яши иде, ул анда алданрак – 1930-1931 нче елларда киткән. Мин аның киткәнен бик ачык хәтерләмим, тегесен дә, монысын да… Миңа бит ул елларда дүрт-биш яшьләр генә булган инде. Алай дисәң, истә калган вакыйгалар да бар. Җиңгинең суга батып үлүе… Маһинурның әтисе Пәткеш (Фәтхетдин) абзыйның атылып үлүе, әткәйнең асылынып үлүе дә хәтердә бит…

Әткәй 1932 елның 20 маенда үлгән. Миңа – биш яшь ярым, энем Касыймга – 3 яшь, Камил энемә – нибары 2 ай. Ул әтине гомере буе кичермәде безне ташлап асылынып үлгәне өчен. «Тапкан җиңел юл котылыр өчен!»– дияр иде. Әткәй курыккан шул! Төрмәдән дә, сөргенгә сөрелүдән дә… Барыбыз бергә үлеп бетәрбез, чыдый алмабыз дип курыккан. Янәсе, үзе үлгәч, балаларына, хатынына тимәсләр. Язып калдырган кәгазенә дә шулай дигән: «Балаларыма, җәмәгатемә тимәгез!»

Шәһидә Максудова-Ахунова ■

Мөһаҗирлектәге татар китабы

Фин илендә Кәрәкәшле кызы

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Гәүһәр Туганай

...Чит илләрдә яшәү читен хәл ул,
Йөзләрне саргайтты сагышы. (67 б.)

Туган илем калды бик еракта,
Алсуланып кояш чыккан якта... (68 б.)

Гәүһәр Туганай

Мөһаҗәрәттәге милләттәшләребез, чит мәмләкәтләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты хакында сүз чыкканда, күпләр иң әүвәл Финляндияне атый. Моның үзенә күрә ныклы нигезе дә бар. Бердән, бу ил – йөз елдан артык Рәсәй империясе составында яшәп, Октябрь инкыйлабыннан соң бәйсезлек алган күрше дәүләт. Ул элек-электән үк татарлар чагыштырмача оешып яшәгән Мәскәү, Петербург, Нижгар һәм Касыйм төбәкләре белән аралашып тора. Балтыйк флотында милләттәшләребезнең хезмәт итүе дә мәгълүм. Финляндиядәге татарлар хакында Гәүһәр Туганайның «Безнең тормыш корылышы» (72 б.) әсәрендә дә кайбер мәгълүматлар бар: *«Моннан берәр гасыр элек мишәр бу җиргә килгән. Төрле кием-салымлыклар метрлап сатып йөргән; Тора-бара юллар табып, гаиләләре дә килгән»*. Икенчедән, бу мәмләкәттә кавемдәшләребезнең төпләнеп гомер итә башлауларына инде ярты гасыр ярымнан артык вакыт узып китте. Алар, гәрчә сан ягыннан бик аз булсалар да, милли үзлекне саклауда башка илләрдәге һәм төбәкләрдәге милләттәшләребезгә үрнәк рәвешендә дә карала. Моңа биредәге татарлар, иң беренче чиратта, телне, динне, моңны, гореф-гадәтләрне саклау, чагыштырмача бердәмлек, шактый гына китаплар, гәҗит-журналлар чыгару аша ирешәләр. Татар дөньясының мәркәзе Казан белән дә традицион бәйләнешләре көчле.

Финляндиядәге (Суомидагы) кавемдәшләребезнең иң зур күпчелеге үзләренең килеп чыгышы, нәсел-нәсәпләре белән Нижгар (Сергач) яклары, тагын да төгәлрәк әйткәндә, Яңапар (Актук) авылы белән бәйле. Бу хакта аларның бик күп язмалары бар. Үзе дә шушы авылда туып үскән, 15 яшендә Суомига күчеп килгән Хәсән Хәмидулланың (1900-1988) «Яңапар тарихы» китабында (Хельсинки. 1954. –

«

Мәгълүм ки, 20 нче еллардагы ачлыктан берничә йөз мең милләттәшебез кырыла. Башка җирләргә, илләргә күчеп, качып китүчеләрнең саны да гаять күп.

85 б. Гарәп язуында) Финляндиядәге милләттәшләребез, аларның асыл ватаннары хакында шактый тулы мәгълүматлар бәян ителә. Биредәге каләм әһелләренең дә зур өлеше еш кына үзләрен «Нижгар мишәре» дип саный. Әмма моннан чыгармалар да бар. Шундыйларның берсе – Гәүһәр Туганай (15.10.1911-4.02.1998)[1]. Ул чыгышы белән исеме җырларда яңгыраган, берничә билгеле затны (Фәһимә Хисамова, Әнвәр Шәрипов һ.б.) биргән атаклы Кәрәкәшледән. Элек Самара губернасының Бөгелмә өязенә кергән бу авыл хәзер Татарстанның Ютазы районы составында.

Истәлекләрдән булачак шагыйрәнең әтисе Нигъмәтулла һәм әнисе Гайниҗамалның уртача хәлле, чагыштырмача укымышлы, абруйлы кешеләр булуы күренә. Гаиләдә китап үзенә лаеклы урынны били. Авылда электән үк билгеле мәдрәсә эшли. Гәүһәр шул уку йортында, бераздан аның нигезендә ачылган мәктәптә белем ала. Бу – бик тә катлаулы, болгавыр еллар: инкыйлаб дулкыннары, аклар-кызыллар, илдәшләр сугышлары… Тормыш кырмыска оясы кебек кайный. Тиз арада боларга коточкыч ачлык афәтләре килеп кушыла. Ул безнең әдәбиятта, аеруча Г.Ибраһимов, М.Гафури, Ф.Әмирхан әсәрләрендә шактый калку гәүдәләнеш тапкан. Соңрак булса да, аларга Гәүһәр Туганай да килеп кушыла. Аның «Бала вакытымдагы хакыйкый хатирә» исемле язмасында[2] (76-80 б.) ачлык чорының шактый гына аянычлы күренешләре тасвирлана. Шагыйрә аны үз язмышы, үз гаиләсе, үз төбәге мисалында сурәтли («Бу хәсрәтне, – ди ул, – мин дә күрдем…», «Газраил гел янымда… торды…». «Үлән орлыклары белән туену» да телгә алына. Ризык эзләп авылдан авылга хәерчеләр йөри. «Илдә эт, мачы калмады», –ди автор. Әсәрдә Американың азык-төлек белән ярдәм итүе дә искәртелә. Әмма барыбер халык кырыла, «унбишәр» мәетне бер кабергә күмәләр. Әсәр ахырында күрше авылдагы дүрт балалы бер гаиләдә кечкенә кызларын пешереп ашау кебек коточкыч хәл дә сурәтләнә… Мәгълүм ки, 20 нче еллардагы ачлыктан берничә йөз мең милләттәшебез кырыла. Башка җирләргә, илләргә күчеп, качып китүчеләрнең саны да гаять күп. Болар арасында Кәрәкәшленең үсмер кызы Гәүһәр дә бар. Кайбер язмаларда аның туган төбәгеннән Төркиягә килүе искәртелә. Бу мәкаләне язганда без фәкыйрегезгә күренекле милләттәшебез, күптәнге танышыбыз, Хельсинки университеты мөгаллиме Окан әфәнде Таһир белән берничә мәртәбә элемтәгә керергә туры килде[3]. Аның һәм Гәүһәр апаның кызы Гүзәл ханымның әйтүенчә, булачак шагыйрә әтисенең туганы, заманында Буби мәдрәсәсендә укыган Рәйхана ханымның чакыруы буенча әүвәл Финляндиягә килә. Аның бу «һиҗрәте», чикләрне үтүе бик тә авыр булгандыр. Әдибәнең 1962 елда иҗат ителгән «Бала вакытым» шигырендә (10-13 б.) мондый юллар бар:

…Илле яшем үтеп киттем, сагынам туган илне көн дә,
Гомер буе читтә адашсам да, татлы уйлар калды күңелдә.

Бу әсәрдәге сан һәм кайбер башка өстәмә мәгълүматлар Гәүһәрнең Суомига 1922-1923 нче еллардан да иртәрәк килмәвенә ишарә ясый. Биредә ул берара

---

[1] Кабер ташында шагыйрәнең туу вакыты 1907 ел дип күрсәтелгән.
[2] Гәүһәр ханым Туганайның «Шигырь мәҗмугасы». Беренче бүлек… – Тампере, 1970. – 99 б. Алга таба җәяләр эчендә бу чыганакның битләр саны гына күрсәтеләчәк.
[3] Биргән мәгълүматлары, җибәргән фотолары өчен мин бу игелекле затларга рәхмәтләр укыйм.

яшәгәч, Рәйхана апасы һәм җизнәсе белән Төркиягә китә. Кайда яшәве, укуы бик билгеле түгел. Бу мәмләкәттә 3-4 ел торгач, Финляндиягә әйләнеп кайталар. Әүвәл Тирйокида (Зеленоград. 1939 елдан ул СССР составында), аннан ил башкаласында гомер кичерә. 1933 елда чыгышы белән Касыйм татарларыннан булган Хәким (1907-1989) исемле кешегә кияүгә чыга. Окан әфәнде аңлатуынча, аның фамилиясе Тәкәнә исеменә нигезләнгән Текенаев рәвешендә була. Финляндиядә ул аны «Туганай» дип үзгәртә. Гәүһәр апабыз үзенә тәхәллүс итеп шул исемне ала. Аларның берничә баласы булуы мәгълүм. Исемнәре бик мәгънәле, үзебезчә, милли: Хәтфә (1934 елгы), Тугры, Гүзәл (1939 елгы, минем яшьтәш), Якты, Зирәк… Боларның кайберләре белән шәхсән үземә дә күреп сөйләшергә туры килде. «Ислам җәмгыяте»ндә секретарь вазыйфаларын башкаручы, ачык күңелле, ярдәмчел Зирәк миңа гыйльми-тикшеренү өчен кирәкле материалларны табуда шактый булышты.

Туганайлар, нигездә, мех сәүдәсе белән шөгыльләнә. Гәүһәр апа да кибеттә эшли. Бу аның шигырьләрендә дә берничә мәртәбә телгә алына. «Үтте еллар» парчасында (1967) ул сату, кибет эшенең авырлыгын да искәртеп куя:

...Уен-көлкегә, җырларга калмый һич форсат, вакыт,
Кибеттә утырып торабыз үләксә тиресе сатып.
Кич белән өйгә кайтабыз кара тузанга батып,
Көн буена арып-талгач, йоклыйбыз инде ятып. (70 б.)

Миңа 1990 елда Финляндиягә өч айлык гыйльми командировка вакытында Гәүһәр апа, аның гаилә әгъзалары белән берничә мәртәбә сөйләшергә, аларның Хельсинки мәркәзендәге «Туганай» дип исемләнгән мех кибетләрен дә күрергә туры килде. Беренче очрашу, ничектер, күңелдә ныграк уелып калган. Хельсинкига килеп, берничә көн үтүгә, Гәүһәр апаның кызы Хәтфә ханым үзенең елык-елык килеп торган машинасында кунакка алып китте: тору урыннары шактый зур-иркен. Мул тормышта яшәүләре сизелеп тора. Мине бөтен кыяфәтеннән, үз-үзен тотышыннан ук татар икәнлеге күренгән бер хатын каршы алды. Ул Гәүһәр апа булып чыкты. Мул итеп чын милли табын әзерләнгән. Самавыр да гөрләп тора. Утырдык. Мин, артык ачылып китмичә, үземне рәсмирәк тотам. Имеш, Совет кешесе. Шунда Гәүһәр апабыз, үземнең әнкәй кебек аркадан сөеп: «Хатыйп улым, читенсенеп утырма», – дип, йомшак кына әйтеп куймасынмы! Шуннан телләр ачылып, сөйләшеп киттек. Мин аның матур сөйләменә, тормышны, кешеләрне, әдәбиятны, халкыбызны белүенә сокланып утырдым. Үз туган теленнән тыш, ул төрек, фин, швед һәм кайбер башка телләрдән дә яхшы хәбәрдар иде. Гәүһәр апа минем лекцияләргә дә иң алдан килеп утырды. Милләттәшләребезнең аны хөрмәт итүен үз күзләрем белән күрдем. Ул милли чараларда актив катнаша, халкыбызның гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклауга үзеннән зур өлеш кертә. Туган якларына да кайтып килгәләве, туган-тумачалары белән бәйләнештә торуы да мәгълүм[4].

Финляндиядән мин мөһаҗирлектәге татар китапларына шактый баеп кайттым. Ул басмаларның зур өлешен үзебезнең китапханә-музейларга тапшырдым. Аларның бит шактый өлешен миңа Гәүһәр апа бүләк иткән иде! Бу гамәле өчен генә дә ул олуг рәхмәтләргә лаек. 1990 елның апрель аенда Хельсинкиның тимер юл вокзалында мине озатырга, башка күп кенә милләттәшләребез белән бергә, Гәүһәр апа да килгән иде. Шәхсән миңа һәм үзенең кардәше, авылдашы Фәһимә ханым Хисамо-

[4] Туган якларына Гәүһәр Туганай берничә дистә елдан соң гына кайтып килгән бугай. «Әнкәм үлгәндән соң» дип исемләнгән шигырендә (15.07.1956) ул әнисе белән очрашуны озак көтүен искәртә. Әмма барыбер бу теләгенә ирешә алмый: «Мин утыз ике ел көттем әнкәй белән күрешүне», «Күрмичә калдым еракта әнкәйдән мин ятим». (2 б.)

вага күчтәнәчләрен биреп: «Исән-сау йөр, Хатыйп улым», – дип, мине озатып калды. Ул җибәргән тәм-томнар белән өйдәгеләрне генә түгел, эштәгеләрне дә сыйладым. Үзенә күп рәхмәтләр укыдылар. Яңадан Суомига баруларымда инде ачык йөзле Гәүһәр апабыз якты дөньяда юк иде... Аның һәм кайбер башка милләттәшләребезнең каберләрен генә зиярәт кылырга, рухларына дога кылырга гына туры килде.

* * *

20 нче йөздә Суомида яшәгән кавемдәшләребез мең тирәсе генә булса да, алардан чыккан каләм әһелләренең саны дистәдән артып китә: Хәсән Хәмидулла (1900-1988), Садрый Хәмид (1905-1987), Садыйк Хөсәен (1906-1971), Гайсә Хәкимҗан (1896-1972) һ.б. Болар арасында Гәүһәр Туганай да мөһим урынны били. Аның әдәби иҗат белән кайчаннан бирле шөгыльләнүе төгәл билгеле түгел. Шигырьләре аркылы без аның яшьтән үк әдәбиятны яратуын, сүз сәнгатенә тартылуын күрәбез. Әмма Кәрәкәшле кызы әдәби иҗат белән ныклап чагыштырмача соңрак, 50-60 нчы елларда гына, шөгыльләнә башлаган булса кирәк. 1968 елның 16 апрелендә язылган шигырендә ул болай ди:

Кайвакыт күкрәгемдә кайный хисле илһам чишмәсе,
Тупланып килгәч күңелгә, язмыйча соң нишләсе?..
Ярты гомрем үтте язарга вакыт таба алмыйча,
Бәлки, дустлар уйлый торгандыр бу «саташкан» диеп.
Мин үз-үземне таныйм да, бакмыйм аларга кыек.
Укысаң әүвәлге шагыйрьләр тарихын – нәкъ шулай,
Тиле исмен күтәреп йөрүе булмаган уңай. (72 б.)

Шагыйрә безгә мәгълүм әсәрләренең башында ук язылу вакытын көне, ае, елы белән күрсәтеп бара. Аларның иң зур күпчелеге нәкъ менә 60 нчы елларга карый. Арада, сирәк кенә булса да, 50 нче елларда иҗат ителгән парчалар да күзгә ташлана.

Гәүһәр Туганайның аерым язмалары мөһаҗәрәттәге төрле җыентыкларда, гәҗит-журналларда басылып килә. Мәсәлән, 1986 елның 25 октябрендә Хельсинкида Г.Тукайның тууына 100 ел тулу уңае белән зур кичә оештырыла. Аның җыентык рәвешендәге махсус программасы да бар. Анда шагыйрьнең берничә әсәре дә («Пар ат», «Яз галәмәтләре», «Туган авылым», «Көз» һ.б.) урнаштырылган. Шунысы мөһим: латин хәрефләре белән басылган бу мәҗмуга Гәүһәр Туганайның Тукайга багышланган шигырьләре белән ачыла һәм ябыла. Аларда автор шагыйрьнең бөеклегенә, «мәңгелегенә» басым ясый. *«Аның исеме, шигырьләре мәшһүр, җаныбызга – аш, күңелгә – нур»*, – ди. Җыентык ахырындагы «Тукайны сагыну» парчасы мондый строфа белән төгәлләнә:

...Ничә еллар көттек сиңа тиң торганны,
Белеп булмый синең мислең туармы?
Һәр ел зурлап хөрмәтлибез бу көнеңне,
Вакытсыз ташлап киттең – әрнетә күңелне.

Илдәге басмаларда шагыйрә иҗатының аерым үрнәкләре, гәрчә бик сирәк булса да, күзгә ташлана. Күзәтү характерындагы язмаларда, шул исәптән без фәкыйрегезнең хезмәтләрендә дә Гәүһәр Туганай хакында аерым белешмә-мәгълүматлар бар. Шагыйрәнең безгә мәгълүм тәүге җыентыгы ике китап («бүлек». – 99 б.; 104 б.) рәвешендә 1970 елда дөнья күрә. Гарәп хәрефләре белән басылган бу «Шигырьләр мәҗмугасы» «Тампере Ислам мәхәлләсе имамы» Хәбибрахман Шакир матбагасында нәшер ителә. Кызганыч ки, бу китапларның «беренче бүлеге» генә кулыбызда бар. Шуңа күрә хәзерге вакытта шагыйрә иҗаты хакында сүз әнә шул басмага таянып

Гәүһәр һәм Хәким Туганайлар туй көннәрендә. Тирйоки (Финляндия), 1933

алып барыла, мисал-өзекләр дә шул «Беренче бүлек»тән китерелә. Кәрәкәшле кызы үзенең иҗатын, әлбәттә, 1970 елдан соң да дәвам иттерә. Әмма ул чор әсәрләренең аерым туплам рәвешендә нәшер ителүе бу юлларның авторына хәзергә мәгълүм түгел.

1970 елда дөнья күргән «Шигырьләр мәҗмугасы»нда (төгәлрәге, аның «беренче бүлеге»ндә) авторның 87 шигыре урнаштырылган. Алар, нигездә, 60 нчы елларда иҗат ителгән. Әлеге китап, гомумән, лирик-эмоциональ характерда; эпиклык-вакыйгалылык азчылык урынны били. Әсәрләре аркылы авторның шигъри дөньясы, рухи халәте, күңел биографиясе шактый тулы күзаллана. Шәхси уй-кичерешләр, хатын-кыз психологиясе аркылы иҗтимагый, фәлсәфи, милли, тарихи мәсьәләләргә шактый урын бирелә. Туган ил һәм җир, газиз халкың, ата-ана, туганнар һәм кардәшләр, якташлар һәркем өчен бик тә якын-үз. Алардан аерылу адәм баласын, аеруча иҗат әһелләрен кайгы-сагышка, сагыну диңгезенә сала. Мондый халәт, мондый хис Гәүһәр Туганай парчаларында бигрәк тә ачык гәүдәләнә. Аның күп кенә шигырьләре туган ягына мөнәсәбәттә язылган. Җыентыкның тәүге битләрендә үк без 1956 елда иҗат ителгән шундый юллар белән очрашабыз:

Мин бик яшьдән айрылдым туган илдән,
«Илем», дигәч, күңлем нәзек нечкә кылдан.
Шуның өчен төшерә алмыйм сине телдән,
Иген үсә иде уңып башдан, билдән,
Беркайчан да туймас идем туган илдән,
Аны мәшһүр итәр идем, килсә кулдан.
Авылыбызның исеме дә Кәрәкәшле,
Тирә-ягы биек таулар һәм бурташлы,
Анда үскән кызлар матур, кара кашлы,
Җегетләрдә – кара мыек, кара чәчле... (2 б.)

Хатыйп Миңнегулов Туганайлар кабере янында. Хельсинки, 2018 елның 2 ноябре

Автор кайвакыт тормыш, гомер агышы хакында уйлана. Аның фикерләвенчә, бу дөньяда, рәхәт-шатлыкка караганда, газап-михнәт хәддин ашкан. Лирик герой әнә шул капма-каршы төшенчәләр арасында бәргәләнә: *«Хәсрәт ялкыны эчендә тарсынып җаным талашты, Бер туктамый яна йөрәк, янмаган көне бик сирәк»* (46 б.); *«Дөнья кыса, тормыш авыр, сызыла күңлем тарсына, Ямь таба алмый, тәм таба алмый, нигә болай ярсына?!.»; «Җан яна, урын таба алмый, михнәт эчендә иртә-кич»* (63 б.). Татар шигъриятендә «күңел»гә мөрәҗәгать итеп, аны хәтта рәдиф итеп (юл ахырында кабатлап) язу күптәннән килә. Гәүһәр Туганай да бу традициягә тугры кала. Газәл жанрына тартым бер шигырендә автор лирик герой күңеленең бәргәләнүен, сызлану-әрнүләрен, яну-көюләрен шактый үтемле тасвирлый:

Әй, күңел, ялкыны юк янган күңел,
Су сибеп сүндерергә мөмкин түгел.
...Дөнья золмәтендә изелгән күңел,
Һәр явызлыкларга түзә алган күңел.

Шагыйрә мондый халәтнең үзенә күрә сәбәбе булуын да искәртә:

Дөнья ерткыч булмаса, янмас идек,
Хөр яшәр, йончымас, интекмәс идек... (38 б.)

Кәрәкәшле, туган илнең бер символы, коды буларак, шагыйрәнең кайбер башка әсәрләрендә дә очрый. Бу тирәдәге халыкның яшәеше билгеле бер дәрәҗәдә Ык белән дә бәйле. Гәүһәр Туганай шигырьләрендә дә әлеге елга телгә алына. Аның «Ык буе хатирәсе» дигән махсус шигыре дә бар (44-45 б.). Бу әсәр берничә яктан игътибарга лаек. Беренчедән, әлеге елга, аның кешеләре автор өчен бик тә кадерле:

...Ык буенда үскән кызлар ул тирәдә мактаулы:
Йөзе кояш, кашы кыйгач, эшчән, армый-талмый...
...Бала чагымда ук таныйм: ямьле лә ул Ык буе,
Кара бөрлегән, карлыган куаклары бик куе.
Чиләкләп җыйсаң да бетми – халык җыя җәй буе,
Җәтмә, кармакка эләкде зур җәен балыклары...

Икенчедән, бу шигырь авторның нәсел-нәсәбенә, тәрҗемәи хәленә дә билгеле бер ачыклык кертә:

Каразирек авылында әнкәем туып үскән,
Буе кыз булгач, Кәрәкәшлегә яшь килен булып киткән.
...Әнкәй Вилдан нәселендән – Әхмәдҗан бабам кызы
Ерак әбием Сәхибкәмал – сөлекче иде үзе.

Җыентыкта «Крым»ны мактаган бер шигырь дә күзгә ташлана (19 б.). Ул көньяктагы Кырым түгел, ә Ык тирәсендәге Крым – Сарай. Автор аның гүзәллеген генә түгел, ә үзе өчен бер «Ватан» булуын да искәртә. Күрәсең, аның берәр бик якын кешесе бу авыл белән бәйледер.

Ахыры киләсе санда ■

Язучы Гариф Ахуновның иҗат кыры – татар халкының тормышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге... Ул иҗат күпьяклы, киң колачлы. Шуның өчен дә Гариф Ахунов халык язучысы исеменә лаек булды.

Гариф Ахунов геройлары дигәндә, күз алдына җиң сызганып кайда гына, кем генә булып эшләмәсен, хезмәтеннән тәм табып, аңа яңа ямь биреп, тырышып эшләүче хезмәт кешесе килеп баса. Шунысы кыйммәт: ул образлар язучының үз образы белән тәңгәл килә иде. Минем хәтердә Гариф Ахунов һәрвакыт шөгыльдә, эшчән, актив, туры сүзле, зур абруйлы, халкыбызның олы мәхәббәтенә чын-чынлап лаеклы, мәшһүр каләм остасы булып саклана.

Минтимер Шәймиев

ГАРИФ АХУНОВ

Халык язучылары Гариф Ахунов һәм Әмирхан Еникинең Минтимер Шәймиев белән сөйләшер сүзләре күп... 1997 ел

безнең мирас №9 сентябрь 2020

Фатих малае

(Хикәя)

Гариф Ахунов

Фатихның мин күңеле йомшап, нечкәреп маташкан чагын белмим. Сугышта бергә йөрдек, ризык бетмәгәндер, туган-үскән якларга исәнсау әйләнеп кайттык. Фатих сугышка чаклы ук үз авылында тарих укытып киткән иде. Кайткач та нык кул белән шул укытучылык эшенә кереште. Бер-бер артлы дүрт малай табып биргән Нәгыймәсе белән дә ул нечкәреп маташмады: төчеләнеп сөйләшүнең, бала-чага иркәләүнең бу йортта нәрсә икәнен белмәделәр. Мәктәптә нык кул белән укыту өстенә, Фатих малайларын балта тотарга, печән чабарга, олыны олы, кечене кече дип белергә өйрәтте. Ләкин авыл кешеләрен гаҗәпләндергән ягы аның бу түгел иде. Авыл баласының крестьян эшен белмәве үзе гайре табигый бер хәл булыр иде. Юк, Фатихның Карагайлы авылы кешеләрен гаҗәпкә калдырган һәм легенда булып телгә кергән яклары бүтән иде.

Иртән кояш урманнар артыннан баш калкытуга, Фатих малайларын урамга җыеп алып чыга, үтә бер җитдилек белән команда биреп, капка төбенә тезә һәм трусиктан килеш кенә авыл буйлап йөгертеп алып кайта.

– Пәтихнекеләр сабан туена чыкты! – ди халык һәм шуннан башлап көтү куарга, кырга чыгарга вакыт җиткәнне чамалап ала.

Бөтен авылны бер итеп йөгерешеп кайткач, малайлар яшел чирәм каплаган ишегалдына кереп тулалар. Тәгәрмәч булып тәгәри, кулдан ясалган таганда атына, ахылдый-ахылдый салкын кое суы белән юына башлыйлар. Монысы җәй көнендә. Кышларын исә тәннәрен кып-кызыл булып кызарганчы кар белән уалар.

Фатих малайларының берсен дә солдат хезмәте иттермичә югары уку йортларына кертмәде. Үзенә күрә фәлсәфәсе дә бар иде укытучы Фатихның: «Солдат хезмәте кешене сүтеп, өр-яңа баштан җыя», – ди иде ул.

Олы малае диңгез флотына эләгеп, Балтыйк буйларында хезмәт итеп кайтты. Елына ике мәртәбә бик төгәл рәвештә аның командирыннан Фатих Хафиз улы Хикмәтовка атап язылган рәхмәт хатлары килеп торды. Аннары олы малай үзе кайтып төште. Ярка кебек булып үскән, арка-җилкә калынайган, бескозырка белән диңгезчеләр формасы киеп җибәргән егет әтисен чытырдатып бер кочаклады, әнисенә сыенып торды, алып кайткан бүләкләрен энеләренә өләште. Бөтен гаиләләре белән җыелып, өстәл янында хәл-әхвәл сораштылар, олы малайның «яңадан сүтелеп җыелу» хөрмәтенә әтисе белән диңгезче егет берәр йөз граммны тоттылар да яңадан үз эшләренә керештеләр.

...Әти кеше, портфелен күтәреп, мәктәпкә, балалар укытырга китте, олы улы Рәхим, каеш тимерләрен ут кебек ялтыратып, диңгезче формасын салмыйча, Уфага юл тотты. Җәй буе шунда ятып, медицина институтына имтихан тотты. Әти-әнисенә бернинди мәшәкать тудырмады, ай саен өйләреннән бик төгәл килеп торган егерме сум янына стипендиясен кушып, азмыйча-тузмыйча яшәп, институтны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлады да, Уфада төпләнеп, педиатр булып эшли башлады.

Икенче малае Шамил, пехотага эләгеп, армиядә хезмәт итте. Аның да

командирларыннан рәхмәт хатлары килеп торды. Педагог Фатихның сәер гадәтләреннән көлгән авыл халкы нык куллы таләпчән атаны башкаларга үрнәк итеп сөйли башлады. Әнә бит ул тәрбия дигәнең нишләтә! Шамил белән дә солдаттан кайту хөрмәтенә бер мәртәбә табын корып алдылар. Аннары Шамил Казан университетына физматка барып керде – математикадан бик башлы егет булып чыкты. Укуын бетергәч, аеруча сәләтле санап, аны Новосибирскига эшкә җибәрделәр.

Урамга көн саен «Сабан туена» чыгучылар хәзер икәү генә калды.

Фатихның үзенең дә гаилә тәрбиясе кими төшкәндәй булып, ул җәйге ял вакытларын юл йөреп, төрле сәяхәтләрдә үткәрергә гадәтләнеп китте. Бәләкәй йомры гәүдәсен, туп кебек тәгәрәтеп, әле Әгерҗегә, әле Пәнҗәргә, әле Ижауга барып чыга, малайларын да үзе белән алып бара, мәктәп балаларын да үз янына кушып, гражданнар сугышы батыры Азин узган юллардан йөри, искереп беткән кәгазьләр, сәмруг кош мөһере сугылган документлар табып алып кайта, җыйнап кына әйткәндә, – ул үз мәктәпләрендә Туган як музеен ачарга җыена иде.

Ләкин аңа бу елларда бер борчу да өстәлде. Өченче малае Рубин солдат хезмәтенә эләгә алмады. Кул-аяк, буй-сын бик тигез килсә дә, малайның күзе зәгыйфьрәк, ул күзлек киеп йөри, фантастик китаплар укырга бик һәвәс булганлыктан, төннәр буе китапка капланып утырганга, унынчыны бетергәндә, аның күзе тагын да зәгыйфьләнә төшкән иде. Рубин үзе дә, әтисе дә солдатка эләгә алмауны авыр кичерделәр. Бигрәк тә әтисе борчылды. Ул хәрби комиссар белән дә, врачлар белән дә сөйләшеп карады. Аның хәлен аңладылар, әмма ярдәм итә алмадылар. «Солдат хезмәте солдат хезмәте инде, анда сау-сәламәт кешеләр кирәк, армиянең ныклыгы өчен барыбыз да бердәй жаваплы», – дип, әти кешене тынычландырырга тырыштылар.

Рубинның күңелендә очучы булу хыялы яши иде. Ләкин әти кеше белә: пехотага да ярамагач, хәзерге заман самолетларына Рубинны якын да җибәрмәячәкләр. Улына кабат-кабат күңел ярасы ясамас өчен, әти кеше моның хәстәрен алдан ук күреп куярга булды. Казанга барып, химия-технология институты галимнәре белән сөйләште, дөресрәге, күңелендәге төенен бушатырга дип килде. Химия кебек кызыклы өлкәгә эләксә, аның улы Рубин, бәлки, очучы булу хыялларын да оныта алыр. Яшьтәшем вә кордашым Фатих туп-туры минем квартирага килгән иде. Мин аңа институтка барып йөрмәскә киңәш иттем. Ул барды. Галимнәрне үз күзе белән күреп, аларның сүзен үз колагы белән ишетмичә торып, мин әйткәннәргә генә ышанмады. Гаять дәрәҗәдә намуслы кеше булганлыктан, ул, әлбәттә, улының күзендә зәгыйфьлек барын әйтмичә калдыра алмый иде. Әти кешене, хәлենә кереп, тыңлаганнар, тик менә бу химия дигән мең төрле тәҗрибәгә бәйле кислоталар, төтеннәр, агулы исләр белән эш итәчәк кешене бик зур сынаулар көтәчәген әйткәннәр. Шуларны миңа кайтып сөйләп, ул бик күңелсезләнеп утырган иде...

– Йә, нишлим? – диде ул, озак кына дәшми утыргач.

– Улыңның үз иркенә куй, – дидем мин.

Ул чактагы сөйләшүдән соң ике елдан артык вакыт узып китте. Мин көтмәгәндә Фатих кордашымның улы һәлак булу хакында хәбәр алдым. Мин тетрәнеп киттем, башыма югарыдан бер кирпеч китереп бәргәндәй, аңымны җуеп тордым. Миңа шундук кордашым янында булырга, аны кулымнан килгән кадәрле юатырга кирәк иде. Шундук җыенып юлга чыктым.

Көз иде. Шаулап яфрак коелган чак иде. Поезд тәрәзәсеннән мин, җил очырган сары яфракларны, ша-

рәләнә башлаган агачларны карап, күңелсез уйларыма бирелеп бардым. Кордашымның Карагайлы авылында, аның югары очында, урман буенда ук, алты почмаклап салынган дәү иске йортын, ишегалдындагы таң калырдай тәртипне күз алдыма китердем. Шушы йортка килеп керүемне, әти кеше белән күрешү, кайгы уртаклашу минутларын күңелемнән кичердем...

Бүрәнәләре җил-яңгырдан каралган, йөзлекләренең буявы уңудан тәрәзәләре ничектер тоныкланып калган, күптәнге йорт мине бу юлы боегып каршы алды. Фатихның капка-кура бикләү гадәте юклыгын белгәнгә, туптуры кече капкадан ишегалдына уздым. Хуҗаны очрату нияте белән тирә-ягыма күз төшереп алдым. Монда мин башка елларда кайтканда очрата торган ныклы тәртип бетә башлаган – киселгән утын агачлары ишегалдын тутырып чәчелеп ята, әлерәк кенә бакчадан алып кереп киптерергә салган бәрәңге келәт буенда өелеп тора, өй буендагы ялгыз ак каен шыбырдап яфрак коя иде.

Шунда лапастан иске генә спорт костюмы кигән, чәче тузгып чуалган берәү килеп чыкты да, кулын каш өстенә куеп, төбәлеп карагач, ашыгып миңа таба килә башлады. Тәбәнәк йомры гәүдәсеннән, бер кулын селтәп, икенчесен янтыгына кысып килүеннән мин кордашым Фатихны танып алдым. Ул бик нык бирешкән, күз төпләренә мул булып җыерчыклар кунган иде.

Күрешкән чакта кулымны, салкынча учында тотып, байтак вакыт җибәрмичә торды. Кайгысын ишеткән булуымны күзләремнән үк күрде бугай, ул хакта сүз кузгатмыйча, ничектер күтәренке, ясалмарак тавыш белән:

– Ай, кайтып бик тә шәп иттең бит әле син, Һашим! – диде дә, бәләкәй чемоданымны кулымнан алып, өйгә таба атлады. Биек күтәрмәле чоланга узган чакта: – Бик тә кирәк әле син миңа, – дип тә әйтеп куйды.

Өйгә кердек. Чемоданымны кая куярга белмичә, бер генә мәл икеләнеп алгач, үрелеп, борынгы зур китап шкафы өстенә куйды. Өстәл өсте тулып яткан кәгазьләргә, стена буйларында өем-өем рәтсез тезелгән китапларга, тәрәзә төбендәге көл савыты тулы папирос төпчекләренә күз төшереп:

– Рәт китте әле, кордаш. Нәгыймә мәктәп балалары белән яшелчәгә йөри. Үзем менә һич кенә дә җитешә алмыйм. Гаеп итә күрмә, яме, – дип, гафу үтенгән сыман өтәләнеп, бер урындыкны, гарәп хәрефләре белән басылган китаплардан бушатып, минем алдыма китереп куйды. Калганын ул сүзсез генә эшләде. Кар базына төшеп, сөзмә алып менде, чоланнан юан корсаклы бер «баллон» тозлы кыяр алып керде. Ипи турады, чәй кайнатты. Бакчасыннан, җиңе белән сөртә-сөртә, куш йодрык чаклы ике алма өзеп алып керде, кием шкафы артыннан бер чикүшкә табып чыгарды. Шешәнең яртысы бушаган, өстен тузан каплаган иде. Шундук чамалап алдым: гаять зур кайгысы да аны шешә белән дуслаштыра алмаган икән.

Стакан төбенә генә салып, авыз чайкаган булдык.

Кыяр чәйнәштереп беркавым сүзсез утыргач, йөрәк түреннән күтәрелгән авыр бер көрсенү белән әйтте:

– Менә шулай булып китте әле, Һашим кордаш...

Мин дә ирексездән көрсенеп куйдым.

Аннары ул, сораганны көтмичә, сөйли башлады:

– Үтә дә уңган бала иде шул. Мәктәптә алдынгы булып укыды. Җәмәгать эшләренә һич карусыз катнашыр иде. Тиле үзенекен мактар, ди, мактап әйтүем түгел, үзәкләрем өзелгәнгә әйтәм. Язулары язу гына идеме?! Инша язса: «Әти, укып кара әле, рәт чыкмады бугай моннан», – дип, иң әүвәл миңа китергән булыр иде. Күңелләрем аның әнә шул

ышануыннан бер еллык сөенеч таба торган иде, кордаш... Характерымны беләсең, мактау ишетмәде миннән балалар. Инде менә хәзер, ник бер генә мәртәбә булса да мактамадым икән дип үкенәм. Очучы булам дип ашкынды. И ашкынып та карады соң! Ничәмәничә тапкырлар шул хакта минем алда сүз кузгатты. «Улым, син инде ул хакта баш ватма, сине алмаслар», – ди торган идем. Алмадылар. Алай да басылмады күңеле. Мин катырак орынсам, оныт инде син аларны, дисәм, әйтер иде: «Әти, – дияр иде, – җирдә генә яшәп үлү үлү түгел бит ул, йолдызларга карап, айга карап үлсәң, менә, ичмасам, дөньяда яшәдем, дип әйтергә дә ярый», – дияр иде. Ике мәртәбә комиссиягә барды – алмадылар, алай да борынын салындырмады, юк әле, мин үземнекен итәрмен әле, диде. Татарча чыккан календарьдан «Таня ничек күзле булды?» дигән мәкаләне табып укыган, Харьковка, академик Нюренбергка хат язды. Советлар Союзы Герое очучы Софронов белән хат алышты. Күзе кимчелекле кешеләргә кидертә торган махсус күзлек була икән. Контактлы күзлек дип атала. Тырыша торгач, анысын да тапты. Ижаугa барды, бортрадистлар хәзерли торган техникумга керде, менә дигән итеп укыды, теләгемә ирешәм бит, әти, дип, хатлар язып торды. Кайтыр иде дә сөенер иде, кайтыр иде дә сөенер иде. Үзем, ниндәй коры кеше, аның сөенгәнен күреп, күңелләрем нечкәрер иде, җүнлегә генә булса ярар иде бу сөенечләр дип тә уйлап куя торган идем. Тырышканын тапты улым, техникумын тәмамлап, документын алып кайтып күрсәтте. Үзебезнең Ятчә белән Ижау арасында оча торган бәләкәй самолетларга бортрадист итеп куйдылар.

«Өченче улым да мөстәкыйль булып чыкты. Тәки үз дигәненә иреште бит», – дип нәтиҗә ясадым, горурландым улым белән. Икәүдән-икәү генә сөйләшеп утырдык. Миңа бер генә үтенечен әйтте: «Әти, – диде, – үз көнемне үзем күрә башлаганчы, миңа бәләкәй генә бер матай алып бирерсең инде, яме, мин буш вакытларымда сезнең янга кайтып йөрермен», – диде. Үзең беләсең, балалар, кирәкмәгәнне сорап, минем теңкәмә тимәделәр. Сизәм: бу юлы Рубин кирәккә сорый. Ак та димәдем, күк тә димәдем, алып бирермен, дип вәгъдә бирмәдем. Вәгъдә бирер идем, күзе зәгыйфь, алай-болай берәр нәрсәгә бәрелеп харап булмагае дип шикләндем...

Кордашым байтак вакыт тын утырды. Үкенеченнән нишләргә белмәгәндәй, тамырлары бүртеп торган кара нык кулын өстәлгә җәйгән клеенкага суккалап алды. Шуннан соң тагын сөйләп китте:

– ...Самолетта очарга беренче көн баруы иде. Ялт иттереп ботинкаларын чистартты, кулмәген үтүкләде. Петлицаларын бик пөхтәләп такты. Канатлы кош билгесе бар бит аларның. Киез итек ки, улым, дидем, кимәде. Бәйләп кулына гына алды. Ятчәдә бик якын бер танышым бар иде, укытучы кеше, бик тә миһербанлы, фатирга шуларга кер, балам, дидем. Аэропорт башлыгы Дмитрий Фомичка хат язып бирдем, улымны фатирга урнаштырырга ярдәм итүен үтендем. Аны-моны әйтмәде Рубин, хатны кесәсенә салып куйды. Баргач, начальнигына әйткән, әти Сезгә дип бер хат бирде, әйдәгез, без аны ертып ташлыйк, фатирга мин үзем урнашырмын, дигән. Миңа бит инде унтугыз яшь, тулы хокуклы гражданин бит мин, дигән. Актыктан начальнигы шулай дип сөйләде. Улым, чыннан да, үзе фатир тапкан, үзе урнашкан. Ятчәдән Ижауга очып барып кайткан, начальнигына кереп рапорт биргән, кичкырын сөенечен минем белән уртаклашырга дип юлга чыккан. Без аны шул ук көнне кайтыр дип башыбызга да китермәдек...

…Иртәгәсен Су буе Фәхри әби керде.

– Фатих улым, – ди, – тау өстендә бер малай өшеп үлгән, барып карыйк әле, – ди.

– Юк, бара алмыйм, Фәхрисаттәй, хәзер дәрескә керәсем бар, зинһар, гаеп итә күрмә, яме, – дидем.

Фәхри әби китәргә ашыкмый, нәрсәдер әйтергә тели, әйтеп тә бирә алмыйча интегә.

– Син, Фатих улым… туктале, алай кырт кистереп кенә әйтмәле… Синең бит, теге ни… авылда булган төрле-төрле хәлләрне кәгазьгә язып бара торган гадәтең бар… – дип, һич кенә дә янымнан китми.

– Үпкәләмә, Фәхрисаттәй, үлгәннәрне сугышта да күп күрдем, бигайбә, баралмыйм, – дидем.

– Безнең авылныкы дип әйтеп әйтәләр аны күрүчеләр. Әйдәле, дәресең-сабагың качмас, барып карыйк әле… – ди.

Шуннан соң да бит әле, Һашим кордаш, башыма килми, минем улым түгел микән дип уйлап та бакмыйм. Ни булса ул, олы кешенең сүзен аяк астына салу килешмәс, дип, Фәхри әбигә ияреп киттем.

Кар өстендә, яңа яуган ап-ак кар өстендә кап-кара булып ята бу. Күрүем булды, йөрәгем бер генә мәртәбә сулкылдап куйды да тораташ булып каттым да калдым. Ни сүз әйтә алмыйм, ни кузгала алмыйм… Гөлләр кебек сулып ята балакаем… Авылга җитәргә кырык-илле метрлар гына кала туңып үлгән…

– Ничек, бер дә күрмәде микәнни соң?

– Күзлеген югалткан ул. Кайтып җитәрәк буран чыккан. Шушы тирәдә, үзебезнең тау башында адашып йөргән-йөргән дә, салам эскертенә юлыгып, утырып торган. Тагын киткән кузгалып, тагын утырган… Арыгандыр, хәле калмагандыр… Суыктан мираж күренә, диләр бит. Йолдызларны күрде микән? Чалкан ятып үлгән… – диде кордашым Фатих, үз гомерендә беренче мәртәбә мин аның күзенә яшь килеп тыгылганын күрдем.

Ир-атны юату мөмкин түгел. Дәшмәдем. Бик озак сүзсез утырдык.

Капка шыгырдап ачылды.

Көчәнә-көчәнә мотоцикл этеп, ундүрт яшьләр тирәсендәге ак каскалы, күзлекле, терсәгенә кадәр җиткән кара перчаткалы үсмер малай капкадан керә башлады. Мотоциклына ниндидер арба таккан, арбада ак таштан юнып ясалган, башына йолдыз куйган һәйкәл – кабер ташы ята иде.

Кордашым Фатих ашыгып урыныннан торды, ашыгып күз яшьләрен сөртте.

– Төпчегем кайтты. Булышыйм әле.

Мин, тәрәзә буена басып, аларның аталы-уллы мотоциклны ишегалдына алып керүләрен карап тордым. Күңелемдә берьюлы ике уй кузгалды:

«Рубинга алып бирә алмаган мотоциклны кече улына алган икән».

«Һәйкәлне сугышта үлгәннәргә куйган кебек итеп – йолдызлап ясаганнар».

Бераздан Фатих өйгә керде.

– Рөстәмем һәйкәлне алып кайткан. Рубин каберенә куябыз. Бик тә вакытлы кайттың әле син, Һашим кордаш. Син бит рәссам кеше, безгә язуын язарга булышырсың…

Өстәл тартмасыннан бер язу алып килеп бирде.

«Фатих малае

Рубин Хикмәтов

1950-1969», –

дип язылган иде анда.

Язуның гадәти булмавына игътибар иттем. Нигә «Фатих улы» дигәне юк? Ләкин шундук күңелемнән килештем. Авыл халкы, балаларының кылган гамәленә әтисен дә катнаштырып, Фатих малае, дип сөйли бит. Мөгаен, шулай дөрестер.

1969 ■

Тукай һәм шагыйрь Сирин

Әнвәр Шәрипов, филология фәннәре докторы

Баулыдагы волонтерлар үткәргән акция: Сирин Батыршин каберен тәртипкә китерү. 2019 елның 1 мае
Ксения Мудюкова фотосурәте

Габдулла Тукай иҗаты әле үзе исән чагында ук киң популярлык ала, аның әсәрләре татарлар яшәгән барлык төбәкләргә тарала. Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы Ютазы төбәгенең Кәрәкәшле авылында дөньяга килгән Сирин дә, балачагында ук Тукай турында ишетеп, аның әсәрләрен укып үсә. Һәм шул вакыттан алып Тукай образы, Тукай иҗаты Сиринне бөтен тормыш юлы буена озата бара. Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыган чакта (1910-1914 нче еллар) ул үзенең беренче иҗади тәҗрибәләрен ясый. Шунда ук, Тукай әсәрләреннән өйрәнеп, классик шигъриятнең газәл, касыйдә, мәснәви кебек жанрларын үзләштерә. Ә беразсоңрак, Бөгелмәдәге укытучылар һәм тәрбиячеләр әзерли торган семинариядә укыган чакта (1918-1921 нче еллар), Сирин, Тукай иҗатыннан үрнәк алып, үзенең берничә шигырен ул иҗат иткән темаларга багышлый. Сириннең 1920-1930 нчы еллардагы әсәрләре белән Тукай әсәрләре арасында типологик параллельләр үткәрергә мөмкин.

Биредә шуңа игътибар итәргә кирәк: Сирин яшь ягыннан Тукайдан ун яшькә кечерәк, ул 1896 елда туган. Тукай белән Сириннең тормыш юллары һәм иҗат юнәлешләре арасында беркадәр охшашлык та, зур гына аерма да бар. Охшашлык – алар икесе дә мәдрәсә белеме алганнар, иҗатларында Көнчыгыш классик поэзиясе йогынтысын кичергәннәр (Сирин ул йогынтыны беренче чиратта Тукай әсәрләре аша алган). Аерма шунда – алар икесе ике төрле җәмгыятьтә яшиләр, икесе ике төрле идеология вәкиле: Тукайның гомере 1917 елгы революциягә кадәрге шартларда уза; ә Сирин, гомеренең 21 елын революциягә кадәр яшәгән булса да, бөтенләй икенче идеология йогынтысында тәрбияләнгән кеше, ул – совет чоры шагыйре.

Сирин баштарак, бөтен күңеле белән, революциядән соң яңа, гаделсезлекләр булмаган, бәхетле тормыш төзибез дип шулкадәр тирән ышана ки, үзенең әсәрләрендә еш кына патша чорын – ач-ялангачлар тормышы, ә совет чорын бәхетле, якты тормыш итеп сурәтли. Шушы караш Сириннең Тукайга ияреп яки Тукай әсәрләренә җавап рәвешендә язган шигырьләрендә дә ачык чагыла.

«Сирин баштарак, бөтен күңеле белән, революциядән соң яңа, гаделсезлекләр булмаган, бәхетле тормыш төзибез дип шулкадәр тирән ышана ки, үзенең әсәрләрендә еш кына патша чорын – ач-ялангачлар тормышы, ә совет чорын бәхетле, якты тормыш итеп сурәтли.

Тукайның «Эштән чыгарылган татар кызына» (1909) белән Сириннең гражданнар сугышы чорында иҗат ителгән «Авыл кызына» (1920) әсәре арасында да охшашлыклар бар: ике әсәр дә яшь татар кызының елавына багышланган; икесендә дә «мәюсь», «залим», «күңел» кебек уртак сүзләр кулланыла. Әмма Тукайда «залим» булып татар бае саналса, Сириндә «залим» дип иске тормыш күз алдында тотыла. Тукайда татар кызының чарасызлыгы сурәтләнә, ә Сирин исә гражданнар сугышына киткән егетен сагынып елаучы кызны: *«Күп тә үтмәс, менә кайтып җитәр / Җан сөеклең көләч йөз белән»; «Менә киләчәгең нинди матур, / Рәхәтләнеп гомер итәрсең»*, – дип юата. Аны киләчәкнең якты булачагына өметләндерә.

Үзенең «Диңгезгә» шигырен (1920) дә Сирин Тукайның «Даһигә» (1913) әсәренә нигезләнеп иҗат иткән. Ике әсәр дә идеал темасына багышланган, икесе дә мәснәви формасында язылган. Бу әсәрләрнең иҗат ителүләре арасында нибары 7 ел вакыт үткән. Тукай үз әсәрендә милли азатлык хәрәкәте турында уйлана һәм газиз халкын колониаль изүдән коткару, аны иҗтимагый-мәдәни яңарышка алып чыгу юлларын эзләгән даһи образын иҗат итә. Тукай яшәгән җәмгыятьтә алда ялтыраган нәрсә ут түгел, ә алтын (ягъни байлык) икән һәм ул «нәрсәдә» нур да, күңел өчен җылылык та юк икән; җәмгыятьнең нигезендә алтынга, байлыкка омтылу ята икән.

«Ялтырау күрдеңме артта? Ут түгел ул – алтын ул;
Юк мөкаддәс нур да анда, юк җылылык – салкын ул», – ди Тукай.

Һәм Тукай әлеге даһины үзе бара торган юлдан тайпылмаска, үз идеалына барганда туктап калмаска чакыра:

«Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табла табылса – Алла ул».

Сириннең «Диңгездә» шигырендә исә идеал булып яңа тормыш өчен көрәштә бернәрсә алдында да туктап калмый торган, диңгез дулкын-упкыннарына да буйсынмас, көчле, ашкын, бунтарь образы калкып чыга. Сириннең лирик образы, диңгезгә эндәшеп, болай ди:

«Ниндәй дулкыннарга атсаң да, барыбер батмамын!
Һәм үлеп, суың төбендә дә череп ятмамын!
Миндә көч, гайрәт вә дәрт бар, күкрәгемдә ут яна,
Мин күрәмен алда – анда ялтыраган ут, әнә!
Ул шулай күзгә күренә, ут түгел, юк, нур бит ул!
Пакь вә саф, ап-ак күңелле бер фәрештә нур бит ул!
Тарта яшь, дәртле күңелне үз янына, алга ул,
Киң колачлап мин йөзәм, шунда минемчөн Алла ул!»

Димәк, алда күренгән нәрсә ул нур икән; ул күңелне үзенә тартып, кызыктырып тора; ә бу нур, – Сирин фикеренчә, совет җәмгыятенең якты киләчәге.

Шунысы кызыклы: Тукайның «Булмаса» газәленә (1908) ияреп, Сирин дә «Булмаса» дигән шигырь (1920) язган (әмма газәл формасын сайламаган, ә ирекле рифмалар кулланган). Ике шигырь дә 15х15 үлчәме белән иҗат ителгән. Тукай үз әсәрендә шагыйрь күңелен дәртләндереп торучы былбылга (гүзәл затка, гүзәллек шаһына) мәдхия җырлый:

«Кем белер кадреңне, җаным, дәртле күңел булмаса?
Наз итәр кемнәргә гөл – каршында былбыл булмаса?
...Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа;
Ул болай бер кыз гына – каршында Мәҗнүн булмаса».

Ә Сирин үз шигырен иҗтимагый темага багышлый: «коммунист» дип аталган кешенең совет җәмгыятендә зур дәрәҗәсе, җаваплы вазыйфасы, «гали фәрештәлеге» барлыгы ассызыклана. Анда: «Әгәр ярлы халыкка, ач-ялангачларга чын күңелең белән хезмәт итәргә теләгең булмаса, син коммунист булма да», – дигән фикер үткәрелә:

«Булмаса күңелдә халыкка мәхәббәт хисләре, –
Булма коммунист, якын килмә бүтән уйлар белән.
Янмаса күкрәгеңдә ярлы халыкның уйлары, –
Ул гали фәрештәлек, басма аяк-герләр белән».

Әсәрдә 1920 нче елларда совет җәмгыятендә махсус күпертелгән сыйнфый көрәш темасы да чагылып ала: коммунист образына кулак образы каршы куела. Шигырь болай тәмамлана:

«Булмаса хезмәт уең ач-ярлыларга, – кит ерак.
Мин беләм: син – күп ятимнәр күз яшен түккән кулак».

Бу инде Сириннең шул чор җәмгыятендә актуаль булган теманы үз иҗатында күтәреп чыгуын, әлеге тема белән уйланып яшәвен күрсәтә.

1923 елда, Тукайның үлеменә ун ел тулу уңае белән, Сирин «Безнең яшьләр (Тукайның «Яшьләр»енә ияреп, җавап урынында)» дигән шигырен иҗат итә (шигырь «Татарстан» газетасының 1923 елның 15 апрелендәге якшәмбе санында беренче биттә басылган). Бу әсәрне шагыйрь, Тукай кебек үк, касыйдә жанрында язган. Тукай әсәре дә, Сириннеке дә классик касыйдә жанрына куела торган барлык таләпләргә дә җавап бирә: икесе дә – аа, ба, ва, га... тәртибендә рифмалашып килә торган икеюллыклар, ягъни бәетләр белән иҗат ителгән. Хәтта күләмнәре дә бер үк диярлек – Тукайныкы ун бәеттән торса, Сириннеке тугыз бәеттән гыйбарәт. Әмма Тукай белән Сирин шигырьләренең идея юнәлеше монда да төрлечә: әгәр Тукай әсәре 1905 елгы революциядән соңгы кара реакция елларында язылган һәм төшенкелек, киләчәккә өметсезлек мотивлары, яшьләрдә егетлек, кешелек сыйфатларының юклыгына зарлану фикерләре белән сугарылган булса, Сирин шигырендә, киресенчә: әсәр революцион романтика, авторның яңа, якты тормыш төзүгә ныклы ышанычы, барган юлдан һичкайчан тайпылмау, ахырга кадәр җиңеп барырга омтылу кебек хис-тойгылар, ниятләр белән өретелгән.

Тукай шигырендәге өметсезлек мотивларының үз сәбәпләре бар. Аның «Яшьләр» шигыре 1910 елның 15 июлендә «Ялт-йолт» журналында басылып чыга. Бу – кара реакциянең милләтләрнең үсешенә, хөр фикерлелеккә каршы көрәш алып барган чоры. 1906-1908 нче елларда чыгып килгән «Милләт», «Азат», «Өлфәт», «Әхбар», «Ватан хадиме», «Азат халык», «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы», Тукай яратып эшләгән «Әл-ислах» һәм «Яшен» кебек газета-журналлар ябыла. Илдәге вазгы-

ять үзгәрү сәбәпле, яшьләр дә милләтнең үсеше өчен көрәштән читләшә. Мондый хәлләр Тукайда да төшенкелек, киләчәккә өметсезлек тудыра. «Яшьләр» шигырендә Тукайның нәкъ әнә шундый рухи халәте чагыла да инде. Шигырьнең беренче юлларында ук Тукай болай ди:

«Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.
Кичә якты вә милли бер күңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас».

Ә Сирин исә, Коммунистлар партиясе идеяләре белән рухланып, үзенең шигырен романтик пафос, Тукай фикерләренә капма-каршы булган фикерләр белән башлап китә:

«Йөрәккә ут кабынган, мәңге сүнмәс,
Яна күкрәктә дәртләр, һич суынмас.
Көч алдык, калтырау юк юлыбызда,
Диябез яшьләр:
«Бу күкрәк мәңге туңмас!»

Шуннан соң Тукай үз чорындгы яшьләрнең, вак, көндәлек идеаллар белән рухланып, милләт проблемаларын читкә ташлап, акча-байлыкка табынып яшәүләрен тәнкыйтьли; аларның, тәти уенчык тапкан сабый бала кебек, байлык белән мавыгуларын әйтә:

«Вә кем бар, йөз чөерми милләтеннән,
Көмеш, алтын санәмнәргә табынмас?
Тәти тапса сабый барган юлында,
Йомыш истән чыгар, һич айрылалмас.
Шулай яшьләр дә: юлда күрсә алтын,
Баюдан башкага күңлен дә салмас».

Сирин дә Тукайның фикер сөреше артыннан бара, әмма, Тукай чорындагы яшьләрдән аермалы буларак, «яңа яшьләрнең», алтын-көмешләргә табынмыйча, халыкка хезмәт итүләрен, искелекләрне җимереп, яңа тормыш төзүләрен, шул алган юлларыннан читкә тайпылмаячакларын белдерә:

«Күңелдә кайный хезмәтләр халыкка,
Чын ир алтын-көмешләргә табынмас.
Җимердек искелекләрнең барын да,
Аларга инде артык кайту булмас.
Ышандык без кызыл көчкә, юл алдык,
Турайдык сафка, нык юл, һич таелмас».

Тукайны хәтта кайбер язучы-шагыйрьләрнең дә, байлыкка алданып, акча эшләү юлына кереп китүләре борчый. Шигырен ул болай дәвам итә:

«Сатучылык итә бездә мөхәррир,
Әдип исме аңар таглыр-тагылмас».

Ул үз чорындагы яшьләр күңеленә егетлек, олпатлык, кешелеклелек сыйфатлары салынмаганлыкка зарлана, яшьләрнең үзләренең тарихтагы шанлы-данлы, фидакяр бабалары эшчәнлекләренә лаек булган эш-хезмәтләр майтара алмаганлыкларына, көчсез булуларына әрни:

«Яралганмы бу яшьләр күңле әллә
Мөрәүвәт маддәсе яглыр-ягылмас?
Ышанабыз халык көчсезлегенә,
Бабайлар шөһрәтен сагныр-сагынмас».

Ә Сирин Тукайга **«яңа яшьләр» –** һәрберсенең күңеленә иман нуры тулган, ярлы илне бәхетле итү өчен көн-төн эшли торган яшьләр образын китереп куя:

«Иман күкрәктә һәммәбездә тулган,
Табылмас, безгә көчсезләр тагылмас.
Көрәштә без ныгыйбыз көн дә, көн дә,
Эшлибез ярлы ил бәхте юлында,
Кылыч, балта, чүкеч кулдан салынмас».

Күренә ки, Сирин монда өчьюллыкны файдалана, шуның исәбенә бер икеюллыкны кыскартып, шигырьне бары тугыз бәеттән генә төзи.

Тукай үзенең шигырен «Милләт байрагын тотып юлга чыксак та, ерак китә алмадык, егылдык» дигән фикер белән тәмамлый:

«Тотып милләт ливасын, юлга чыктык,
«Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас».
Җыгылдык без, ике-өч чакрым да китми, –
Җегетләр! Бездә көч юк, – ахры, булмас!»

Тукайга җавабында Сирин, үзләренең милләт байрагы түгел, ә интернациональ эчтәлектәге кызыл байрак тотып юлга чыгуларын һәм үзләренең соң-ахыргача барырга ният кылуларын каршы куя. Яшьләрнең нык, көчле икәнлекләрен күрсәтү өчен, кулларын «тимер куллар» дип атый:

«Яңа дөнья төзибез, һәркем эшләр,
Тимер кулларга шәйтаннар сарылмас.
Кызыл байрак тотып без юлга чыктык,
Барырбыз соңгача, һичкем абынмас».

«Безнең яшьләр» шигыре, әлбәттә, 1923 елда әле Сириннең чын күңелдән яңа, гадел җәмгыять төзибез дип ышанып яшәгән чагын, ягъни аның иҗат юлының башлангыч чорын характерлый торган әсәр икәнлеген күрсәтеп тора. Аны көч-энергиясе ташып торган 27 яшьлек Сириннең 24 яшьлек Тукай белән әңгәмәсе дип тә кабул итәргә мөмкин.

Сирин, татар совет шагыйрьләреннән беренче буларак, үз иҗатында җәмгыять һәм шагыйрь, шагыйрьнең җәмгыятьтәге урыны, роле, яңа совет җәмгыятендә шагыйрьлек миссиясе проблемаларын күтәреп чыга. Шунысы кызык: шагыйрьлек миссиясен аңлауда да Сириннең карашы Тукай карашына аваздаш. «Йөрәк каны белән» шигырендә Сирин үзенең поэтик иҗатын болай сурәтли:

«Бу – минем
уйларым,
Бу – ритм.
Бу – минем
йөрәгем тибүе.
Бу – минем
канымның
тәнемнән
Җыр булып
кәгазьгә
күчүе».

Төзелеп килә торган җәмгыятьтә шагыйрьнең миссиясен ачыграк күзаллау өчен, ул үз-үзенә шундый сорау бирә: *«Ни өчен, ни өчен мин болай / Ак кәгазь өстендә кан коям? / Каләмнән тамдырып канымны / Үземне вакытсыз ник суям?»* Шушы сорауга бәйләп, ул үзенең төп фикерен әйтә: шагыйрьнең тормыштагы вазыйфасы

авторның шәхси мәнфәгате, эгоистлыгы, дан-шөһрәткә омтылуына бәйле түгел. *«Шөһрәт кирәкме? – Кирәкми / Мин үлгәч, шөһрәт нәрсәгә?»* – ди. Сирин үз алдына куйган сорауга үзе үк: *«Киләчәк тормышны күрәсе һәм шунда яшисе килә»*, – дип җавап бирә. Ә киләчәк тормышны автор матур итеп күзаллый: *«Киләчәк елларның тормышы / Уемда бик матур корылган. / Шул елларның нигез ташына / Безнең еллар өеп куелган»*. Әмма ул матур киләчәкне кул кушырып утырып кына яки елмаеп, эшләр-эшләмәс йөреп кенә якынайтып булмый. Шагыйрь кәеф-сафа корып, бизәнеп, үз-үзеңә сокланып кына, эшсез утыруга каршы чыга: *«Ни булыр иде соң / мин, Сирин, / Гөлсирин булып, гел бизәнсәм? / Яз саен яшәреп, / Таң саен зәп-зәңгәр чәчкәдә утырсам?»* – ди ул. Һәм автор, якты киләчәкне тизрәк җиткерү өчен, үзенең шигърияте, ялкынлы сүзе белән көрәшәчәген, хәтта шушы юлда үзен корбан итәргә дә әзер торуын белдерә:

«Юк,
каным жәл түгел,
коелсын чәчкәм дә,
Каләмнән тамдырып
канымны,
кәгазьгә чәчәм дә,
Җыр итеп
тезәм мин.
Беләм мин:
корбансыз
җиңү юк,
Авырлык күрмичә,
рәхәтләр күрү юк».

Күренә ки, Сирин шагыйрьнең тормыштагы миссиясен поэтик югарылыкка күтәреп тасвирлый: үзен шагыйрь дип исәпләгән иҗат кешесенең бары тик янып, халыкның кайгы-шатлыкларын үз йөрәге аша үткәреп кенә, «йөрәк каны белән» генә язарга тиешлеген белдерә. Тукай да шундый ук карашта. Ул да, билгеле булганча, шагыйрьлек вазыйфасын бик югары бәяләде: ул үзенең иҗатын шәхси мәнфәгатенә түгел, ә халыкка хезмәт итүгә багышларга тиеш. *«Әйдә, халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә; Бу юлда һәртөрле хурлыкка, зорлыкларга түзмәккә!»* дигән чакыру ташлады. Ул, үз чорының вазгыятеннән чыгып, шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси ролен «йоклаган» татар халкын уятуда, тергезү-терелтүдә күрде. Тукай бу мәсьәләдә үз чиратында рус классиклары А.С.Пушкин белән М.Ю.Лермонтовка таянды, алардан үрнәк алды. *«Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам / Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам»*, – дип язды ул үзенең «Бер татар шагыйренең сүзләре» шигырендә (1907). Монда шундый типологик параллельлек тә үткәреп була: 1826 елда – Пушкин, 1841 елда исә Лермонтов «Пәйгамбәр» («Пророк») дигән әсәр яза һәм шагыйрьнең җәмгыятьтәге миссиясен пәйгамбәрлек миссиясе дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлый. Тукай да «Пәйгамбәр (Лермонтовтан үзгәртелгән)» (1909) шигырендә шагыйрьнең миссиясен пәйгамбәр миссиясе югарылыгында күрә һәм Сирин әсәрендәге фикергә охшаш фикер әйтә – шагыйрь үз халкы өчен армый-талмый хезмәт итәргә тиеш: *«Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә / Ашамый-эчми көндез, кич белән баш куймый мендәргә»; шагыйрь рухани ут белән янарга тиеш: «Янып рухани ут берлә, ашыккан хәлдә юл тотсам»,* – ди шул ук «Пәйгамбәр» шигырендә. Рус галиме И.Г.Пехтелев язуынча, Тукайның бу фикерләре үзенең остазлары Пушкин һәм Лермонтов фикерләренә аваздаш («Тукай и русская литература». – Казань,

«

Бер үк фикердәге Пушкин – Лермонтов – Тукай – Сирин дигән чылбыр барлыкка килә һәм Сирин бу чылбырда ахыргы бер буын ролен үти.

1966. – С.106). Шулай итеп, Сириннең фикерләре Тукай фикеренә дә, Пушкин һәм Лермонтов фикерләренә дә аваздаш булып чыга. Бер үк фикердәге Пушкин – Лермонтов – Тукай – Сирин дигән чылбыр барлыкка килә һәм Сирин бу чылбырда ахыргы бер буын ролен үти. Гомумән, Сириннең «Йөрәк каны белән» әсәре 1920-1930 нчы елларда гына түгел, ә бөтен XX гасыр татар поэзиясендә гражданлык лирикасының иң матур үрнәкләренең берсе булып санала. Әдәбият һәм сәнгатьнең җәмгыятьтәге урыны, иҗади хезмәт темалары Сириннең аннан соң иҗат иткән «Гейне фикере»(1929), «Тормыш ярына басып» (1933), «Җиңел эшләр» (1933), «Гадәт» (1958), «Минем гаскәрем» (1960) кебек әсәрләрендә дә чагылыш тапты.

Сириннең Коммунистлар партиясе идеяләренә ихлас күңелдән бирелгәнлеге, совет системасының кешеләргә яхшы, матур тормыш бирәчәгенә ышанычы бөтен гомере буена бармый. 1930-1933 нче елларда инде ул совет җәмгыятендә дә гаделсезлекләрнең күп булуына төшенә, алар белән килешә алмыйча, аларны аяусыз тәнкыйтьли, сатира утына ала башлый. Аның 1930-1935 нче еллардагы иҗаты тулаем диярлек совет җәмгыятендәге икейөзлелекне, астыртынлыкны, тискәре күренешләрне тәнкыйтьләүгә багышлана. Нәтиҗәдә, Сирин, кулга алынып, биш ел буе гаҗәеп рәхимсез, кеше ышанмаслык кыргый тәртипләр хөкем сөргән Сиблаг лагерьларында җәфа чигәргә мәҗбүр була. Әмма сөргеннән кайткач та, аның иҗатында совет җәмгыятендәге тискәре күренешләрне тәнкыйтьләү мотивы әле урыны-урыны белән үзен сиздереп ала.

1930 нчы елларда совет җәмгыятендәге гаделсезлекләрне тәнкыйтьләп язган әсәрләрендә Сирин төрле алым-формалар куллана: чит ил шагыйрьләренең тәнкыйди әсәрләрен тәрҗемә итү (мәсәлән, француз шагыйре Беранжедан ике тәрҗемә – «Аучылар», «Син бит Гөлсем түгелсең»), мәсәл формасы, хат формасы («Лермонтовтан хат», «Тумаган балалардан хат»), телеграмма («Бөтен дөньяга телеграмма») һ.б. Шулар арасында аның «Тукаевтан Сирингә телеграмма» дигән шигыре дә бар (1933 ел). Сирингә мөрәҗәгать итеп, Тукай болай ди:

«Син үзең ничек яшисең,
Бармы соң ашарыңа?
Бармы соң эшләү шартың,
Квартирың язарыңа?
Сез инде яңа тормышта, –
Без күргәнне күрергә
Туры килмәс, идән себреп,
Шигырь язып йөрергә.
Дөньяда ничек яшиләр? –
Белгәнем юк бик күптән.
Барысын ачык, дөрес итеп,
Яз әле бер хат, көтәм.
Тукаев».

Шулай итеп, Сирин, гомере буена Тукайдан өйрәнеп, үрнәк алып, күңеленнән аның белән сөйләшеп-фикерләшеп иҗат иткән. Бу, әлбәттә, Сирин иҗатына уңай йогынты ясаган. ■

безнең мирас №9 сентябрь 2020

Театр һәм тамашачы

Раил Садриев

Мин, гомумән, театрга гашыйк кешеләрнең берсе. Хәзер инде аның эчендә кайнагач, кайвакыт үткәннәргә кайтып, күзаллап утырасың.

Бүгенге форматта яшәү үзенең таләпләрен куя. Читтән карау өчен бераз вакыт кирәк. 70 нче еллардагы бер елга хәзерге биш-алты ел сыя. Гомумән, шулкадәр күп вакыйгалар, тизләнеш, үзгәреш...

«Театр һәм аның тамашачысы нинди булырга тиеш?» – дигән сорау һәм таләпләр белән яшибез. Нинди спектакльләр чыгарырга, нинди юнәлештә эшләргә кирәк?! Тамашачы белән ике арада ничек күпер төзергә? Аралашу нинди форматта булырга тиеш?

Менә шундый зур таләпләр куеп, эшкә җигелдек. Россия һәм чит ил күләмендәге төрле фестивальләргә йөри торгач, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм үзебезнең театрларның иҗаты белән даими танышып баргач, үзем өчен шундый ачышлар ясадым. XXI гасыр башындагы глобаль кризис һәм пандемия кысаларында адәм баласы депрессия халәтенә кергәндә театрлар нинди булырга, нинди юнәлештә эшләргә, нинди спектакльләр куярга, тамашачы белән ике арада нинди юл салырга тиеш?..

Э.Радзинский сүзләре белән әйткәндә, XX гасыр ахырындагы театр ул – сәяси, абстракт, эчтәлексез һәм күпчелек чорда режиссер тарафыннан тамашачы өчен аңлаешсыз формага кертелгән театр. Ул театр инде үлде, йә булмаса, үлеп бара. Аңа алмашка нәрсә киләчәк соң?! Без нинди театрга йөрергә һәм нindирәк тамашалар карарга тиеш?

Изге китапта болай диелгән: «Шундый заман килер, кешеләр төньяктан – көньякка, көнчыгыштан көнбатышка бәрелеп-сугылып йөреп эзләнәчәкләр». Кеше театрга ипи һәм су эзләп түгел, Аллаһ сүзен ишетергә, әмма аны, дин формасында булудан бигрәк, сүз рәвешендә кабул итәргә, ягъни җан азыгы эзләп килә. Икенче төрле әйткәндә, адәм баласы театрга җан азыгы булган спектакльләр карап, үзен төшенкелек халәтеннән чыгарыр өчен йөриячәк.

Тамашачы театрга кичерешләр дәрьясына чумар өчен бара. Нәрсәгәдер өметләнә кеше. Һәм... күпчелек очракта бернәрсә дә ала алмыйча кайтып китә.

Бүген бөтен мәгълүмат пандемиягә һәм безне киләчәктә сагалап торучы зур глобаль кризиска корылган. Шулай булгач, иртәгә без көткән иң авыр нәрсә ул – депрессия, төшенкелек, алдагы көнгә өмет-ышанычны җую.

Буа театры куйган спектакльләрдән күренешләр

Әле дөнья чаршавы ачылып бетмәгән, шуңа күрә иртәгә ни буласын тулаем белеп бетерә алмыйбыз. Акыл ияләре, дөнья инде бүтән андый булмас, без яшәгән дөнья үзгәрде дигән фикердә торалар. Кешеләр якын киләчәктә зур өметсезлеккә биреләчәк, ягъни депрессиягә. Менә шул өметсезлек чорында Россиядә театрлар һәм иң мөһиме – милли театрлар тамашачы күңеленә нинди юл салачак?

Безне бүген бер генә нәрсә борчый: тамашачыны бу халәттән чыгарыр өчен, нинди спектакльләр куярга кирәк? Милләт шушындый шартларда театрын, сәнгатен, мәдәниятен, телен һәм үзен ничек саклап калырга тиеш?!.

Тютчев сүзләре белән әйтсәк, ул болай яңгырый: «Бу дөньяга аның һәлакәтле көннәрендә килеп-китүчеләр бәхетле. Аларны Ходай әңгәмәдәшче итеп җирдәге мәҗлескә чакырган».

Кешегә бүген ышаныч, аны юатырлык, аның күңелендә яшәешкә өмет уятырлык спектакльләр, тамашалар һәм гамәлләр кирәк. Театр теленә күчереп әйткәндә, тамашачы, спектакльне карап, аннан икенче төрле халәттә – үзгәреп чыгарга тиеш. Аңа, көтү-төркемнән халыкка әйләнү өчен, тетрәндергеч кичереш булу мөһим.

Театр ул – тере сәнгать, анда һәрвакыт тамашачы белән үзара элемтә, тамашачы белән артист арасында җылылык, күзгә күренми торган вибрацияләр һәм энергетика бар. Моны бернинди телевидение дә, кино да, интернет та алыштыра алмый. Каратэдагы шикелле «фулл-контакт» (тулы контакт)!

Шуңа күрә бүген сәнгатьнең, мәдәниятнең, беренче чиратта, театрларның роле тагын да арта төшә. Бүгенге театр кешегә упкыннан чыгар өчен зур терәк булырга тиеш.

Хөрмәтле милләттәшләр! Безне алда зур сынаулар, авыр кичерешләр, кризислар көтә. Ләкин шул ук вакытта кешелек дөньясы һәм аның киләчәге өчен зур мөмкинлекләр дә туачак. Театр сәнгате шушы мөмкинлекләрне ачып салучы, юл күрсәтүче, ышанычны арттыручы, кешене кеше итеп саклап калучы калкан, таяныч булырга тиеш!

Бүген кешеләр алдында торган иң зур бурыч – теләсә нинди шартларда да кеше булып калу!.. ■

безнең мирас №9 сентябрь 2020

Мәгъсум Хуҗин вафаты
(1930-2008)

Ләбиб Лерон

Мәгъсум Хуҗин «яшьтиләре» арасында: сулда уңга – Ркаил Зайдулла, Мәгъсум Хуҗин, Ләбиб Лерон, Зиннур Хөснияр, Вакыйф Нуриев, Газинур Морат, Зимфира Гыйльметдинова, Марсель Галиев

2008 елның 25 августы. Сәгать иртәнге җиделәр тирәсе. Казанның бер ел элек кенә салынган Миллениум күпере аша машинамда җилдереп кенә эшкә («Салават күпере» журналханәсендә эшләгән чагым) барып ятканда, кесә телефоным шылтырады. Мәгъсум абый Хуҗинның кече кызы Ләйсән икән:

– Бүген төнлә әти үлде бит! Үләр алдыннан аннан: «Егетләрне чакырыйммы?» – дип сораган идем, әти: «Кирәкми! Борчыма аларны», – диде...

Бер ел элек кенә ике олуг каләмдәшебезне: май аенда – Зөлфәт абыйны, шушы вакытларда, ягъни узган җәйнең соңгы көннәрендә Рәис абый Даутовны бакыйлыкка озаткан идек. Инде менә «өлкән яшьтәшебез» (без, яшьләр, аңа, яратып, «яшьти», дип әйтә идек) Мәгъсум абый да китеп барган...

Сөекле хатыны Мәгъферүз апаның үлемен бик авыр кичерде Мәгъсум абый. Бик ярата иде ул аны. Мәгъферүз апа хастаханәдә яткан чакларда: «Чукынчыклар! Апагыз сезне ярата, сезнең өчен үлеп тора бит! Әйдәгез, аның хәлен белеп кайтыйк әле!» – дип, Мәгъсум абый безне дә ияртә иде. Әлбәттә, бер өер кешене хастаханәгә уздырмыйлар инде, Мәгъсум абый, кибеттән үзе сатып алган (ризалыгым юк, дип, безгә алдырмады), без күтәрешеп килгән күчтәнәчләрне тотып, Мәгъферүз апаның хәлен үзе генә белеп чыга:

– Апагызга сез килгәнне әйттем. Күчтәнәчләрегезне тапшырдым. Бик сөенде, рәхмәт әйтте! – ди...

Мәгъферүз апаның вафатыннан соң, Мәгъсум абый: «Мин дә озак тормам инде… Әтием Хәмидулла да минем яшьтә вафат булды», – дип еш әйткәли башлады.

Бик озак еллар урын өстендә яткан шагыйрь дустыбыз Рөстәм Мингалим янына җай чыкканда Мәгъсум абый белән гел икәү бергә барып килә идек. «Сырхаулап торам әле бу арада», – дигәч, 2007 елның 15 августында Рөстәм абыйның хәл-әхвәлен белергә, аны туган көне белән котларга үзем генә бардым.

Әмма ул көнне ике дусны «күрештерү» җаен таптым бит тәки: икесен телефон аша сөйләштердем. И рәхәтләнде инде бу икәү үзара гәпләшеп! Мин дә өлкән дусларымны рәхәтләнеп тыңлыйм. Кем белгән бит аны, нәкъ ун көннән соң, көтмәгәндә-уйламаганда, Мәгъсум абыебыз Мәңгелек йортка китеп барыр дип?!.

Рөстәм абый каләмдәш дустының вафатын авыр кичерде: «Без шулай матур гына яшәгәндә, дустыбыз, зур язучы Мәгъсум Хуҗин арабыздан бөтенләйгә китеп барды, – диде ул. – Бик күңелсез итте дөньябызны. Миңа аеруча күңелсез. Өемдә телефон шылтыраган саен, дертләп китәм. Ул шылтыратыр кебек:

– Абзый, хәлең ничек? Дусларың киләме? – дияр шикелле.

– Юк шул хәзер Казанда синең кебек дустым, Мәгъсум абзый! – диясем килә.

Аның инде бу дөньяда юклыгына ышанырга теләми генә бит күңелем…»

Әйе, Мәгъсум абый үлемен барыбыз да – Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Марсель Галиев кебек олпат каләмдәшләр дә, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Госман Гомәр, Радик Фәизов, Рәфыйк Шәрәфиев, Сәйдә Зыялы, Ризван Хәмид, Рашат Низами кебек кайчандыр төрле елларда, төрле редакцияләрдә бергә әвәрә килгән хезмәттәш-дуслар да, Зәки Зәйнуллин, Камил Кәримов, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Фәйрүзә Мөслимова, Ләис Зөлкарнәй, Илсөяр Иксанова, Вакыйф Нуриев, Рәдиф Сәгъди, Марат Закир, Ирек Нигъмәти, Тәлгать Нәҗмиев кебек «яшьти»-шәкертләр дә авыр кичерде. *«Мәгъсум дә китеп барды… Калын кашлары астыннан, күзлек кысалары өстеннән кешеләргә сынап һәм сокланып төбәлгән карашы гына калды. Әйе, ул бервакытта да әйтәсе сүзен карашын яшереп әйтмәде. Фикерен йә сүзен күзгә туры карап, ләкин кеше хәтерен калдырмаслык итеп җиткерә иде. Шуңа күрә дә аны язучыларның олы яшьтәгеләре дә, әле борын төртеп килгәннәре дә яратты, үзенә тиң итеп күрде»*, – дип язды Туфан Миңнуллин Мәгъсум абыйның вафатыннан соң…

Әдипне соңгы юлга озатышырга Сабага байтак каләмдәшләр җыелып бардык. Бу турыда Мәгъсум абыйның якташы, дусты Тәлгат Нәҗмиев истәлегендә болай дип язган иде: *«2008 елның 26 август көнне борынгы Саба җире үзенең талантлы улы Мәгъсум Хуҗинның җәсәден кабул итте. Аны, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов җитәкчелегендә, иҗатташ дуслары озата кайткан иде. Кайчандыр үзе «Хезмәт» газетасы мөхәррире булып эшләгән Балтач районыннан да якын каләмдәшләре килде. Әдип, үзенең васыяте буенча, районыбызның Язлы Арташта туып үскән, озак еллар «Татарстан яшьләре» газетасында корректор булып эшләгән, үзеннән дүрт ел алдан бакыйлыкка күчкән җәмәгате Мәгъферүз, алтмыш яшен тутырып, нәкъ өч кенә атна яшәп калган бертуган энесе Илгиз, башка туганнары җирләнгән яңа зиратта гүргә иңдерелде. Шунда әдипнең Чабаксарда яшәүче галим энесе Васил Хәмидулла улының озатырга килүчеләргә рәхмәт әйткәннән соң: «Язмыш кушуы буенча кайчандыр чыгып киткән идек, берәм-берәм мәңгелеккә кайтабыз хәзер»*, – дигән сүзләре күңелгә аеруча уелып калды…»

Ошбу юлларның авторы Тәлгат Нәҗмиев та вафат инде. Аның кабере Мәгъсум абый һәм Мәгъферүз апаның каберләреннән әллә ни ерак түгел…

Мәгъсум Хуҗин Шигырь бәйрәмендә (вафатына дүрт ай кала). Микрофон каршында – Ләбиб Лерон. 26 апрель, 2008 ел.
Марсель Галиев фотосы

2008 елның июнендә һәм августында Уфада ике татар әдибенең китабы башкорт телендә дөнья күргән иде: аның берсе – шагыйрь Зөлфәтнең «Язмыштар ярында»сы (кереш сүз авторы – Равил Бикбаев), икенчесе – Мәгъсум Хуҗинның «Айзың уты һүнгән» җыентыгы. Мәгъсум абый үзенең әлеге китабын күреп кала алмады. Фирая апа Маликова (шагыйрь Зөлфәтнең хатыны) әлеге китапны (Зөлфәт абыйныкын да) Уфадан алып кайткан көнне Мәгъсум абый туган ягына соңгы сәфәренә кузгалган иде…

16 август, 2020 ел ■

Мәгъсум Хуҗин һәм аның хатыны Мәгъферуз Фәләхетдин кызы каберләре янында. 11 июль, 2012 ел

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Җиңүгә – 75 ел!

Ут эчендә татар кызлары...

Тәэминә Биктимирова, тарих фәннәре кандидаты

Түземлекләр җиткәч чигенә,
Сынау килгәч туган иленә,
Килеп басты Татар хатыны
Көрәш сызыгының чигенә,
Шәльяулыгын салып иңенә.
...Халык диңгезенең төбеннән,
Берәмтекләп, сөеп җыелган
Сөембикәләре милләтнең
Кан-көрәштә күпме җуелган...
Исемнәре җырга уелган.

Лена Шагыйрьҗан

Очучы Мәгүбә Сыртланова

Без – сугыш чоры балалары. Ил өстенә ишелеп төшкән олы кайгы, миллионнарның гомерен кискән, аналарны һәм балаларны ятим иткән сугыш гомер буе безнең белән янәшә бара. Аннан котыла да алмадык, алмабыз да төсле. Гомер үтеп бара инде.

Балачактан караган кинофильмнар, укыган китапларның күбесе руслар күрсәткән батырлык, тиңдәшсез каһарманнар – рус ирләре, рус кызлары хакында иде. Мәктәптә укыганда «Мин кемгә охшарга телим» дигән темага сочинение язарга булса, без, билгеле инде, Зоя Космодемьянская, Лиза Чайкина, Любовь Щевцова, Ульяна Громовалар хакында яздык. Ул кызларны һич тә гаепләргә җыенмыйм. Аларның батырлыгы күңелгә кергән, анда матур булып урнашкан. Ә менә хатын-кызның сугыш кырында хәле ничек, җайсыз, авыр хәлләрдән алар ничек чыга? Ничек иялөнә, ниләр кичерә, ничек чыдый ул? Боларын уйлый белмәгәнбез икән әле. Кулыма чорыбызның күренекле язучысы, Нобель премиясе лауреаты Светлана Алексиевичның «У войны не женское лицо» (китап исеме шулай хәтеремдә калган) дигән әсәре килеп эләкте. Бу китап миңа сугышта катнашкан кызларның бөтен фаҗигасен аңлатып бирде дә инде. Ирләргә сугышта бер читен булса, хатын-кызга мең тапкыр читенрәк икәнен белү, аңлау бөтен дөньямны әйләндереп ташлады.

Үзебезнең татар кызларының хәлләре тагын да аянычрак булганын, аларның фаҗигаләрен, кичерешләрен аңлап тетрәндем.

1958 елда «Азат хатын» журналы яңадан чыга башлады. Рәхмәт журналны чыгаручы каләм осталарына! Анда безнең татар кызлары – аларның да сугышта күрсәткән батырлыклары, тылда фронтка киткән ирләре урынына басып эшләүче аналарның сугыш шартларында балаларын ачтан үтерми саклаулары хакында язмалар бирелә башлады һәм бу мактаулы эш әле дә дәвам итә.

Телевизор караштыргаларга туры килде быел. Үзәк каналларда да, үзебезнекендә дә татар кызларының батырлыгына багышланган ник бер тапшыру булсын! Ярый әле, Аллага шөкер, сугышны кичереп, 60 елдан артык тигез тормышта яшәгән хатын-кызларыбыз бар икән. Аларга карап сөендек.

Кызлар гына түгел, тиңдәшсез батырлыклары белән дөньяга танылган егетләребез дә искә алынмады… дисәм, үзәк каналда бер таныш исем яңгырады. Рейхстагта җиңү байрагын беренчеләрдән булып кадаган (бу хакта сугышта кинооператор булып катнашкан атаклы Роман Карменның истәлекләре дә, рәсемнәре дә дөнья күргән иде) татар баласы – 19 яшьлек Григорий Булатов исеме иде ул.

Күңел әрни: безнең буын Совет хакимияте чорында үзенең газиз халкы, туган-үскән җиренең тарихы, милләтнең чишмә башы, асылы, тамырлары турында белми үсте. Үз ата-бабаларыбыз, чын Ватаныбыз, үз милләтпәрвәрләребез хакында да белмәдек без. Безнең башлар борынгы, урта гасырлар, яңа һәм иң яңа тарихлар белән тутырылды. Тарихыбызны белсәк, бүгенге наданлык та, үз халкыңа, аның үткәне һәм бүгенгесенә битарафлык та булмас иде.

Сүзем ут эчендәге татар кызлары хакында иде бит әле. Сугыш утын кичкәннәрне искә алу иде максатым.

Үз Ватаннарында үги булып яшәсәләр дә, шул илгә афәт килгәндә, гомерләре, саулыклары белән исәпләшмәгән кызларыбыз. Тормышның кайсы гына өлкәсенә карама – һәркайда каһарманлыклары белән балкып торган кызларыбыз күп. Рус әдипләре, тарихчылары татар кызларының сугыш вакытында күрсәткән батырлыкларын, хезмәткә намус эше итеп карауларын, һәр эшне көчләрен, хәтта гомерләрен кызганмый башкаруларын күрмәмешкә салыштылар. Йөрәгемне әрнеткән нәрсәләр күп…

Сугышның иң хәтәр көннәрендә Мәскәү белән Ленинград шәһәрләре күкләрен саклаган зенитчыларның күбесе татар кызлары булуы хакында ник онытылды? Белергә теләүчеләргә «Сөембикә» журналының быелгы 5 нче санын укырга киңәш итәм. Раилә Хәялиева «Татарочкалардан үрнәк алыгыз» исемле мәкаләдә зенитчы кыз хакында язган. Рәхмәт аңа!

Дөрес, мәкаләдә бәян ителгәннәр белән генә чикләнми, зенитчы кызларыбыз күп булган. Кайберләренең исемнәрен тагын искә алыйк. Мәрхүмә булсалар, рухлары шатлансын, могҗиза белән исән калсалар, үзләре шатлыктан еласын. Кайгырсак та, шатлансак та елыйбыз бит. Болар: Наилә Әхмәтҗанова, Мәрьям Кадыйрова, Фәнихә Йосыпова, Заһидә Вафина, Мөнәвәрә Насыйбуллина, Зәйтүнә Хәлиуллина, Сәйдә Мостафина, Лена Шәмсетдинова, Зөлфия Нурлыгаянова, Бикә Хәйруллина, Суфия Исхакова һәм тагын бик күпләр. Исемнәрен тәсбих тарткан кебек кабат-кабат әйтеп, рәхмәт белдерик.

Ничек шулай үзләрен башка милләт кызларына үрнәк итеп куя алдылар икән?!. Бер зенитчы кызларга гына да әйтелгән сүз, бирелгән бәһа түгел әле бу. Сугыш елларында күпме кызларыбыз торф чыгаруда эшләделәр. Торф чыгару ул вакытта, чын мәгънәсендә, икенче фронтка әйләнә, чөнки торф сугыш кораллары ясый торган заводларны, электр станцияләрен эшләтүгә, торак йортларны җылытуга китә. Эш шартларының ничек авыр булганын хәзер аңлатуы да кыен.

Безнең кызларның торфны Мәскәү, Вологда һәм Иваново өлкәләреннән алып ерак Себер җирләрендә дә чыгарганлыгы мәгълүм. Бер генә мисал китереп үтим, чөнки язмам бик озынга китә. Арча районының Иске Иябаш авылыннан Рәйсә Хәкимова белән Кәримә Фазылова өч ел буе Түбән Тагил урманнарында торф чыгаруда эшләгәннәр. «Сездән башка татар кызлары тагын бар идеме?» – дип сорагач: «И, сеңлем, нишләп булмасын, элегрәк хатлар да алышкан идек, хәзер исемнәре онытылган инде, гаепләмә», – диделәр. Гаепләмәдем, әмма бернәрсәгә әле дә җавап таба алмыйм. Түбән Тагил өлкәсендә торф чыгарырлык бүтән милләт кызлары булмадымы икәнни?!.

Владимир һәм Калинин өлкәләрендә озак еллар торф чыгарган авылдашым Хәҗирә апа Төхфәтуллина болай дип сөйләде:

– Бервакыт без торган бистәгә күрше колхоз рәисе килде. Колхозның исеме хәтеремдә калмаган, Калинин өлкәсе иде. Шул рәис (үзе чулак, фронттан кайткан булса кирәк): «Кызлар, сезнең тырышлыкны белеп, зинһарлап килдем. Быел уңыш яхшы, безгә ял көннәрендә урак урырга килмәссезме икән, игеннәр әрәм була бит», – дип чакырды безне.

Шул авылга киттек. Безнең Әтнә районы кызлары инде: Бәрәскә, Бәрәзә, ике Шимбердән. Торф нормасын тутырабыз да шимбә һәм якшәмбе көннәрендә урак урабыз. Рәис куанычыннан еламый гына. Әле эшләгән өчен ит, май, он бирделәр. Рәхәтләндек туйганчы ашап, ике-өч ел булыштык үзләренә.

– Ул авылның үз кешеләре, үз колхозчылары кайда иде? – дип сорыйм Хәҗирә ападан.

Фотосурәттә: Антонина Худякова, Александра Акимова, Мәгүбә Сыртланова, Надежда Студилина, Калерия Рыльская, Ирина Себрова, Лидия Демешова, Наталья Меклин.
Николай Игнатьев фотосы

– Үз кешеләре дә бар инде. Тик безнең хәтле эшли алмыйлар ич алар, – ди ул, бер дә исе китмичә генә. – Үзләренең яшелчә бакчаларында казыналар. Безне генә көне-төне колхоз эшенә йөртәләр иде, сеңлем!

Искитәрлек хәл. Халкымның иң гүзәл, иң матур сыйфаты – эш сөючәнлеге үзенә үк дошман булып кайта икән ләбаса! Ул – татар халкының фаҗигасе, дисәм дә, ялгышмам төсле. Кайда авыр хезмәт – шунда татар, шунда татар кызлары. Торф чыгарганда кызларның гарипләнүе, хәтта үлеп калулары да мәгълүм бит. Бу хакта безгә «Торфчы Мөнәвәрә», «Мәгъдәнә» бәетләре сөйли.

Әйе, авырлыклар килсә, татар кызларының олы намус ияләре икәнлекләрен дә, нинди гүзәл сыйфатларга ия булуларын да белүчеләр табыла. Сугышның иң хәтәр көннәрендә шушы торф чыгаруда эшләгән хатын-кызлар өчен татар телендә «Правда» исемле махсус газета чыгып килүе очраклы хәл түгел. Бу газетаны татар журналисткасы Мәрьям Дибаева берүзе чыгара. Мәскәү өлкәсендәге торфчы кызлар янына ул, 1944 елда ире Самат Дибаевның фронтта һәлак булган хәбәрен алып, кечкенә кызын әнисе тәрбиясендә калдырып китә.

Берүзе материал җыеп, мәкаләләр язган, Мәскәүгә килеп, типографиягә тапшырган, берүзе бөтен тиражны күтәреп кайтып, торфчы кызларга өләшеп тә йөргән бит Мәрьям. Аның истәлекләрен «Ил язмышын салып иңнәренә» дигән китабыма керткән идем (Кара: Ил язмышын салып иңнәренә. Казан: Алма-Лит, 2006. – 190-191 б.).

Бераз читкәрәк киттем. Әмма укучылар мине аңларлар, чөнки фронт белән тылдагы батырлыкны аерып куя алмыйм. «Кайда җиңелрәк булды?» – дигән сорауга дөрес җавап табып булмый.

Җавап таба алмаган сораулар тагын бар әле ул. Күңелемдә халкымның шушы мактаулы, эш сөюче, намуслы кызлары алдында оялумы икән, кызганумы – бер хис саклана. Ни өчен аларны бөтен СССР буйлап авыр хезмәттә тилмерттеләр

икән?! Милли сәясәтнең ачык чагылышы бит бу. Татарстанның бөтен шәһәрләрен, авылларын эвакуация белән килгәннәр тутырган. Ә Татарстан кызларын, товар вагоннарына төяп, читкә эшкә озатканнар. Авыр эштән, ачлыктан үлеп калганнар күп, әмма хисабын бүген кем белә?! Совет власте елларында Дәүләт Оборона комитеты фронт өчен дип эшләткәч, нигә аларга ташламалар, пособиеләр бирелмәде икән?.. Дөрес җавабын кем белә? Кем курыкмыйча әйтә ала?!.

Тагын фронтка әйләнеп кайтыйк. Безнең горурлыгыбыз – курку белмәс очучы Мәгүбә апа Сыртланова телевизион тапшыруда искә алынды. Рәхмәт! Ул – гади очучыдан эскадрилья командирының ярдәмчесе дәрәҗәсенә ирешкән татар кызы. Әлеге төнге бомбардировщиклар полкы хакында беләләрдер дип уйлыйм. Яшьлегебездә аларга соклана, батырлыклары белән чиксез горурлана идек. Мәгүбә апа, ялгышмасам, 1971 елда бакыйлыкка күчте дип беләм. Хушлашырга бардым, җәсәде Казанның Офицерлар йорты залына куелган иде. Педагогия институтындагы укытучыбыз Зөһрә апа Вәлиуллина миңа: «Мөселманча куябыз җир куенына, Аллага шөкер, рөхсәт бирделәр», – дип әйтеп, сөенече белән уртаклашты. Урыны җәннәттә булсын.

Әмма икенче очучы героебыз Ольга Санфирова, никтер, искә алынмады кебек. Бергә булалар бит алар. Күренекле язучыбыз Шамил Рәкыйповның «Кызлар – йолдызлар» дигән әсәрендә алар турында язылган. «Нәрсә хакында укырга белмәгәч, «Зөләйха күзләрен ача»ны укыдым», – дип сөйләде бер хатын, оялмыйча. Укысын әнә бу китапны!

Бар һәм бик күп горурланырлык татар кызлары! Фронтка үз теләге белән киткән атаклы снайпер кызлар – Зәйтүнә Габделвәлиева һәм Әлфия Рәхмәтуллиналарны онытып буламы?! Шәфкать туташларыннан снайперлар командасы төзегән Бөгелмә кызы Гөлсем Шакирҗанованы рәхмәт хисләре белән искә алыйк. 60тан артык дошманның башына җиткән кыз бу.

Шәфкать туташларыбыз –яраланган меңнәрчә солдатларны, сугыш кырыннан алып чыгып, үлемнән коткарган Мөнирә Әхтәмова, Сафура Подвигина, Суфия Хәйретдинова, Зәйтүнә Бариеваларны; медицина пунктларында һәм госпитальләрдә яралыларга күпме каннарын биреп, гомерләрен саклап калган Мәрьям Гимаева, Рая Ибраһимова, Роза Зарипова, Зәйнәп Гыйлаҗетдинова һәм иң беренчеләрдән булып «Батырлык өчен» медале алган шәфкать туташы Асия Ильматованы хөрмәт белән искә алыйк.

Үземнең якташым – Әтнә районының Түбән Көек авылы кызы – шәфкать туташы Наҗия Шакированың исемен аеруча горурлык белән атап үтәм. Һәм аның янына авылдашым Фәрзәнә апа Хисамиеваны, Түбән Көек кызлары – Хәлиуллина Майшәрәп белән Шәмсеруй Фазылҗановаларны куям. Авыл кызлары, ә нинди батырлыклар күрсәткәннәр!

Искиткеч авыр шартларда операцияләр ясап, сугышчыларны яңадан армиягә яраклы итеп сәламәтләндергән хәрби табибәләр – Вәсимә Сәйфуллина, Фатыйма Хәбибуллина, Мөнәвәрә Шәрифҗанова, Әминә Хәмзина, Рәисә Булатова, Оркыя Насыйрова һәм башкаларга олы рәхмәтебез булсын.

«

Бар һәм бик күп горурланырлык татар кызлары! Фронтка үз теләге белән киткән атаклы снайпер кызлар – Зәйтүнә Габделвәлиева һәм Әлфия Рәхмәтуллиналарны онытып буламы?!

Халыкара Кызыл Хач җәмгыятенең иң югары бүләге – Флоренс Найтингейл алтын медаленә лаек булганнар арасында татар кызы Фаина Чанышева да бар. Белеп торсыннар!

Татар кызлары елга һәм диңгез флотында да тырышып хезмәт иттеләр. Яралыларны, гаскәрләргә кирәкле азык-төлек һәм сугыш коралларын ташый алар. Араларында пароход штурманнары Фәйрүзә Галиева һәм Оркыя Курмаева да бар. Оркыяның әнисе һәм өч сеңлесе Харьков шәһәрендә дошманнар кулында калгач, ул, үч алу теләге белән, хәрби очучылар мәктәбенә китә һәм фронтта һәлак була.

«Авыл хуҗалыгында төп көчләр хатын-кызлар (1944 елда 76,8 процент) һәм яшүсмерләр булды. МТСта эшләүче механизаторларның 55 процентын хатын-кызлар тәшкил итте. Комбайнчыларның – 62, тракторчыларның 81 проценты хатын-кызлар иде.

Язганнарым күп төсле тоелса да, язасыларым тагын да күбрәк икән. Тик һәрнәрсәнең дә чиге була. Шулай да Көнбатыш фронтның махсус партизан оешмасы штабында хезмәт иткән Чистай кызы Чәчкә Заһированы (руслар исемен Рита дип йөртәләр), дошман басып алган Днепропетровск шәһәрендә подпольеда көрәшеп һәлак булган Фатыйма Гафурованы һәм быел интернетта мактаулы исеме телгә алынган тиңдәшсез разведчица Фәридә Сәлимҗановаларны искә алмый китеп булмый икән. Үзләренең курку белмәс батырлыклары белән ирләрне дә сокландырган пулеметчы кызларыбыз – Суфия Гыймаева, Маһирә Мөхәммәтшина, Нина Ризатдинова һәм Әминә Хафизовалар да һәйкәлләр куярга лаек затлар!

Тылдагылар хакында сөйләделәр, яздылар, Алла бирсә, тагын язарлар дип өметләнәм. Бары тик кайбер саннарны гына искә төшерәм. Авыл хуҗалыгында төп көчләр хатын-кызлар (1944 елда 76,8 процент) һәм яшүсмерләр булды. МТСта эшләүче механизаторларның 55 процентын хатын-кызлар тәшкил итте. Комбайнчыларның – 62, тракторчыларның 81 проценты хатын-кызлар иде. Татар кызларыннан тракторчылар Х.Сираҗиева һәм Б.Гыйззәтуллиналар (кызганыч, исемнәре язылмаган) «Советлар Союзының иң яхшы тракторчысы» дигән исемгә лаек булды.

Исемнәре күрсәтелмәгән, бер карашка әллә ни батырлык дип тә саналмаган бер төркем хатын-кызларыбызны әйтеп китәм. Аларның намуслы хезмәтләрен искә алып, исемнәрен эзләп табуны алдарак искә алган якташым Нажия апа Шакирова сораган иде. Архивлардан эзләдем, тик таба алмадым. Бу исемсез каһарманнарыбыз – кер юучы хатын-кызлар. «Сталинград янында күпме хатын-кыз яралы сугышчыларның керләрен юа, үткли иде!» – дигән иде ул. Бик кызганыч, кайсы районнан җибәрелгәннәрен дә ачыклап булмады. Әмма бу изге эштә 1942 елда гына да Татарстаннан 84 мең (!) хатын-кыз катнашкан икән.

Бу саннар артында да – кеше язмышлары. Берсе генә хакында булса да ник язылмады икән?!.

Сугыш еллары бездән торган саен ераклаша бара. Ил-көнебез тыныч булсын, бу газаплар бүтән кабатланмасын иде. Ә әлеге коточкыч авырлыкларны үткән кызларга багышланган фильмнар «Мөселман киносы» фестивалендә генә булса да күрсәтелсен иде. ■

Гариф Ахунов Арчада

Без бит Арча яклары*

Гариф Ахунов

Арчадан Балтачка бара торган олы юл өстендә, апрельнең азаккы атнасында, без, машинада узып барышлый, телеграм баганасы төбенә чүмәшкән берничә кешене күреп алдык.

Арча районында әле бер җирдә дә чәчүгә чыкмаганнар, болар монда нишләп йөриләр икән дигән кызыксынуга бирелеп, яннарына туктадык. Миннән бигрәк, минем белән юлга чыккан радио корреспонденты Наил Гыйззәтуллин һәм якташым Мөхәммәт Мәһдиев бу хәл белән кызыксындылар.

Төштек. Карыйбыз. Минем сабакташ Мирбат Хәстиев, мин белмәгән тагын ике егет телеграм баганалары тирәли бодай чәчәләр – кул белән чәчәләр. Өсләрендә телогрейка, юл кожаны. Битләрен кояш ашаган, җил кискән. Кырык бишләр тирәсендәге ир уртасы кешеләр, үзләре чибәр, олыгайган кешеләрне көнләштерерлек таза, саусәламәт.

Мине күрүгә, Мирбат Хәстиев, «Известия» колхозы председателе, бите-башы белән елмаеп, каршыга атлады, җилән чабулары кош канаты кебек җилпенеп киттеләр.

– И-и-и, Гарифҗан абый, сине нинди җилләр ташлады монда?!

– Менә шулай, председатель иптәш, сабакташ, якташ, туган җирләрне карап кайтырга булдым әле. Багана төбендә нәрсә сихерлисез сез?

– Син инде партия съездында булган кеше, Гарифҗан абый, беләсең, сыйфат бишьеллыгы бит. Багана төпләре буш калмасын дип, алданрак, чәчүгә кузгалганчы, аяк киенебрәк кую иде. Чәчү узганнан соң онытыла, Тукай әйтмешли, татар башы кеби такыр кала бу җирләр, – диде Мирбат, өстә күренеп калган ике-өч бөртек бодайны күн итек башы белән күмеп куйды.

– Алай икән, алай икән, – дидем мин, – сине, әйбәт председатель, дип, җирне ярата дип, булсынга йөри, дип бик мактыйлар иде, димәк, зерәгә түгел мактаулары…

Мирбат кызарды, уңайсызланып елмайды. Күзен кояштан ышыклый төшеп:

– Чыннан да, нинди йомыш белән килеп чыктыгыз әле? Бу иптәшне кем дип белик? – диде.

– Монысы – радио корреспонденты Наил Гыйззәтуллин, монысын беләсең инде, Казанбашта укыткан педагог, язучы Мәһдиев. Язгы басуларны карап, саф һава сулап кайтырга дип чыктык. Йә, сөйлә, нинди яңалыклар, нинди искелекләр дигәндәй, нәрсәләр белән сөендерә аласың безне? Культура сарае салмадыңмы әле?

– Фундаментын салырга җыенабыз.

> **«Мине күрүгә, Мирбат Хәстиев, «Известия» колхозы председателе, бите-башы белән елмаеп, каршыга атлады, җилән чабулары кош канаты кебек җилпенеп киттеләр.**

* Гариф Ахуновның шул исемдәге очеркыннан өзек.

Бәдри Хәстиев Казанбаш авылы балаларына белем бирә

– Озак, туганнар, озак. Казанбаш бит колхоз оешкан елларны клублы булу ягыннан барлык авыллардан алда иде. Әтиең Бәдри абзыйлар, коммунист Заһидуллиннар эшне бит клубтан башлаганнар иде. Менә дигән таш клуб иде бит авылда. Шул заманнардан да артта калып барабызмыни инде?

– Агач материалы да, кирпече дә, ташы да бар, чын осталары юк. Төзүче һөнәре бик кадерлегә әйләнде бит хәзер.

– Шулайдыр анысы, ләкин Казанбашны, театр труппалары беренче булып килә торган авылны, кайчандыр кантон булган Казанбашны клубсыз итеп күрү сәер.

– Аңладым инде, аңладым, маңгайга чиртеп әйтмәсәгез дә... – дип, ул кинәт «син»нән «сез»гә күчте. Шуның белән мин сүзне очлап куярга мәҗбүр булдым:

– Ярый, аңлагач, әйбәт. Радио корреспондентына берәр сүз әйтәсеңме?

– Әйтермен, кирәге булса...

Корреспондент, чәчүче егетләрне һәм мине арба янына чакырып, җилне ышыклап торырга кушты, үзе, магнитофонын рәтләп, җиргә чүгәләгән председатель янына иелде.

– Чәчүгә кайчан чыгасыз? – диде корреспондент.

– Тагын биш көннән.

– Менә шул хакта, чәчүгә әзерләнү хакында сөйләсәгез иде.

Мирбат сөйли башлады. Мин кинәт авызымны ачып, шаккатып калдым. Әле генә уңайсыз елмаеп, кызарынып торган председателебез радио дикторларыннан да болайрак сөйли, тамчы, бөртек тә уңайсызланмый, тотлыкмый, сөйләвен игенчеләрнең, механизаторларның исемнәре белән беркетеп бара иде.

– ...Кояшлы булды 26 апрель көне. Күңел күтәрерлек булды. Механизатор Фәлән Фәләновлар, көнлек нормаларын бер йөз дә илле процентка үтәп, чәчүне югары сыйфатлы итеп башкардылар...

Корреспондент магнитофонын шып туктатты.

– Туктагыз әле, ә сез ул көнне кемнең чәчүгә чыгасын һәм күпме эшләячәген каян беләсез? Мин бит сезнең язгы чәчүгә әзерлек турында сөйләвегезне генә үтендем, иптәш Хәстиев...

Председательнең бу юлы уңайсызлану хәбәрендә дә юк иде, ул, аксыл кашларын югары чөеп, күзен дә йоммастан:

Минтимер Шәймиев «Известия» колхозы эшчәнлеге белән таныша.
Сулдан өченче – Социалистик Хезмәт Герое Мирбат Хәстиев. Казанбаш авылы. 1990 нчы еллар

– Әгәр мин чәчүгә кайсы механизаторым чыгасын, аның күпме норма үтисен биш көн алдан белмәсәм, минем председатель булып йөрүемнең бәһасе Арча базары көнне сукыр бер тиен. Бусы – бер. Икенчедән, корреспондент иптәш, фамилиягез кем әле, әһә, Гыйззәтуллинмы, сезнең халыкны беләм бит мин, ничәмә-ничә мәртәбә язып алганнары бар, әй әтәләнәләр, әй кабаланалар, перәме ут чыккандай кыланалар, ә бактың исә, ашыгыч дип язып алган материалны бер атнадан, хәтта ун көннән соң бирәләр. Мин сөйләгәнне Сез чәчү башланган көннән дә алдарак бирмисез бит. Шуңа күрә мин Сезгә чәчү көнен сөйлим дә…

Без рәхәтләнеп көлдек. Менә әйтте бу, әйтеп карады!

Эшләр шуннан соң тизрәк китте. Сөйләтәсе сүзебезне сөйләтеп, өйгә кайтырга чыккач, радио корреспонденты, миңа терсәге белән төртеп:

– Ай-яй усалланды авылда халык, авызыңны ачып торсаң, төкереп китәргә дә күп сорамас, ха-ха-ха! – дип, тагын бер мәртәбә көлеп куйды.

– Тормыш дигәнең менә шул инде ул, бүген монда килмәгән булсак, председатель Хәстиевнең андый үткенлеген каян белер идек әле без, – дидем.

– Гариф абый, син бит аның белән авылдаш дип таныштың, сабакташ та дидең, бергә укыган идегез мәллә?

– Анысы сиңа ник кирәк? Әллә күңелеңдә бөре уяна башладымы? Минем якташ ошап куйды мәллә үзеңә?

– Ошамаслык түгел бит! Төп башына утыртып куя язды бит үзебезне! Радио өчен җилле генә бер очерк язып булмасмы дип торам әле мин аның турында. Чәчү чәчкән чагына килеп чыксам… урак өстенә… Колхозчыларына булган мөнәсәбәтен чамалый башладым инде. Озак эшлиме ул председатель булып?

– Егерме елдан артыктыр инде.

– Әти-әниләре дә игенчеләрме? Механизаторлар ук түгелдер бит?

– Юк, механизатор түгел. Калыпка сугарга азапланма син бар нәрсәне. Әтисе дә, әнисе дә укытучылар иде аның. Әнисе – география укытучысы, әтисе – әдәбият. Өстәвенә, ул әле хәзерге заман укытучылары кебек педагогика эшенә «туп-турыдан туп пашул» булып килеп кергән кеше дә түгел. Заманында хәлфә булган кеше. Революциядән соң совет мәктәбендә балалар укытырга керешкән һәм шул эшнең

остасы булып киткән кеше. Әгәр син кайчан да булса Бәдри Хәстиевтә әдәбият сабагы алган берәр кешене очрата алсаң, ул ниндирәк кеше, ниндирәк укытучы иде дип сорасаң, алар сиңа аның кем икәнен аермачык әйтеп бирерләр. Дөнья бәясе кеше иде. Әдәбият турында сөйли башласа, авызларны ачып, дөньяларны онытып тыңлар идек. Казанбашта ул колхозлар оештырышты, балалар укытты, урта мәктәпнең директоры булып эшләде. Әнисе дә бик ягымлы, бик сабыр кеше аның. Ирле-хатынлы ике укытучы икесе дә Казанбашның күз өстендәге кашы кебек кешеләр, менә дигән бакчачылар иде. Казанбашта Бәдри абыйны сагынып сөйләмәгән бер генә кешене дә таба алмассың.

– Әтиләре – укытучы, ә бу ничек игенче булып киткән?

– Хикмәт шунда да шул, әти-әнисе аңа җирнең кадерен белү кебек аңны бик матурлап сеңдергәннәр. Әтисе исән чагында ук председатель булып эшли башлаган иде инде ул. Өч ел чамасы авыл советы председателе булып та эшләде. Шул ук Казанбашта. Шул чагында председательлектән аерылып торды, әмма җирдән беркайчан да аерылмады.

– Ә колхозчылар белән мөнәсәбәте, эш стиле ничегрәк аның? – дип, иплэп кенә сорап куйды радио корреспонденты.

– Карале, Наил, зерә хәйләкәр кеше булып чыктың бит әле син, малай. Әкрен-әкрен хәйләсене китерәдер көйгә бу, дигән шикелле, син Хәстиев турындагы очеркыңны аның янына бармыйча гына язарга уйладың, ахрысы, әкәмәт.

– Һөҗүмгә күчәр алдыннан разведка дигән хикмәтләре дә бар бит. Син аны яхшы беләсең. Үземә кирәк, димәсәң, берәр генә детален булса да әҗәткә биреп тор, үзе янына барып өйрәнгәч, очерк итеп кайтарып бирермен.

– Шулай дисәң генә инде. Әйбәт очерк язам, дисәң генә. Алайса белеп тор: Мирбат Хәстиевнең колхозчылар, механизаторлар белән эшләве тирән педагогик алымнарга, психологиягә корылган. Бүген син аны багана төбенә бодай сибәргә юкка чыккан дисең мәллә? Чыгар сиңа, бар! Эше аның муеннан. Әмма бүгенге эше, шәхси үрнәге чәчү беткәнче җитәчәк. Сыйфатның нинди икәнен үзе башлап күрсәтте, диячәкләр. Шуның өстәвенә, син үз вакытында, Хәстиев әйткәнчә, нәкъ көнендә ул сөйләгәннәрне республикага тапшырсаң, Хәстиев ул синең җаныңда нәрсә ятканны бер атна алдан күрә, диячәкләр. Белдеңме?

– Анысын мин үзем дә күрдем. Мин күрмәгәне…

– Син күрмәгәнеме? Син күрмәгәне шул: бервакыт колхозда ике егет матур гына салып йөри башлыйлар. Эшкә уңган, сәләтле егетләр, чүп-чураман түгел. Бик эче поша мондый хәлгә Хәстиевнең. Ничек туктатырга? Турыдан-туры үгетләсәң, андыйны авыл халкы бик өнәп бетермәүчән. Нишләргә? Тәки бер җае чыга моның. Көннәрдән-беркөнне әлеге ике егетнең ашыгыч йомыш белән колхоз идарәсенә килүен әйтәләр. «Эчкәннәрме?» – ди председатель. Ул өендә утыра әле. «Юк, – диләр, – икесе дә апаек». «Яхшы, әйтегез үзләренә, хәзер килеп җитәм», – ди председатель, ә үзе идарәгә барырга бер дә ашыкмый. Тагын киләләр моңа. «Хәзер, хәзер, – ди председатель, – менә райкомга бирәсе ашыгыч отчетымны гына язып бетерим». Тагын бер сәгать килми бу, вакытны суза бирә, суза бирә. Ниһаять, егетләр көтә-көтә хәлдән тайгач, идарәгә килеп керә.

– Көттегезме, егетләр?

– Көттек, – диләр тегеләр, яшермичә.

– Кыенмы көтүләре?

– Бик кыен.

– Нишләп килми торды, дисезме?

Мирбат Хәстиевне 70 яшьлек юбилее белән котларга Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев тә килде. Казанбаш авылы

– Шулай дибез шул. Бик аккуратный кеше ие председателебез, ни булды икән дип баш ватабыз.

– Әйтимме ни икәнен? Беркемгә дә әйтмисезме?

– Әйтмибез.

– Чынмы?

– Ант итеп әйтәбез, үзара калыр.

– Алайса әйтәм: кичтән эчкән идем мин.

– Пиво эчкән идегезме?

– Эчсәм аракы гына эчәм мин.

Егетләр, уңайсызланып, идәнгә карыйлар, тамак кыргалыйлар.

– Көтүләре кыенмы? – дип кабат сорый Хәстиев.

– Бик кыен, – диләр егетләр, эшләрнең кай якка барганын абайлап.

– Миңа да бик кыен була, мин сезне кайчакларда көннәр буе көтәм, ләкин көтеп бетерә алмыйм...

Бу диалог шул көнне үк, сәгате-минуты белән, халык арасына тарала, кабатланып сөйләнә торгач, арта-күперә һәм әлеге ике егетне шешәдән биздерер хәлгә китереп җиткерә. Чөнки алар халык телендә көлке объектына әйләнәләр. Ул гына да түгел, вакытсыз эчкәннәргә карата халык: «Көтүләре кыенмы?» – дип, ике генә сүз әйтә, бу шундук көлү өянәге кузгатып, салмыш адәмнәрнең йөрәк-бәгыренә төшеп җитә...

– Болай булгач барам, бармый калмыйм, кызыклы характер бу, – диде Наил, мавыгып.

– Бара күр, теге егетләр кебек озак көттерә торган булсаң, үзем язып куярмын, – дидем мин, елмаеп.

Машинадан төшеп, кипшергән кара кырлар янына туктадык. Күкрәкләрне киңәйтеп, җанга яз һавасы тула, дымлы туфрак исе, узган елгы үләннәр исе, кайдадыр эскерт калдыгын яндырганнан калган салам исе аңкый иде... ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Мөхәммәт Мәһдиев турында истәлекләрем

Шәһидә Максудова

Мөхәммәт Мәһдиев хатыны Лилия һәм кызы Гәүһәр белән

Мөхәммәтләр Галиевләр урамындагы фатирларына 1968 елны килеп урнашкан икән. Без дә Новаторлар урамындагы фатирыбызга шул ук елның августында Әлмәттән кайтып төпләндек. Әнә шул вакыттан бирле безнең балалар бер мәктәпкә йөрде, Наилә белән Гәүһәр классташлар иде, бер почта бүлегенә, бер үк саклык кассасына, бер аптекага, бер азык-төлек кибетенә йөрдек, шактый еллар талонга ала идек бит әле ризыкны, шул сәбәпле очрашулар, сөйләшүләр гел булып тора иде.

Гомәр абый белән Кәримә апа да Новаторлар урамына килеп урнашты бит әле – Лилия белән Мөхәммәтнең кулында зур-зур икешәр сумка булыр иде. Озын буйлы кешеләрдә ул авыр сумкалар алай ямьсез күренмәс иде. Без, Гарифҗан белән мин, мәзәгрәк күренгәнбездер инде, сумкалар үзебездән әз генә бәләкәй булгандыр. Әле поездда да очраша торган идек, дөресрәге, Новаторлар тукталышында. Алар – Васильево янындагы дачаларына, без 774 нче километрдагы дачабызга барырга чыксак, бер вагонга утырыр идек тә, Мөхәммәт белән Гарифҗан юл буе сөйләшеп барырлар иде. Без дә балалар турында, ирләребез турында, тагын әллә ниләр, әллә ниләр турында сөйләшер-көлешер идек. Ихлас күңелле, туры сүзле Лилияне беренче күрүдән үк яраттым, әле дә бик якын күрәм, авыр хәсрәте минем дә йөрәгемне телгәли…

Очрашуларны санап китүе шуңа, димәк, 1968 елдан башлап Мөхәммәтнең авырып киткән көннәренә чаклы тормыш-көнкүреш, иҗат бергә-бергә үткән диясем килә. Мөхәммәт Мәһдиевнең әсәрләрен дә китап булып басылып чыгуга укып бардым, хисемне, фикерләремне телефон аша да, очрашкан чакларда да әйтә идем, ул исә минем белән гәпкә кермичә генә тыңлап торыр иде дә, рәхмәт, рәхмәт, кенә дияр иде.

Шәһидә (Гөлшәһидә) Максудова-Ахунова (1926-2009) – язучы, тәрҗемәче, ТР Язучылар берлеге әгъзасы. «Минем кала алуым», «Асылбикәне җирләгәндә» һ.б. повестьлар авторы. Гариф Ахуновның хатыны. Игътибарыгызга авторның язучы Мөхәммәт Мәһдиев вафатыннан соң язылган истәлегеген тәкъдим итәбез. Мәкаләнең кульязмасы Шәһидә һәм Гариф Ахуновларның кызы Наилә Ахуновадан алынды.

Безгә кергән чакларда китап киштәләрен карарга ярата иде ул. Кем китабының кайсы киштәгә куелганын барлап, шуңа нәтиҗә чыгаргандыр инде, мөгаен. Гарифҗанга язып биргән китаплары татар язучыларының китаплары белән янәшә – Әмирхан абый Еники китаплары артыннан ук анықылар тезелеп китә иде. 1980 елда басылып чыккан «Ут чәчәге» китабына: *«Гарифҗан! Бу китап гел безнең яшьлек еллары, гел безнең тормыш китабы. Моны дөньяга чыгарганчы, син бу китап турында байтак җылы сүз әйткән кеше бит. Ихтирам белән, М.М. 4.1.81»,* – дип язган.

...Беркөнне шулай Мөхәммәтләргә кердек. Кердек дип әйтүем шуңа, без инде әйләнгеч юлдан түгел, чокыр аркылы чыгып, туп-туры Галиев урамына киләбез, биш-ун минутлык юл. Чәйләп-мәйләп, дөньябызны онытып утыра торгач, төннең үтеп киткәнен, вакытның таңга авышканын да сизми калганбыз. Шунда Мөхәммәт үз башыннан узганнарны китап итеп яза башлавын сөйләп утырган, язганнарыннан бер бүлек тә укыган иде. Анда заочникларның, диплом яклаганнан соң, Казансу елгасы өстендә, күпер төбендәге ресторанда мәҗлес оештырулары турында язылган. Ул мәҗлестә Гарифҗан белән мин дә булган идем, безне Мөсәгыйть Хәбибуллин чакырган иде. Башыннан узганнарны ул «Ачы тәҗрибә» исемле китап итеп язып чыгарды. Хәер, аның күп әсәренең төп герое ул үзе бит...

Җәйге төн үтеп, таң беленә башлады. Без китәргә дип кузгалдык. Чыгып киткән чакта Мөхәммәт безгә поши мөгезен бүләк итеп тоттырды. «Бу менә Гөберчәк янын-

Язучы Вазыйх Исхаков гаиләсе белән. Гариф Ахунов хатыны Шәһидә Максудова һәм кызы Наилә белән. Әлмәт, 1965 ел

дагы урман пошыеның мөгезе булыр, сезнең аны башка урында күрәчәгегез юк, бу мөгез безнең йортта гына булыр!» – диде. Зур, әллә ничә тармаклы мөгезне күтәреп, бу юлы инде турыдан чокыр аша түгел, Галиев урамы белән Себер трактына чыгып, аннан үзебезнең Новаторлар урамына кереп бара идек, каршыбызга әзмәвердәй ике егет килеп чыкты. Алар бик тә күтәренке күңел белән ниндидер мәҗлестән кайталар иде бугай, икесе дә кызмача иде, безгә бәйләнә башладылар. Тарткалашу куркыныч төс алды. Нишләргә дә белми аптырагач, мин боларга:

– Ни кылануыгыз бу, егетләр, без бит ирле-хатынлы, без әнә теге йортта гына яшибез, кирәк дисәгез, без сезне сыйлый да алабыз… – дидем. Шунда берсе, озынрак буйлысы:

– Ну вас, фәлән-фәсмәтән, блины! – диде дә, Гарифҗанның кулыннан мөгезне йолкып алып китеп тә барды, икенчесе аның артыннан иярде. Без инде көләргә дә, еларга да белмәгән хәлдә өйгә элдердек. Әгәр Мөхәммәт безгә мөгез бирмәгән булса, яки без: «Үзебездә дә бар, улыбыз Рәшит Әгерҗе урманы пошыеның мөгезен алып кайтты, шундый ук зур, авыр, берне түгел, икене», – дип, алмаган булсак, нәрсә белән бетәр иде мондый очрашу?!. Тәпәләгән булырлар иде шул. Алай гына булса әле…

Икенче көнне Гарифҗан якташы Мөхәммәткә хәлләрне сөйләп бирде телефоннан. Янәсе Гөберчәк урманы пошыеның мөгезе безне бәладән коткарып калды. Көлештек. Ә иң яхшысы – вакытында кайтып китү. Рәхмәт әйтеп.

Шулаен ул шулай да, җәйге төн бик кыска шул, сөйләшә башлагач, сүз бетми. Мөхәммәт кебек теленә шайтан төкергән язучыны тыңлавы дөнья рәхәте, бәхетнең дә бәхете бит ул…

Шуларны уйлыйм да аһлар орам, бигрәк иртә китте, бахыр, җитмеш бишкә тикле яшәгән булса да, таулар актара иде әле, Ходай Тәгалә биргән таланты ун кешегә җитәрлек иде аның.

Аның хакында сөйлиселәрем күп минем. Агачлар, үләннәр, йорт хайваннары белән сөйләшүен, аларның серен-сихерен белүен, насыйп булса, күп итеп язармын. ■

Мөхәммәт Мәһдиев хатыны Лилия белән. Ялта. Октябрь, 1963 ел

«Хат язар идем сезгә...»

Сугыштан тынган арада,
Каләмне манып карага,
Хат язар идем сезгә...

Муса Җәлил, 1942

Ниязи Кыям улы Бигашев (1912-1943)

Дәһшәтле сугыш еллары ачы тамга салмаган гаилә юктыр бу дөньяда... Һәркем, үз йөрәге аша узган авырлыкларны искә алып, үзенең гаилә геройларын барлый. Үсеп баручы буынга тарихны өйрәнү шәхси мисалларда күрсәтелгәндә, күпкә отышлырак килеп чыга. Безнең әле бүгенге көндә шул вакыйгаларның шаһите булган өлкән буын вәкилләре белән аралашу бәхетебез бар. Сугыш елы балалары буларак, алар безнең белән хәтерләгән истәлекләрен, онытылмаслык хисләрен чын күңелдән рәхәтләнеп уртаклашалар. Фронттагы сугышчылар белән күзгә-күз карап сөйләшә алмасак та, аларның якын кешеләренә язылган хатлары аша хис-кичерешләрен, шатлык-хыялларын, кайгы-борчуларын бүлешә алабыз. Хатлар аркылы аларга якынаябыз, алар белән аралашабыз кебек. Һәрбер сугышчының язмышы, су тамчылары кебек җыелып, Бөтендөнья океаны булып кушыладыр сыман.

«Орден алдым. Партиягә кердем. Илне саклауда яхшы уңышлар күрсәттем. Әгәр дә исән-сау кайтырга туры килсә, бик зур кеше булырмын, Җиһан!»

Сугыш елы хатирәләренә фронттан килгән хатлар шаһит. Әлеге чор баласы булган дәү әниебез Рәйсә Ниязи кызы Бигашева-Кәрамова әтисенең фронттан килгән хатларын без, киләчәк буын өчен, кадерләп саклаган. Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан, без дә үз өлешебезне кертергә уйладык: булган хатларны җыйнап, бер өлешен журнал укучыларына да тапшырырга булдык.

Безнең дәү әтиебез – Ниязи Кыям улы (Кивамович) Бигашев. Әнисе Наҗия – Иж-Бубый мәдрәсәсе мөгаллимәсе Мөхлисә Бубый тәрбияләп үстергән ятим бала, үз гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган шәхес, педагог. Әтисе Кыям – Мордыбый авылында мөгаллим, Иж-Бубый мөгаллимнәре белән берлектә, аларның ярдәме белән укыту эшләрен алып барган. Үзләренең дүрт балаларын да белемгә омтылучан итеп үстерәләр: Ниязи, Өлфәт, Әнәс, Әнисә. Иң олы уллары Ниязи 1912 елның 4 декабрендә Әгерҗе районының Мордыбый авылында туган. Ниязи 1928 елда Лубян урманчылык техникумына укырга керә, 1931 елда аны тәмамлый – лесовод-техник квалификациясен алып чыга. Сугыш башланганчы, үз һөнәре буенча эшли, гаилә кора, балалар үстерә. Урманчы (лесничий) булып эшләгән җиреннән, 1942 елда Зәй районы военкоматыннан, үз теләге белән Бөек Ватан сугышына китә. Гаиләсенә хатлары еш килеп тора. Язылган хатларында туганнарына, якыннарына фронт яңалыкларын җиткерә: *«Партияга кергәнне элекке хатымда язган идем. Дошманны бик нык кудык. Яхшы сугышкан өчен Сталин, приказ язып, безгә благодарность җибәрде, аннан соң төрле бүләкләр килде».* Гаиләсе, газиз хатыны һәм балаларына, кайгыртучанлык күрсәтеп, хуҗалык эшләрендә үзенең киңәшләрен бирә: *«Маллар күп икән, кәҗәне күп калдыргансың, бер кәҗә җиткән. Җәй көне үзең аптырарсың ул кәҗәләр белән».*

«Мин хәзер кече командир. Һаман да минометчик. Орден алдым. Партиягә кердем. Илне саклауда яхшы уңышлар күрсәттем. Әгәр дә исән-сау кайтырга туры килсә, бик зур кеше булырмын, Җиһан!».

Ниязи Бигашевның сугыштагы батырлыгын командирлары язган характеристикалар да раслый: *«20.02.1943 в районе Ново-Александровском тов. Бигашев, будучи наводчиком миномета, ведя боевой огонь, отразил вместе с двумя другими расчетами три атаки противника, уничтожив при этом только из своего миномета свыше 40 автоматчиков противника, рассеяно и уничтожено до роты пехоты противника, уничтожено 2 пулеметных точки и одна рация. Израсходовав все боеприпасы и получив приказ на отход, тов. Бигашев вынес с поля боя, рискуя своей жизнью, под шквальным огнем противника раненого командира расчета т. Гельфенбейна и нес его на себе по снегу 8 км. За весь период полевых действий роты тов. Бигашев являлся одним из самых дисциплинированных, хладнокровных и смелых бойцов».*

«Бигашев Ниязи Киямович, красноармеец, наводчик миномета 13 гвардейской танковой бригады, награжден медалью «За отвагу» №224942 приказом 13 гвардейской танковой бригады № 08/н от 11.04.1943 г., Награда вручена, временное удостоверение №497355».

Табылган документлар буенча, Ниязи Кыям улы Бигашев 1943 елның 18 августында Украинаның Харьков өлкәсендәге Ахтыр районында – Курск дугасында батырларча һәлак була. Кызганыч ки, герой кабереның урыны билгеле түгел.

Ниязи гаиләсе белән

05.09.1942

Кадерле Җиһаным һәм балаларым!

Барыгызны да бик сагынып, күп сәламнәр җибәреп калам. Мин сезгә 30 нчы августта Глухово шәһәреннән бер хат язган идем. 31 нче августта аннан чыгып киттек. Син акча җибәргән булсаң, кире кайтыр. Сугышка кермәдем әле. 50-60 чакрым чамасы артта ятабыз. Бер җирдә урман эчендә торабыз, сахрадагы кошлар белән бергә гомер итәбез. Үзем һаман минометчик, ефрейтор. Ашаулар начар, бик ябыктым. Күрсәгез, таный да алмассыз инде. Шушы көннәрдә сугышның эченә кертмәкче булалар. Нәрсә булып калыр инде. Комиссияләр еш була, һәрвакыт, таза, дип чыгаралар. Сездән бер хат та ала алмадым, хәлегезне белмим. Бу урында адрес юк, хат язмый тор. Мин хат яза алмасам, Заинский военкоматына хәбәр итәрләр, шуннан белешеп тор. Конюх карт белән карчыкка, Юныска, Антиповка, Нюрага, Нафиговка, Мифтаховка, Илһамга һәм башка мине сораганнарга сәлам әйт. Бабай килдеме? (Бабай – каенатасы, Ниязиның олы кызы Рәйсә сугыш елларында әби-бабай карамагында, Кукмара районының Төркәш авылында кала. – ***К.Г.****). Әнкәй хат язамы? (Әнкәй – Наҗия Бигашева, Мөхлисә Бубыйның кызы. –* ***К.Г.****) Хушыгыз.*

Ниязи. Исән булсак, бер күрешербез әле.

30.01.1943

Кадерле Җиһаным һәм акыллы кызларым!

Барыгызга да гвардия Кызыл Армия сәламе җибәреп калам. Үзем бик исән-сау. Фронттан бераз арттарак бер авылда ял итеп ятабыз. Ял бик кыска булды. Бүген иртәгә тагын фронтка чыгып китәбез. Синең Яңа ел бәйрәме көнне язган хатыңны бүген алып укыдым һәм бик сөендем. Аннан соң бүген бабайдан бер хат алдым. Ул хатны синнән кайткач язган. Шулай, Җиһан, беренче сугышта чыдадым. Алдагы сугышларда ничек була инде. Сезне бик сагынам. Ашаулар яхшы, үзем хәзер бик тазардым. Партияга кергәнне элекке хатымда язган идем. Дошманны бик нык кудык. Яхшы сугышкан өчен Сталин, приказ язып, безгә благодарность җибәрде, аннан соң төрле бүләкләр килде. Исән булсам, Җиһан, җәйгә кайтырга өметләнеп торам. Син, Төркәшкә кайтмасаң, берәр колхозда я лесхозда эшлә. Олыҗыга, Кызыл юлга йә Байракка күч. Тортсалар, гел тора торган өйдә тор әле. Районда булгач, сиңа зыян юк.

Маллар күп икән, кәҗәне күп калдыргансың, бер кәҗә җиткән. Җәй көне үзең аптырарсың ул кәҗәләр белән. Алар, бәрәнләгәч, бер көтү булалар. Лучше сарыкларны берәр баш артык калдырасың калган. Ярый инде. Заданиесы булса, шунда бер кәҗәне бирерсең.

Кызларым мине сагыналардыр. Мин аларны бик сагынам. Алар сиңа эшләшә торганнардыр инде дип уйлыйм. Җиһан, син минем бар хатларымны да аласың микән? Минем хатларны көт тә, үзең дә хат язып тор. Хатың бик сирәк килә. Адрес шулай: 2483 полевая почта, часть 84, Бигашеву Ниязи Киямовичу. Хат яз.

Ниязи.

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

08.03.1943

Кадерле Җиһаным!

Сиңа һәм акыллы кызларым Римма белән Рашидәгә бик күп сәламнәр җибәреп калам (Олы кызы Рәйсәнең хәлен бабай белән хат алышып белешеп торган. – ***К.Г.)****. Җиһан, мин сиңа бер айдан артык инде хат яза алмадым, монда күп сәбәпләр булды. Бик каты канлы сугышларда булдым, вакыт булмады. Почта да артта калган иде. Менә хәзер ялга чыгабыз, бер җиргә җыелдык.*


ЛУБЯНСКИЙ ЛЕСОТЕХНИЧЕСКИЙ ТЕХНИКУМ

„25“ Июня 1931 г.

№ 1063

П/о. Лубяны Тат. Респ.

Пролетарии всех стран, соединяйтесь!

Р. С. Ф. С. Р.

Автоном. Татарская Соц. Сов. Республика

Союзлеспром ВСНХ. СССР.

Свидетельство

Выдано настоящее свидетельство гр-ну Бигашеву Ниазию Киямовичу родившемуся в 1912 году 4 Декабря месяца в том что поступив в 1928 году в Лубянский Лесотехнический Техникум окончил его „25“ Июня 1931 года С лесо-хозяйственным уклоном отделению.

Гр-ну Бигашеву Н. К. присваивается квалификация лесовода-техника

Гр-н Бигашев Н. К. во время пребывания в Техникуме пользовался стипендией в течении 3х лет.

М. П.

Зав. Техникумом / Tixnikum mədire:

Секретарь / Uqьtu bylege mədire:

Зав. Учебной частью / Sikritar:

LYBIAN URMAN TIXNIKASЬ tixnikumь

„25“ iyn 1931 г.

№ 1063

Lybian poc. byl. T. R.

Brleşegez bəten dөnja eşçelere

R. S. F. S. R.

Tatarstan sotsial sovitlar çemhyriəte

VSNX. Urman. promь SSSR. jşlnno. sojuzь

TANQLЬQ.

Bu tanqlьq 1912 ncь jlnьn 4 nce XII ajnda tuqan graz. Niazi Qiam ulь Bigaşef qa, anьn 1928 nce jlnьn ... nce ... ajnda Lybian urman tixnikasь tixnikumьna uqrqa krep 1931 nce jlnьn 25 nce iyn ajnda anьn Urman xuçalыq bylegen bterep lisovod-tixnik kvalifikatsiəsen aluь turnda birlde.

graz. Bigaşef N. Q. tixnikumda uqьqanda ... jьl slipindiə blən fajdalandь.

Любян урман техникумын тәмамлау таныклыгы

Бик күп җирләрдә булдым. Донбассны, Харьков өлкәсен, Ворошиловград һәм Воронеж өлкәләрен кыш буена бик нык таптадык.

Җиһан, мине орденга яздылар, шушы арада орден алам, яхшы сугышкан өчен. Минем бу хат исәнлек хаты гына булыр инде. Күп язып булмый. Яңадан яхшылап язармын әле. Синең үзеңнән ике ай инде хат алганым юк. Сыер бозаулагандыр инде. Сарыклар, кәҗәләр бәрәнләп беттеме? Ничә бәрән? Бозау үгезме, танамы? Хәзергә исән-сау гына торасызмы? Шуларның барысын да әйтеп хат яз. Буген – 8 нче март, Хатын-кызлар бәйрәме. Башка елларны бу көнне бәйрәм ясый торган идек. Хуш, сау булыгыз.

Ниязи Бигашев.

20.04.1943

Кадерле Җиһаным һәм акыллы кызларым!

Барыгызга да гвардия Кызыл Армия сәламе җибәреп калам. Үзем исән-сау әле. Җәйге сугышка кермәдем әле. Ялда ятабыз. Мин хәзер кече командир. Һаман да минометчик. Орден алдым. Партиягә кердем. Илне саклауда яхшы уңышлар күрсәттем. Әгәр дә исән-сау кайтырга туры килсә, мин бик зур кеше булырмын, Җиһан! Үзем турында бетте.

Ничек торасыз? Кызлар үсәме? Синнән инде дүрт ай булды хат юкка. Хәбәреңне бик беләсем килә. Кайда торасың? Җир чәчтеңме? Бәрәңге утырттыңмы? Нинди маллар бар? Ничә сарык, кәҗә, бәрәннәр, тәкәләр, тавыклар һәм башка маллар? Әйтеп яз.

Барча мине белгәннәргә сәлам әйт. Әнкәйдән һәм бабайдан хатлар юк. Хатыңны озынрак яз. Минем кәгазь юк. Бу арада сине һәм кызларымны төштә күрәм. Озакламый тагын сугышка керәбез. Сау бул.

Ниязи Бигашев.

Ниязи Бигашев фронттан, дошманны җиңеп, гаиләсенә тизрәк әйләнеп кайту хыялы белән яшәгән, киләчәктә матур тормыш дәвам итүен теләгән: *«Дошман бик нык каршылык күрсәтә. Шулай булса да, без бирешмибез, әкренләп алга барабыз. Шулай итеп, без быел җәй көнендә аны җибәрмәбез. Озакламый бөтенләй җиңеп чыгарга тиешбез. Исән калсам, кайткач зур бәйрәм ясар идек».*

Аяныч ки, Бөек Ватан сугышында солдатларның күбесе чит җирләрдә мәңгелеккә ятып калган. Алар арасында дәү әтиебез Ниязи Кыям улы Бигашев та бар.

Рәйсә Ниязи кызы Бигашева-Кәрамованың оныгы ***Камилә Гыйльметдинова*** ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

«Җырланып бетмәгән җырым»

Илзирә Вәлиуллина

Нәҗибә Ихсанова, Илзирә Вәлиуллина, Туфан Миңнуллин

Ямьле июнь аеның бер көнендә Татарстанның халык язучысы, мәрхүм Туфан ага Миңнуллинның Нагорный бистәсендәге өендә булырга туры килде. Шундый матур бакча, һәр тарафта хуш исләрен бөркүче исәбе-чуты булмаган төрле төстәге чәчкәләр, гөл-ганҗәләр... Заманча теплица, аның эчендә үсүче кып-кызыл викторияләр һәм тагын әллә ничә төрле яшелчә, җиләк-җимеш... Бүгенге көндә боларның барысын да күңел биреп, зур теләк белән ике бөек шәхеснең кызлары Әлфия Миңнуллина белән кияүләре Корбангали Нуркеевич үстерә, тәрбияли. Тәрбияли, дигәннән, узган елның августыннан авырып урын өстендә ятучы яраткан артисткабыз Нәҗибә Ихсанова да алар тәрбиясендә яши. Әнә бит, Әлфия апа белән Корбангали абыйның кунакка чакыруын кабул итеп килгән якын туганнары (бертуган апасы Нәкыя, аның улы Гадел белән килене Миләүшә, сеңлесе Роза Байбекова, мәрхүмә Хәния апасының кызы Миләүшә, Туфан абыйны 15 ел йөрткән шофер Ришатның әнисе Әминә һәм әтисе Минхәсән Шаһиевлар), күрешеп, бер-бер артлы янына килеп, хәл-әхвәлләрен сорашкач, бөек актриса йә, ишетәм сезне, дип берәр ым кага, йә кулын кымшаткалап куя, йә булмаса, иренен селкетеп, берәр сүз әйтергә омтыла... Алданрак баруыбызда күпләрнең кумиры булган бөек актриса кызымның милли киеменә, калфагына бик озаклап карап торган иде. Алты яшьлек кызым: «Исәнме, Нәҗибә апа!» – дигәч, артистканың йөзендә елмаю барлыкка килде... Кечкенә вакытында кулына алып, чын күңелдән яратып сөя иде шул Нәҗибә апа кызыбызны. Әйе, күрешкәндә нәкъ үземне якын итеп кочаклап алып аркамнан сөйгән төсле...

* * *

Актриса белән иң беренче мәртәбә моннан 17 ел элек, 2003 елның 18 мартында, галиҗәнап Г.Камал театрына «Зәңгәр шәл»не карарга баргач күрешкән идем. Әлеге данлыклы театрга барып спектакль карау күптәнге хыялым иде инде. «Зәңгәр шәл» куелган көнне сайлавым да очраклы түгел, чөнки анда яраткан артисткам Нәҗибә Ихсанова абыстай ролен башкара. Күршебез Минҗамал апага (урыны җәннәтә булсын) Казаннан кайткан кунаклар да, ниятемне куәтләп: «Әйдә, җыен, киттек безгә кунакка, спектакльгә дә бергә барырбыз», – дигәч, Аллага тапшырдым да әзер машинага капка төбеннән үк утырып киттем. Минем белән спектакльгә барырга тиешле Минниса апаның икенче көнне температурасы күтәрелеп авырып китү сәбәпле, миңа спектакльне аннан башка гына карарга туры килде. Спектакль бетеп, сәхнәгә чәчәк тотып чыккач, Нәҗибә апа минем хәлемне җиңеләйтеп, ягымлы елмайган кыяфәттә: «Сез кем буласыз?» – диде. Мин тиз генә аның белән әңгәмә үткәрәсе килү теләгемне әйттем һәм ул миңа, гардеробтан киемнәремне алгач, үзенең грим бүлмәсенә керергә кушты. Мин кергәндә, Нәҗибә апа бүлмәдә Наилә Гәрәева белән иде. Бу көнне без фойеда беренче күрешү истәлеге итеп фотога төштек, бөек актриса миңа иртәгә көндез театрга репетициягә киләсе барлыгын әйтте, китмәсәң, шунда кил әле, иркенләп сөйләшеп утырырбыз, диде.

> «
> **Мин кергәндә, Нәҗибә апа бүлмәдә Наилә Гәрәева белән иде. Бу көнне без фойеда беренче күрешү истәлеге итеп фотога төштек, бөек актриса миңа иртәгә көндез театрга репетициягә киләсе барлыгын әйтте, китмәсәң, шунда кил әле, иркенләп сөйләшеп утырырбыз, диде.**

Икенче көнне көндез билгеләнгән вакытта театрда актриса мине үзе каршы алды. Йөзеннән нур бөркелеп торучы Нәҗибә Ихсанова белән шунда янә бер күрешү, иркенләп сөйләшү насыйп булды. Әңгәмә барышында аның затлылыгына, һәрнәрсә турында төпле фикере булып, ягымлы итеп сөйләшүенә мөкиббән китеп утырдым. (Алга таба да һәр күрешүебездә шундый иде ул!) Әмма бөек актриса турындагы язмам әңгәмә буларак түгел, ә очерк буларак язылды. Чөнки аның белән сөйләшкәндә алган тәэсирләр, әңгәмә кысаларына гына сыешмыйча, очерк жанрына күчеп, «Идел» журналының декабрь санында басылып чыккан көннәрнең берсендә Нәҗибә апа Ихсанова миңа рәхмәт әйтеп шылтыратты.

– Укыгач, хәтта Туфан абыең да, әйбәт, җылы язылган, дип әйтте, – дип тә өстәде зыялы ханым. Рәхмәт әйтү белән генә чикләнмичә, ул мине үзләренә кунакка, Туфан абыйның «Шулай булды шул» премьерасын карарга чакырды. Югыйсә мин – гади бер авыл кызы. Нәҗибә апаның өйләренә дәшүен ишеткәч, дулкынланудан тәнемә каз тәпиләре чыкты...

Хәтер һәм дәфтәр көндәлекләремне шул көннән башлап актарсам, анда күпме истәлекләр, хәл белешүләр, җылы очрашулар, юксынулар, дигәндәй... Әйткәнемчә, актриса белән элемтәбез, телефон аша дисеңме, күрешепме, һәрвакыт яңартылып торды. Озаграк шылтыратмый торсам, Нәҗибә апа миңа: «Синең тавышыңны да ишетер көннәр булыр икән, тәтием», – дип, олы башын кече итеп, үзе шылтырата иде... Үскәнем, акыллым, тәтием, дип матур итеп эндәшүе йөрәгемә сары май булып ятуын әйтеп тә торасы юк. Очрашканда, җай туры килсә, Нәҗибә ападан шигырь укуын

Туфан Миңнуллин Илзирә Вәлиуллинаны котлый

үтенә идем, чөнки аның кебек оста, йөрәккә үтеп керердәй итеп шигырь сөйләүчеләр сирәк... Мактану булып яңгырамасын, Нәҗибә апа 2005 елның августында «Мәдәният дөньясында» тапшыруында «Хәерле юллар, Казан» дигән шигыремне укыгач, бик сөендем. Теге яисә бу шәхескә багышланган кичәләр, премьералар булганда, бөек актрисаның, үскәнем, кил, дип чакыруы җанымны озак вакытлар буе җылыта иде... Аннан алган җылылыкта байтак җылынып йөри идем...

Нәҗибә апаның чакыруы белән Туфан Миңнуллинның «Шулай булды шул» әсәре буенча куелган спектакльнең премьерасын карарга баруым да бүгенгедәй хәтеремдә. Тәмле итеп әзерләнгән кайнар аш, үзе пешергән эремчек пирогы белән сыйлады яраткан артисткам. Хәзер Туфан абыең да кайтып җитә, дигәч, читенсенү вә каушаудан йөрәгемнең күкрәгемнән чыгардай булып ничек дөп-дөп тибүен белсәгез икән?! Чыннан да, ул дулкынландыргыч мизгелләр килеп җитте, озакламый ишек кыңгыравы шылтырап, кулына зур портфель күтәргән Туфан абый Миңнуллин килеп керде.

– Кайттыңмы, кунагыбыз бар, Туфан. Түбән Камадан Илзирә, – диде Нәҗибә апа, бер миңа, бер Туфан агага ягымлы караш ташлап.

– Ярар, бик әйбәт, Нәҗибә апаң гел сөйли инде синең хакта, – диде Туфан ага үзенә генә хас гөрелдәп торган тавышы белән.

Туфан абыйдан кыяр-кыймас кына исәнлек-саулык сораштым. Бергәләп табын артында чәйләп утыру барышында алар мине икәүләшеп кыстый-кыстый, өстәл тулы сый-нигъмәттән авыз иттерделәр. Дулкынланудан ике битемнең кызышуы театрга Туфан

«

Сөенеч өстенә сөенеч, дигәндәй, шул ук елны артистка тамашачыны шпагатка утырып шаккаттырган «Йөрәк маем» спектаклен дә Казанга барып карау бәхете тәтеде.

Сулдан уңга: Мөсәгыйт Хәбибуллин, Гөлчирә Ибәтуллина, Рифкать Имаев, Туфан Миңнуллин, Илзирә Вәлиуллина

абыйның «Шулай булды шул» премьерасын карарга баргач та бетмәде. Нәҗибә апа, әлеге спектакльдә үзе дә катнашканлыктан, Туфан абыйга: «Илзирәне үзеңнән калдырма!» – диде. Шулай итеп, мин, зыялы Туфан ага янәшәсендә утырып, әлеге тамашаны карадым. Спектакль барышында халык язучысы миннән: «Театр җене кайчан кагылды?» – дип сорады. Ишетелер-ишетелмәслек кенә итеп: «Күптәннән, кечкенәдән үк!» – дидем.

Бу очрашуыбызда Туфан абый белән Нәҗибә апа мине Актерлар йортына да алып барды. Танылган режиссер мәрхүм Марсель Сәлимҗановны искә алу кичәсе булды анда. Ул көнне Актерлар йортына аның исеме бирелде. Нәҗибә апа белән Туфан абый аркасында миңа анда булган бөтен артист һәм режиссерларны, гомумән, талантлы шәхесләрне якыннан күрү бәхете тәтеде. Милләтемнең ике мәшһүр шәхесе янәшәсендә бер түгәрәк өстәл артында утыруны язмышыма язылган олуг бүләк итеп кабул иттем. Бу – җиһанда һәм күңелдә аклык хакимлек иткән кыш – 2004 елның гыйнвар ае иде...

Китап киштәмдә, шушы көннең якты бер хатирәсе булып, олуг әдибебез имзасы куеп бирелгән «Утырып уйлар уйладым» исемле китап саклана. Сөенеч өстенә сөенеч, дигәндәй, шул ук елны артистка тамашачыны шпагатка утырып шаккаттырган «Йөрәк маем» спектаклен дә Казанга барып карау бәхете тәтеде. Көз аенда, ягъни 28 нче октябрьдә баруымда «Яшьләр» театрында Нәҗибә апа һәм Туфан абыйлар белән бергә Рабит Батулла әсәре буенча куелган «Бичаракай» спектаклен карау насыйп булды. Ә инде 2004 елның 29 октябрендә М.Сәлимҗанов каберенә таш куелды. Шунда Нәҗибә апа миңа татар зыялыларының каберләрен күрсәтеп йөрде. Алар арасында Хәсән ага Туфанныкы да бар иде. Мәшһүр шагыйрьнең каберен Туфан ага Язучылар берлеге рәисе булган вакытында икенче урынга күчерткән икән, чөнки ул, әдип фикеренчә, тиешле урында түгел, әллә кайда артка җирләнгән булган. Хәзер Хәсән аганың кабере

Туфан Миңнуллин һәм Илзирә Вәлиуллина «Шулай булды шул» премьерасыннан соң. Түбән Кама. 1 ноябрь, 2004 ел

зиратка килеп кергәч тә күренеп тора. Аннан кайтышлый, Нәҗибә апа театрга репетиция ясарга төшеп калды, мин исә «Мәдәни җомга» редакциясенә Түбән Камада узган «Җидегән чишмә» кичәсе турындагы язмамны тапшырырга киттем. Ә кич, бергәләп, Г.Камал театрына сезон ачылуга бардык. Гадәттәгечә, К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е белән ачылды. Ул башланыр алдыннан театрның өлкән артистларын тәбрикләделәр, аннан аерым иҗат кешеләренә бүләкләр тапшырдылар. Бүләкләнүчеләр арасында, Татарстанның халык артисткасы Наилә Гәрәева, Алсу Хәйруллина белән беррәттән, Туфан ага Миңнулин да бар иде.

Әлбәттә, мин Казанга һәр баруымны Нәҗибә апага әйтмәскә тырыша идем,чөнки аны гел-гел борчыйсым килмәде.

Мәрхүм Марсель Сәлимҗановның Туфан абый иҗатын бәяләп әйткән мондый сүзләре бар: *«Туфан ни генә язса да, анда яңалык, ул кабатланмый – жанр ягыннан да,тормышны күрүе белән дә. Аның кебек оста характер тудыручы юк, алар – чын җир кешеләре»*. Чыннан да, Туфан абый әсәрләренең көчле оптимизм, яшәү дәрте, кыю фикер сөреше, олы бер мәгънә белән сугарылганлыгы тормышта үзенең дә оптимист булып яшәгәнлегенә ишарә ясый. Үзе дә бит әнә: *«Нәселдә бардыр, бездә җылак кешеләр булмады, нинди генә аяныч хәлдә дә яшәргә омтылыш тоеп гомер иттем»*, – ди. Һәм бабасы – әнисенең әтисе Гатауллины искә төшерә: «Ул минем нәселем тармагы – горурлыгым. 89 яшенә тикле яшәде. Уен-көлке, эш яшәтте аны. Бервакыт чана табанын юнган чагында янына бер исерекбаш килә дә:

– Нәрсә инде карт башың белән азапланасың? Җитмимени, барыбер кала бит ул, – ди.

– Дурак син, – ди яшь бабай, – кала шул менә. Ә синнән нәрсә кала? Сине бит инде исән чагыңда ук онытты-лар! – ди.

> **«**
>
> **Язмышын театр белән бәйләгәнгә һич тә үкенмәгән олпат әдип һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Туфан аганы да бүген онытмыйлар: ул мәңгегә халык күңелендә, тарих битләрендә...**

Чыннан да, теге исерекбашны инде күптән оныттылар, ә яшь бабайны һаман сагынып сөйлиләр, кызыклы якларын елмаеп искә алалар, осталыгын сокланып сөйлиләр».

Язмышын театр белән бәйләгәнгә һич тә үкенмәгән олпат әдип һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Туфан аганы да бүген онытмыйлар: ул мәңгегә халык күңелендә, тарих битләрендә... Исән булса, Туфан Миңнуллинга быел 85 яшь тулган булыр иде... ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Казанда Гали Акышны хөрмәтләү

Фоат Галимуллин, филология фәннәре докторы

Гали Акыш

Бөек әдипләребездән һәм сәясәтчеләребездән Гаяз Исхакыйның фикердәше, алай гына да түгел, көрәштәше дә булган Гали Акышка (Алиулла Хисаметдин улы Агишев) җитмеш биш яшь тулу уңаеннан, 1993 елның 24 июнендә М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры бинасында зур юбилей кичәсе уздырылган иде. Ул көн, анда алынган тәэсирләр, ничектер, бөтен ваклыклары белән хәтеремдә саклана. Иң шаккаттырганы шул булган иде: Гали Акыш үзе дә әлеге кичәдә катнашты! Бу аның илебезгә беренче һәм соңгы тапкыр килүе булды.

Г.Акыш 1918 елда Кытайның Хайлар шәһәрендә туган. Шунда – мөселман төрек-татар мәктәбен, аннан 1936 елда рус гимназиясен тәмамлаган. Әти-әнисе иң әүвәл малайга туган телебез, әдәбиятыбыз, ягъни рухи кыйммәтләребез нигезендә милли тәрбия бирергә тели. Татарның төп туган җире Россиядә икәнлеген дә онытмыйча, аңа рус телен өйрәнү шартларын да тудыралар. Ихтимал, шушы якларга кайту мөмкинлеге туса (кем белә, Ходайның насыйп итеп куюы да бар), тел мәсьәләсендә кыенлык кичерергә туры килмәсен дигән теләктән чыгып эш иткәннәрдер. Әмма Гали әлеге уку йортын тәмамлаган утызынчы елларның икенче яртысында чит илдә сыену урыны тапкан кешеләргә Советлар Союзына кайту турында уйларга да мөмкин түгел иде. Шуңа күрә ул Каһирәгә юл тота. Гали андагы атаклы Әл-Әзһәр дәрелфөнүнендә ислам нигезләрен тирәнтен өйрәнергә керешә. Ике ел укыгач,

ул Гаяз Исхакый янына – Варшавага китә. Аның белән бергә төрки халыклар мәнфәгатьләрен яклау юнәлешендә хезмәттәшлек итә. Большевикларның милли сәясәтендәге мантыйкка сыймый торган күренешләргә каршы көрәшү алар эшчәнлегендә алгы урында тора. Әлбәттә, аларны иң беренче нәүбәттә татарларның хәле борчый. Икенче Бөтендөнья сугышы башлану куркынычы чынбарлыкка әверелә башлагач, алар, Гаяз әфәнде белән бергә, Төркиягә юл тоталар. Һәм монда да Гали Акыш үзеннән кырык яшькә олы остазының уң кулы булып кала бирә. Г.Исхакыйның вафатыннан соң, бу эшне, гомумән, үз кулына ала. Ә инде 1966 елдан, Ауропага күчеп, эшчәнлеген «Азатлык» радиосында җәелдерә. Бу хезмәтен ул 1983 елга кадәр дәвам иттерә.

> «
> **Большевикларның милли сәясәтендәге мантыйкка сыймый торган күренешләргә каршы көрәшү алар эшчәнлегендә алгы урында тора. Әлбәттә, аларны иң беренче нәүбәттә татарларның хәле борчый.**

Г.Акышның «Азатлык» радиостанциясендә эшләве, хәтта тора-бара татар-башкорт редакциясендә җитәкче вазыйфасын башкаруы, сүз дә юк, безнең илнең мәгълүм оешмалары тарафыннан игътибарсыз калдырылмады. Бу тапшыруларның эчтәлеге, нинди мәсьәләләрне ничек итеп куюлары, безнең илдәге вазгыяткә карата булган карашлары, әлбәттә, өйрәнелеп барылгандыр дип уйларга кирәк. Аларга карата бездәге билгеле авторларның мөнәсәбәтләре, бик еш булмаса да, вакытлы матбугатта искәртелә килеңде. Шунысы бәхәссез: Гали Акыш әлеге чыгышларда илебезгә карата идеология диверсиясе алып баручыларның берсе буларак күрсәтелде.

Менә шушы кешенең Казанда, аның да иң затлы биналарының берсендә юбилей кичәсе уздырылуы заманның ничек тамырыннан үзгәрүе турында сөйли иде.

Миннән ул кичәне алып баруымны сорадылар. Әлеге тәкъдимгә башта аптырап та калдым, чөнки бу шәхес хакында исеменнән башка бернәрсә дә белмим диярлек. Белгәнем дә С.Батыев, М.Абдуллин кебек авторларның мәкаләләрендә бәян ителгәннәр генә. Үзен күреп белү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Шулай да кичәне оештыручылар, аның хакында беребез дә күп беләбез, дип әйтә алмыйбыздыр, кичәне әзер программада күрсәтелгәнчә алып барсаң, шул җитә, дигәч, риза булдым инде.

Гадәтем шундый: андый вакытларда чара уздырыласы урыннарга алданрак барырга тырышам. Бу юлы да Опера-балет театрына бер сәгать чамасы алдан килдем. Миңа әлеге кичәне җырчы Гөлзада Сафиуллина белән бергә алып барачагымны әйттеләр. Без аның белән, программаны укып чыгып, кайсы номерны яки чыгышны кем игълан итәчәген килештердек, кичә барышының кайбер үзенчәлекләрен ачыкладык.

Шунда кемдер пышылдады:

– Әнә, Гали Акыш үзе дә килде.

Әйе, аны озата килүче безгә таныш ике-өч кеше белән уртача гәүдәле, ябыграк йөзле, әмма шактый җиңел хәрәкәтчән кеше яныбызга якынлашып килә иде. Аның белән янәшә килүчеләрнең берсе Әзһәр Хөсәенов булып, якынлаша төшкәч, безне Гали абый белән таныштырды:

– Менә бу кунагыбыз бүгенге кичәнең сәбәпчесе Гали абый Акыш була инде. Ә бу ханым белән әфәнде, – диде ул, Гали абыйга борылып, – бүгенге сәхнәнең хуҗалары – җырчы Гөлзада Сафиуллина һәм педагогия институты доценты, Татарстан радиосының элеккеге дикторы Фоат Галимуллин.

Моны ишеткәч, Гали абый миңа аерым бер игътибар белән карады кебек. Күрешкәч, әйтеп куйды:

– Фоат Галимуллин… Таныш исем кебек. Ә?! Диктор, дидегез бит әле.

Аннары дәвам итте:

– Йә, энекәш, берәр сүз дә әйтеп куегыз инде, тавышыгызны да ишетик.

Мин үземне шактый сәер хәлдә итеп сиздем. Шулай да, ике-өч җөмлә оештырып, нәрсәдер сөйләп алдым. Хәзер инде хәтерләмим дә.

Ул исә, мине тыңлагач, шатлангандай итеп, киң елмаеп, әйтеп куйды:

– Шул, шул! Нәкъ шул тавыш! Мюнхендагы радиостанциядә Сезнең тавыш белән язылган тапшырулар саклана. Без, аларны тыңлап, хәзерге вакыттагы татар әдәби телендә сөйләшү үрнәкләрен ишетә идек. Ул язмаларның кайберләрен, Алманиядән киткәндә, Төркиягә дә алып кайттым. Ара-тирә булса да тыңлап алгалыйм.

Мин әлеге сүзләргә аптырап калдым.

– Нинди язмалар икән ул һәм алар Мюнхенга ничек барып эләккән? Минем алар белән беркайчан да элемтәләрем булмады ич?..

– Һи, хәзер теләсә кайсы әйберне табу, алу мөмкинлекләре чиксез күп бит. Сезнең язмаларыгызга килгәндә, аларның безгә килеп ирешүе ике юл белән мөмкин булды дип беләм.

– Кызык, нинди юллар икән ул?

Гали абый җиңелчә генә көлеп куйды. Аннан, мәзәк сөйләгәндәге хәрәкәтчән интонациягә күчеп, күзләрен як-якка йөртеп, сөйләп китте:

– Хәтерлисездер, алтмышынчы елларда сезнең радио «Чит илләрдәге милләттәшләребезгә» дигән тапшырулар әзерли иде. Хәзерге саф татар телендә. Аны Камал Саттарова һәм тагын Сезнең тавыш белән яздыралар иде. Шул тапшыруны Мәскәү аркылымы, әллә Аурупа, яки Төркиягә якынрак башка шәһәр радиостанциясеннәнме эфирга бирәләр иде. Ул илләрдә, ягъни Алманиядә һәм Төркиядә чит кыйтгалардан сөйләүче радиостанцияләрнең тавышларын кеше аңламаслык итеп бозу юк иде. Без атнага бер була торган әлеге тапшыруларны тыңлап бардык, алай гына да түгел, яздырып та ала идек. Сез анда Советлар Берлегендә татарларның ничек бәхетле яшәүләрен канәгать тавыш белән бәян итә идегез.

Сирәк кенә булса да, икенче юлы да файдаланылды. Мәсәлән, хәтерлисезме икән, алтмышынчы еллар ахырында Казанда АКШның сәнәгать өлкәсендәге казанышлары күргәзмәсе булды. Анда океан артыннан килгән экскурсоводлар арасында татарлар да булган. Шулардан бер ханым сезнең биредә татарча яңгырый торган тапшыруларны эфирдан язып алып кайткан иде. Анда ниләр генә юк, ул спектакльләр дисеңме, концертлармы?! Әлбәттә инде, Сезнең сөйләгәннәрегез дә күп кергән. Ул, радио бинасына барып, Сезнең белән очрашырга да омтылып караган. Әмма аны борып җибәргәннәр, дикторлар әле монда юк, дигәннәр. Кайчан буласыгызны да әйтмәгәннәр.

> «Без атнага бер була торган әлеге тапшыруларны тыңлап бардык, алай гына да түгел, яздырып та ала идек. Сез анда Советлар Берлегендә татарларның ничек бәхетле яшәүләрен канәгать тавыш белән бәян итә идегез.

Мин шул вакытлардагы хәл-әхвәлләрне хәтеремдә яңарттым. Утыз еллап вакыт узса да, шундый вакыйга булганлыгы исемә төште. Ул күргәзмә Үзәк стадион коймасы эчендә эшләде. Әлеге Америкадан килгән татар ха-

Фәридә Гаффарова һәм Шәукәт Кунтай Гали Акыш белән

тынын күрер өчен, Камал апа белән шул күргәзмәгә дә бардык. Бер хатынның татарча сөйләшүен ишетеп, читтән генә, шаклар катып, тыңлап тордык. Ләкин үзебезне белдермәдек. Камал апа: «Бәласеннән башаяк, күзәтеп торучылар булырга мөмкин», – дигән иде.

Шулай итеп, бу Гали абый дигәнебез безнең хакта шактый хәбәрдар булып чыкты. Аннан инде ул сорау бирде:

– Без Сезнең белән коллегалар икән – дикторлар. Ә менә Сезнең мине эфирдан тыңлаганыгыз булдымы?

– Юк, булмады. Дөрес, ара-тирә радиоалгыч белән эфир дулкыннарында «йөргәндә», «Азатлык» радиосына юлыга идем. Ләкин Сезнең нәрсә, ничек сөйләвегезне аңларга мөмкин түгел иде. Нәкъ шул ешлыкта чыжылдау-выжылдау тавышлары котырыпмы-котырына. Шуңа күрә, нәрсә сөйләвегезне аңламаган кебек, кая анда кем сөйләгәнен аерып алу?!.

Бу читтән килгән абый белән танышуыбыз шулай булды.

Кичә бик күтәренке кәеф белән берничә сәгать дәвам итте. Анда ул вакыттагы иң күренекле әдәбият-сәнгать көчләре тупланган иде. Гали Акышның үз чыгышын да бик хуплап каршы алдылар.

Шул рәвешле, гомере буе халкыбызның язмышы өчен борчылып яшәгән һәм аның киләчәген матур итеп күрү юлында фидакяр хезмәт куйган Гали Акышка Татарстан башкаласында зур хөрмәт күрсәтелде. Ул республикабыздан бик канәгать калып китте. Инде әйтелгәнчә, кызганыч, Гали ага бирегә башка килә алмады. 2011 елның июлендә Әнкара шәһәрендә вафат булды. Милләтпәрвәр шәхесебезнең җәсәде шул шәһәрдәге Җебеҗи зиратында әти-әнисе, абыйсы һәм сеңлесе каберләре янәшәсендә җирләнде. ■

Истә, һаман да истә!

Шагыйрә
Фирая Зыятдинованың
тууына 75 ел

Шагыйрә һәм тәрҗемәче, 1989 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы Фирая Гали кызы Зыятдинова 1945 елның 5 сентябрендә Әтнә районының Мамыш авылында туган.

Ул 1968 елда Казан дәүләт университетын тәмамлый һәм, бер ел мәктәптә укыткач, Татарстан китап нәшриятында эшли башлый.

Ф.Зыятдинованың кайбер китаплары: «Матур буласым килә» (1986), «Язгы ярсу» (1988), «Ташкын» (1991), «Айнур» (1995), «Мин Кояшка елмаям!» (2000), «Бака туе» (2003), «Утның яшисе килә» (2005). Аның аерым шигырьләренә Ә.Бакиров, Ф.Әхмәтов, Л.Батыр-Болгари, Р.Кәлимуллин кебек күренекле композиторлар көй язды.

Ул 2006 елның 22 апрелендә вафат булды.

Драматург
Таҗи Гыйззәтнең
тууына 125 ел

Драматург, актер, ТАССРның (1939) һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1940), 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәт (Гыйззәтуллин) 1895 елның 15 сентябрендә Әгерҗе районының Барҗы-Омга (Умга) авылында игенче гаиләсендә туган.

Ул үз гомерендә 37 пьеса яза. Аларның күбесе Татар дәүләт академия театрында куела (мәсәлән, «Чаткылар», «Ташкыннар», «Бишбүләк», «Таймасовлар», «Наемщик»).

Т.Гыйззәт 1955 елның 7 мартында Казанда вафат булды. Вафатыннан соң, Казандагы һәм Алабугадагы урамнарның берсенә аның исеме бирелде, 2007 елда Әгерҗедәге 3 нче мәктәптә музее ачылып, бюсты куелды. Әлеге мәктәп аның исемен йөртә.

Композитор
Заһид Хәбибуллинның
тууына 110 ел



Композитор, скрипкачы, ТАССРның (1950) һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1981), ТАССРның халык артисты (1970), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1968) Заһид Вәли улы Хәбибуллин 1910 елның 10 сентябрендә Орск шәһәрендә туган.

Ул иҗат иткән җырларның кайберләре: «Сагыну» (М.Җәлил сүзләре), «Батыр егеткә» (Ә.Ерикәй), «Сайра син, тургай» (Г.Насрый), «Бормалы су» (Н.Исәнбәт), «Баулылар» (Н.Арсланов), «Яшьлек җыры» (Ш.Маннур), «Казах дустыма» (С.Хәким).

Заһид Хәбибуллин 1983 елның 20 ноябрендә Казанда вафат булды.

Композитор
Шамил Тимербулатовның
тууына 70 ел

Композитор, Татарстан Республикасының (1995) һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе (2005), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2013) Шамил Харис улы Тимербулатов 1950 елның 25 сентябрендә Казанда туган.

1967 елда музыка мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан музыка училищесының халык инструментлары бүлегендәге баян классына укырга керә. 1972-1977 нче елларда Казан дәүләт консерваториясендә укый.

Кайбер әсәрләре: 1 нче симфония – «Бомбаны яшерегез!» (1972), 2 нче симфония – «Җир сулышы» (1994), 3 нче симфония – «Дәверләр чоры» (2000), 4 нче симфония-оратория – «Өмет» (Г.Тукай, Р.Фәйзуллин).

Ш.Тимербулатов 2013 елның 30 маенда вафат булды.

Композитор
Исмай Шәмсетдиновның
тууына 110 ел

Композитор, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1966) һәм ТАССРның халык артисты (1981) Исмай Гайнетдин улы Шәмсетдинов 1910 елның 29 сентябрендә Пермь губернасындагы Надеждинск каласында туган.

Исмай Шәмсетдинов 1936 елда Казан музыка училищесына Юрий Виноградов классына укырга керә һәм аны 1940 елда тәмамлый.

1941-1945 нче елларда ул Бөек Ватан сугышында катнаша. Исмай Шәмсетдинов 1948 елда, Нәҗип Җиһанов киңәше буенча, милли кадрлар кирәк булу сәбәпле, Казан дәүләт консерваториясенә укырга керә.

1952-1971 нче елларда Татар радиосында музыкаль мөхәррир, тавыш режиссеры вазыйфаларын башкара.

Кайбер әсәрләре: «Язлар җитсә» (Л.Айтуганов сүзләре), «Йөр син безнең урамнарда» (З.Вәли), «Чайкала иген кырлары» (Г.Латыйп), «Мәңге яшь кала» (З.Нури).

Ул 1982 елның 8 июнендә вафат булды.

Артистка
Люция Фарсинаның
тууына 90 ел

Артистка, ТАССРның халык артисты (1980) Люция Габдулла кызы Фарсина 1930 елның 30 сентябрендә Казанда туган.

Ул 1951 елда Казан театр училищесын тәмамлый.

Л.Фарсина 1951 елдан алып 1985 елга кадәр К.Тинчурин исемендәге театрда эшләде. Ул уйнаган кайбер рольләр: Сәнүвар («Йөрәк серләре», Б.Рахманов), Пәре («Сулган чәчәкләр», Җ.Җаббарлы), Мәрьям («Хәзрәт үгетләргә килә», З.Шаһиморатов), Сәкинә («Тугыз гашыйк», З.Шаһиморатов), Елена («Мещаннар», М.Горький), Ләбибә («Кырларым-тугайларым», Т.Миңнуллин), Зөлхия («Кыр казлары артыннан», И.Юзеев).

Люция Фарсина 2005 елның 4 мартында вафат булды.■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Борынгы татар милли музыка уен коралларының

Ринат Гыйләҗев, «Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

Ринат Гыйләҗев (сулдан беренче) татар фольклор галимнәре белән

Һәр халыкны халык итеп танытткан уен коралы ул, – әлбәттә, кыллы уен кораллары. Көчле милли аң булу өчен милләтнең теле, дине, моңы булу гына җитми, аның милли уен коралларының да булуы шарт. Әгәр игътибар итсәгез, һәр суверен дәүләтнең үз милли оркестры бар. Оркестрның нигезен күп очракта кыллы уен кораллары тәшкил итә. Шуңа да мин, татар халкының беренче чиратта кыллы уен коралларын тирәнтен өйрәнеп, дәүләт күләмендә милли уен коралларыннан гына торган оркестрыбызның булуын теләр идем. Татар милли уен кораллары оркестрының үзәген саз, думбра, кыл-кубыз, гөслә, курай, сорнай кебек уен кораллары тәшкил итә алыр иде.

Белгәнебезчә, татар халык музыка уен коралларының күбесе кулланудан күпмедер вакытка төшеп, онытылып торган. Сакланганнарының да ясалу технологиясе бик гади һәм аларда уйнау традицияләре дә бик түбән. Ни өчен? Беренчедән, музыка коралларын сыйфатлы итеп ясау өчен, күптөрле махсус эшкәртү кораллары, аерым детальләрне җыйнау өчен төрле җайланмалар, калыплар кирәк. 500 еллар буена, никадәр генә теләсәң дә, ул кораллар татар осталарында булмаган. Чөнки татар авылларында, хәтта өйдә дә тимер пычак тотарга ярамаган. Шуңа да

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

карамастан, халык осталары, ничектер җаен табып, музыка уен коралларын, бик үк сыйфатлы булмаса да, ясаганнар, аларда уйнаганнар. Бу бигрәк тә керәшеннәрдә, үзәктән читтәрәк урнашкан татар авылларында сакланган. Шуңа да XVI-XX гасырлар арасында татар халкының думбра, ятаган, гөслә, кыл-кубыз, саз һәм башка күп төрле музыка коралларын ясау һәм аларда уйнау тулысынча диярлек онытыла. Аннан соң ул елларда татарның ачы язмышы уен кораллары турында уйларлык хәлдә дә булмый.

Рус халкының үзендә дә музыка уен коралларына битараф булмаган фидакяр музыкантлар 19 нчы йөз ахырларында гына күренә башлый. Беренче балалайканы коми остасы С.И.Налимов, 1895 елда В.В.Андреев биргән сызымнар буенча, коми халкының өч кыллы «Ас вочом» дигән уен коралы нигезендә ясый. Сер түгел, Андреев, Русиянең руслар яшәгән бөтен төбәкләреннән эзләп тә, балалайкага охшаган уен коралын таба алмый. Кылларының көйләнелеше дә соль-ре-ре коми халкының «сигудок- балалайка» дигән уен коралыннан алынган. 1896 елда шул ук Налимов, Андреев биргән сызым буенча, беренче рус думбрасын ясый. Аның да үрнәген Андреев Идел һәм Нократ буйларында яшәүче халыклардан, ягъни татар һәм нугай думбрасыннан ала.

Шул ук елларда, Европадан кергән гармоника нигезендә, рус осталары төрле гармуннар, хромка, баян ясый башлыйлар. Соңга табарак әлеге коралларда, теләсәләр-теләмәсәләр дә, СССРда яшәүче барлык халыклар да уйный.

Шулай итеп, татар тормышында думбраны – балалайка, сазны – мандолина, кыл-кубызны – скрипка, сорнайны – жалейка, курайны – свирель, тарны – гитара («гитара» сүзе шулай ук төрки сүз, «ги» – ике, «тар» – савыт дигәнне аңлата) һ.б. кораллар алыштыра. Совет власте елларында балаларны көчләп диярлек музыка мәктәпләрендә, югары уку йортларында әлеге коралларда уйнарга өйрәттеләр, укыттылар, бу коралларны пропагандаладылар. Ә инде СССР таркалгач, рус халкының үзенә дә мондый коралларның кирәге калмады. Сүз дә юк, әлеге уен кораллары – эшләнелеше, тавышының көче, уйнау мөмкинлекләре буенча бик яхшы уен кораллары, әмма аларны халык үз итмәде, алар халыкныкы түгел, алар хәтта урысныкы да түгел. Казакъ музыка уен кораллары белән дә шундый ук хәл күзәтелде. Бер казакълар гына түгел, күп кенә башка халыклар да Совет власте басымы астында милли уен кораллары белән күптөрле экспериментлар ясадылар. Соңыннан, озак еллар адашып йөргәннән соң, барыбер үзләренең традицион уен коралларына әйләнеп кайттылар.

Аннан соң әле икенче зур сәбәп тә бар. Бу – уен коралына игътибарның дәрәҗәсе. Мәсәлән, күрше башкорт халкы, беренче чиратта, Башкортстанның дәүләт җитәкчеләре, шул ук совет чорында конкрет бер курай уен коралын вакытында күреп, сайлап алалар. Бик акыллы гына, шауламыйча, курай ясаучыларны, уйнаучыларны кызыксындыралар. (Әйтик, фатир, остаханә, дәрәҗәле исем бирү.) Иң зур сәхнәләрнең түрендә курайга урын бирелә. Балаларны музыка мәктәпләрендә Башкортстан мәгариф министрлыгы төзегән махсус программа нигезендә укыталар. Югары сәнгать уку йортларында махсус курай сыйныфлары ачыла. Хәтта Континенталь хоккей лигасы хоккейчыларының киемнәренә дә курай эмблемасы төшерелгән. Нәтиҗәдә, дөнья халыклары сокланырлык, башкорт халкының горурлыгы булган курай уен коралы торгызыла. Башкару мәктәбе булдырыла. Мәңгелек дан аларга! Башкортстанда яңарыш җиле хәзер дә дәвам итә. 1992 елда Уфа дәүләт сәнгать институты каршында уен коралларын ясау буенча махсус остаханә оештырыла. Шул тәртиптә әле хәзер дә башкорт думбрасын, кыл-кубызны һәм әле тагын байтак кына уен коралларын торгызу өстендә эшлиләр.

Тыва Республикасында да сокланырлык эшләр бара. Тыва халык музыка уен коралларыннан гына торган 60 кешелек милли дәүләт оркестры төзелгән. Әлеге оркестрның беренче җитәкчесе бүгенге көндә мәдәният министры булып эшли.

Республикада, ел символы итеп кыллы уен коралы игилне алып, «Игил елы»н игълан иткәннәр. Уен коралына нинди хөрмәт!

Якут халкының хезмәте дә олы хөрмәткә лаек. 1988 елда фольклорчы галим Иван Егорович Алексеев дөнья халыкларының хомуз һәм шуңа охшаган уен коралларын җыя, бергә туплый башлый һәм дөньяда иң зур хомуз музееен булдыра. Ул беренче тапкыр хомуз уен коралының концепциясен төзи, аны ясау һәм башкару мәктәбен булдыра. И.Е.Алексеев башлангычында Якутск каласында, СССР композиторлар берлеге белән, Хомузчыларның I Бөтенсоюз конференциясе үткәрелә. Шул ук вакытта ул Якутиядә яшәгән иң оста хомузчы виртуозларны бергә туплап, хомузчылар ансамбле төзи һәм үзе дә искиткеч оста итеп уйный. Нәтиҗәдә, сыйфаты буенча да, уйнау осталыгы буенча да дөньяда тиңе булмаган хомуз уен коралы торгызыла. Менә бу ичмасам, республика җитәкчеләре тарафыннан да, фидакяр музыкантлар тарафыннан да музыка уен коралына карата игътибар, батырлык. Хомуз ул – якут-саха халкының милли горурлыгы.

Аннан соң, уен коралының язмышы, минемчә, элек-электән халыкның үзеннән дә торган һәм хәзер дә шулай. Монда беркемне дә гаепләп булмый шикелле. Әгәр уйнаучыга уен коралы кирәк икән, ул ясаучы оста янына бара һәм аны ясатып ала. Монда инде базар законы эшли башлый. Әмма күпләп уйнаучыны каян табарга? Миңа калса, аның берничә юлы бар. Беренчедән, үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә катнашучыларның саны күп булуда. Сәнгать мәктәпләрендә, махсус урта һәм югары уку йортларында халык уен кораллары сыйныфларын булдыруда. Әмма бу эшләрнең берсен дә дәүләт ярдәменнән башка эшләп булмый. Икенчедән, минемчә, иң әһәмиятлесе – уен коралында уйнап акча табарга өйрәнү. Әгәр бер яшүсмер үзе сайлаган уен коралында уйнарга өйрәнеп яисә җырлап, киләчәктә үзен һәм гаиләсен тукландырырга ният кыла икән, аның уйнаган уен коралы бик сыйфатлы булырга һәм ул бик оста итеп уйный яисә җырлый белергә тиеш. Булдыра алмаса, аны икенче тапкыр уйнарга яисә җырларга чакырмыйлар, ул төшеп кала. Теләсәк-теләмәсәк тә, бу табигать законын кабул итәргә кирәк. Шулай булганда гына киләчәктә яхшы, сыйфатлы уен коралларыбыз да, оста башкаручыларыбыз да, безне көтеп торган тамашачыбыз да булачак. Шушы артистларга карап, яшь буын үрнәк тә ала бит. Бу урында бер мисал китереп үтим әле. Казанда 1934 елдан бирле эшләп килгән гармун фабрикасы ни өчен ябыла? Үзем анда эшләгән кеше буларак шуны әйтә алам: 1990-2000 нче елларда фабрика җитештергән «Сюита» пианиноларын да, гармун, курай һәм кубызларны да халык бик аз сатып ала башлады. Нәтиҗәдә, 500 кеше эшләгән, зур гына мәйданы, биналары булган фабрика банкротлыкка чыкты. 2002 елда фабриканы бетереп, 12 кешедән генә торган бер цехны калдырганнар иде. Алар ясаган уен коралларының да күбесе сатылып бетмәде. Нәтиҗәдә, әлеге цех та үзен акламады – ябылды. Чөнки бу очракны да ясаучы – оста һәм башкаручы – кулланучы арасында килеп туган гап-гади базар законы хәл итте.

Миңа калса, үткән тарихны дөрес итеп бәяли белергә кирәк, чөнки киләчәктә дә шул ук тырмага яңадан басуыбыз мөмкин. Мәсьәләнең сәяси ягын читкә куеп, татар тормышының соңгы 500 елын гына күз алдына китерик әле. Бу чорда да җырлаган ул татар, такта кисәгенә бармагы белән бәреп булса да, көй дә уйнаган. Шулай булмаганда, гасырлар буе формалашкан озын, моңлы җырларыбыз, дәртле биюләребез, гыйбрәтле, тапкыр йолаларыбыз, моңлы уен коралларыбыз бүгенге көнгә кадәр килеп җитә алыр идеме?!.

Күренекле музыка белгече Земфира Сәйдәшева үзенең бер чыгышында: *«Озын көй-моң Казан татарлары иҗатында элек-электән үк халык тормышын чагылдыручы фактор булып торган һәм бу чорда иң югары күтәрелештә булган. Озын көйнең ритмы – 8-6, 8-7, мелизмнары бик үзенчәлекле, катлаулы. Югары башкару осталыгы сорый. Шуңа да аларны һәр җырчы башкара да алмый. Бәхеткә каршы, шушы моң, ритм бүген дә сакланып калган»,* – дигән иде.

Әлеге җырлар, көй-моңнарыбыз шушы чорда никадәр кеше күңеле, язмыш, фаҗига, сөенеч аша үткән бит! Шуңа да әлеге җырларны аеруча хөрмәт итәргә кирәктер, минемчә. Бигрәк тә репертуар сайлаганда, яшь башкаручыларга берничә озын көйне үзеңә мәҗбүри итеп алырга, ә тамашачыга, йөзен сытмыйча гына, җырның мәгънәсен аңларга тырышып тыңларга кирәктер. Кемнең әби-бабасы шушы җырларны җырлап, елап, ирен яки улын сугышка озатмаган, өйләнмәгән, кияүгә чыкмаган, дип, беребез дә әйтә алмыйбыз. Бәлки, соңгы сулышын алганда да, шушы җыр-моң аның юлдашы булгандыр. Болар татарның каһарман җырлары, хәтере, горурлыгы булырга тиеш!..

Тарих чылбыры буйлап барсаң, һәр музыка уен коралы да шушы ук юлны үткәнлеген күрәсең. Бернинди тыюларга, авырлыкларга да карамастан, татар үзенең рухи теләген өстен куйган. Иң авыр елларда да суфи музыкантларыбыз, музыка коралларын шәрык илләреннән алып кайтып булса да, уйнаганнар, халыкка тыңлатканнар. Мисал итеп, Акмулла, Утыз Имәни, Җәгъфәр ишан әс-Сәфәри иҗатларын гына искә төшерү дә җитә.

Хәтта фашист концлагеры тоткыннарының, Җәлилчеләрнең дә консерва банкасыннан думбра ясап уйнаганнары билгеле.

Күргәнебезчә, халык, ничек булдыра алса, шулай уйнаган уен коралында. Аллага шөкер, бүген дә уйныйбыз. Катнашып, көчеңне сынап карау өчен, Республика, Россия, Халыкара конкурсларның ниндиләре генә үткәрелми. Ни кызганыч, традицион татар музыка уен коралларында уйнап, дәрәҗәле халыкара конкурсларда катнашып җиңү яулаган осталарыбыз бөтенләй юк.

Безнең яшь башкаручыларыбызның бик тиз генә барлык уен коралларында да уйнарга өйрәнеп, артык көч куймыйча гына бөек артист буласылары килә. Алай була алмый ул. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам: бик талантлы егетләребез, махсус уку йортларын тәмамлыйлар да яисә аерым бер укытучы ярдәме белән әзерләгән берничә уңышлы гына көйне башкаралар да, үзләрен инде өлгереп җиттек дип уйлыйлар. Бер-ике ел сәхнәдә уңышлы гына күренгәннән соң, алар гап-гади сәхнә баянчыларына, мәҗлес шамакайларына әйләнеп калалар. Үпкәләмәсеннәр, аларга мондый бәя бирүе миңа бик авыр, чөнки алар бик талантлы егетләр. Минем белән килешергә теләмәсәгез, як-ягыгызга караныгыз әле… Татар тарихында милли уен коралларында уйнаучыларның Халыкара конкурсларда катнашып, 1934 елда призлы урын алган Фәйзулла Туишевтан кала, милли уен коралларында уйнаучы бер генә башкаручыбыз да юк. Хөрмәтле яшь буын, моңа һәрвакыт омтылырга кирәк. Үзегездә шушы киртәне җиңәрлек көч табып, әлеге ялгышларны төзәтергә иде.

Һәр милләтнең милли музыка дөньясы ике төрле юнәлештә формалашкан. Кайбер халыклар үзләренең милли җыр сәнгатен өстенрәк күрәләр, уен коралы җырга кушылып уйнау өчен генә кулланыла. Ә икенчеләрендә уен коралы беренчел, җыр исә уен коралының тавышын тагын да тулыландыру өчен генә файдаланыла. Мәсәлән, якут-саха, тыва, гуцул, болгар һәм венгрларда, Америка индеецлары һәм әле тагын күп кенә халыкларда уен коралларына милләтнең ихтыяҗы җырга ка-

раганда көчлерәк. Ни кызганыч, татар халкы беренче төркемгә керә. Безнең татар җырлап яши. Яхшы җырмы ул, затсыз җырмы, сайлап тормый – барысын да тыңлый, зал тутырып концертларга йөри.

Ә менә музыка коралларыбыз белән хәл бүтәнчәрәк. Кайберәүләр: «Безнең дә кураебыз, кубызыбыз, гармуныбыз бар бит!» – дип әйтерләр. Ләкин ни хәлдә алар? Әлеге һәм тагын байтак кына уен коралларыбыз эшләнелеше, уйнау мөмкинлекләре буенча бүгенге көн таләпләренә һич кенә дә туры килми. Берничә фидакярдән башка борчылып йөргән бер генә белгеч тә, җитәкче дә юк. Милли уен коралларын ясау, профессиональ башкаручылар әзерләү, укыту эшенең хәтта җайга салынып исәбе дә юк. Безнең татарның менталитеты гасырлар буе шулай формалашкан инде дип ризалашыргамы, әллә булдырыргамы?!

Тагын бер мәсьәләгә игътибар итик әле. Җырчының тавышы никадәр генә матур, үзенчәлекле булса да, аның үлеменнән соң, әлеге тавыш, моң югала, акрынлап онытыла. Аллаһы Тәгалә биргән шушы байлыкны, әйтик, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова һәм тагын әле күп кенә артистларыбызның алтын тавышларын бүтән беркем дә кабатлый алмый. Бик теләсәләр дә. Ә менә уен коралында яңгыраган көй-моң, меңнәрчә ел үткәч тә, үзгәрми. Димәк, көй-моңнарыбыз киләчәк буынга үзгәрешсез барып җитсен, саклансын, дисәк, уен коралларыбызның сыйфатына, башкару осталыгына, балаларны милли уен коралларында укытуга аеруча җитди карарга кирәк. Бу бик мөһим.

Тыңлаучы-тамашачы кемдер башкарган көй, җыр дөньясына килеп керә һәм музыка беткәнче, шул дөньяда яши, ләззәтләнә, илһам ала икән – бу бик яхшы. Чөнки тамашачыга тормышта музыка шуның өчен кирәк тә. Ә инде нинди дә булса музыка коралында уйнаган мәлдә уйнаучының, башкаручының эчке халәте бөтенләй башка. Син ул халәтне үзең теләгәнчә булдыра, төзи, хыяллана аласың. Теләсәң, туган якта йөр, теләсәң, син – сөйгән яр, теләсәң, син – каһарман. Шуңа да сәнгатькә тартылган кеше гомер-гомергә уен коралының иң яхшысын үзендә булдырырга тырыша, үзе сайлаган уен коралы белән горурлана, мактана. Иң матур көйләрне генә сайлап уйный, җырлый, күңелен чистарта, иманын ныгыта. Сәнгатьне чынлап яраткан кеше начар кеше була алмый. Үзенең эчкерсез-саф күңеленнән чыккан көйләре белән ул, үзе дә сизмәстән, башкаларга да тәэсир итә. Иң мөһиме – үзеннән соң киләсе яшь буынны тәрбияләүдә катнаша. Шуңа да һәр милләткә бик күп санда сыйфатлы музыка уен кораллары һәм аңарда бик күп уйнаучылар кирәк тә.

Бөтен кеше дә махсус музыка мәктәпләрендә генә укып музыкант булмаган. Кешегә бу теләк-вазыйфа күктән бирелә. Борын-борыннан ук безнең әбибабаларыбыз аны күңелләре белән тойганнар һәм үз теләкләре белән бик күп каршылыкларны җиңеп, уен кораллары ясарга, аларда оста итеп уйнарга, җырларга омтылганнар. Булган йорт-җирләрен, бердәнбер атын, сыерын сатып, уен коралы булдырган очраклар күпме тарихта?!. Югыйсә аларны беркем дә мәҗбүр итмәгән. Мәңгелек дан аларга! Аллага шөкер, бу хәл бүген дә дәвам итә. Музыка уен коралларында уйнаучы яшьләребез бар. Күп булмаса да, уен коралларын ясаучы осталарыбыз, кызыксынучы белгечләребез дә бар. Мин дә, үз чиратымда, татар халкының музыка уен коралларына битараф булмаган яшьләргә азрак булыша алсам, бик бәхетле булыр идем дигән теләктә калам.

Хөрмәтле үсеп килүче яшь буын! Сезнең арадан да халкыбызның буыннан-буынга килгән шушы мирасын дәвам итүче галимнәр, ясаучы осталар, күп санда башкаручылар чыкса, без, өлкән буын вәкилләре, бик шат булыр идек. ■

КОТЛЫЙБЫЗ!

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ 2020 ЕЛНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНДА ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУЧЫЛАР АРАСЫНДА «ЯЗЫЛ ҺӘМ БҮЛӘК ОТ» АКЦИЯСЕ ИГЪЛАН ИТКӘН ИДЕ. ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕҢ ИСЕМЛЕГЕН БҮЛӘК УЙНАТУ (АНЫҢ БАРЫШЫН @BEZNENMIRAS ИНСТАГРАМ АККАУНТЫНДА КАРЫЙ АЛАСЫЗ) ТӘРТИБЕНДӘ БИРӘБЕЗ:

1. Флера Ханипова (Азнакай, Яңа Юл) – чүәк;
2. Лилия Закирова (Арча, Мәтәскә) – мөселман яулыгы;
3. Флера Шәйхетдинова (Яшел Үзән, Күгеш) – намазлык;
4. Фәрит Салихов (Арча) – кәләпүш;
5. Әмир Хасьянов (Самара өлкәсе) – шәл;
6. Алия Садриева (Әтнә, Куәм) – татар бүреге;
7. Гөлсинә Ганиева (Казан) – электрон каләмле Коръән;
8. Гөлнара Корбанова (Әтнә, Иске Җогып) – «Татар дини календаре» һәм «Мәгъсум Хуҗин» (төзүчесе – Л.Лерон) китабы;
9. Шамил Мисбахов (Яшел Үзән, Күгеш) – «Мөселманнар календаре» һәм «Мәгъсум Хуҗин» китабы.

Җиңүчеләребез Гөлнара Корбанова (сулда) һәм Алия Садриева

Бүләкләнүчеләрне ихластан котлыйбыз һәм акциядә катнашкан һәр кешегә зур рәхмәтебезне белдерәбез! Киләсе акция һәм бәйгеләребездә катнашыгыз. Бергә булыйк, бердәм булыйк!

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

Гали Ильясов яшәгән йортта мемориаль такта ачканнан соң. 2017 ел

2017-2020 нче еллар

■ **2017 елның 21 августында** Татар дәүләт филармониясе оешуга 80 ел тулды.

■ **2017 елның 15 июнендә** танылган татар җырчысы Әлфия Авзалова бакыйлыкка күчте.

■ **2017 елның 19 октябрендә** Казанда Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Гали Ильясов яшәгән йортка мемориаль такта куелды.

■ **2017 елның 15 ноябрендә** Казанда Татарстанның атказанган артисты Таһир Якупов яшәгән йортта мемориаль такта ачылды.

■ **2017 елдан** Филармония гамәлгә куйган «Джаз-Кроссовер-Фест-Казан» фестивале ел саен уздырыла башлады.

■ **2018 елның май аенда** Татар дәүләт филармониясенең солисты Резидә Галимовага «Россиянең атказанган артисты» исеме бирелде.

■ **2018 елның июнь аенда** Филармония бакчасында «Чәчәк атучы Татарстан» музыка фестивале кысаларында алты хәйрия концерты узды.

■ Татар дәүләт филармониясе **FIFA-2018 чемпионатының мәдәни программасында** 14 концерт программасы тәкъдим итте.

■ **2018 елның җәендә** Татар дәүләт филармониясенә Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинның «Рәхмәт хаты» тапшырылды.

■ **2019 елның 16 гыйнварында** татар халкының легендар җырчысы Илһам Шакиров бакыйлыкка күчте.

■ **2019 елның 5 апрелендә** Филармония Татарстан Милли музеена 198 оригиналь экспонат тапшырды.

■ **2019 елның июнь аенда** Татар дәүләт филармониясе солисты Георгий Ибушевка «Россиянең атказанган артисты» исеме бирелде.

■ **2019 елның 14 июнендә** Казанда Әлфия Авзалова истәлегенә мемориаль такта ачылды.

■ **2019 елның 14 июлендә** Казанда җырчы, композитор Илгиз Мәҗитов истәлегенә мемориаль такта куелды.

■ **2019 елда** Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булды.

Легендар җырчы Әлфия Авзалова истәлегенә мемориаль такта ачу. 2019 ел

■ **2019 елда** Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле оешуга 20 ел тулды.

■ **2020 елда** Филармония бакчасындагы «исемле» агачлар саны 18гә җитте. Монда эшләгән мәшһүрләр истәлегенә һәм танылган артистлар тарафыннан агачлар утырту традициясе 2015 елда башланган иде.

■ **2020 елның гыйнварында** Татар дәүләт филармониясендә беренче тапкыр «Бард Арт» автор җыры фестивале узды.

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Рөстәм Яхин исемендәге классик музыка фестиваленең Гала-концертыннан соң. 2018 ел

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Мөхәммәт Мәһдиев музее

Ләбиб Лерон

Мөхәммәт Мәһдиевнең музей-йорты. Арча районының Гөберчәк авылы

Татарстанда һәм читтә ничә татар әдибенең музее бар икән? Мин, әлбәттә, хөкүмәт карамагындагы аерым музейларны күз уңында тотам: Габдулла Тукай музее (Казан, Кушлавыч һәм Кырлайда), Муса Җәлил музее (Казанда һәм Оренбург өлкәсендәге Мостафа авылында)... Янә килеп, Казанда – Шәриф Камал музей-фатиры... Мамадышта – Шәйхи Маннур, Кама Тамагында – Туфан Миңнуллин һәм Арчада – Гомәр Бәширов (Яңа Сала авылында) белән Мөхәммәт Мәһдиев (Гөберчәктә) музейлары...

Башкортстандагы Фатих Кәрим музеен (Ает авылында), шулай ук Казандагы Каюм Насыйри һәм Кичүчаттагы (Әлмәт) Ризаэддин Фәхреддин музейларын да исәпкә алсак, җәмгысе 10 күренекле шәхесебезнең аерым музее бар. Дөрес, кайбер район мәктәпләрендә язучылар музеен (әйтик, Норлат районының Кычытканлы авылында Тәлгат Галиуллинга шундый музей быел февраль аенда ачылды) тәшкил иткән кабинет-бүлмәләр бар барын. Ф.Хөсни (Теләче), Н.Дәүли (Әлки), К.Булатова (Әлмәт), Х.Туфан (Аксубай), Ф.Шәфигуллин (Яшел Үзән) музей-кабинетлары... Кем әйтмешли, шуның белән шул... Ә кайда безнең мәшһүрләребез Фатих Әмирханга, Аяз Гыйләҗевкә, Сибгат Хәкимгә, Хәсән Туфанга, Кәрим Тинчуринга, Гамил Афзалга, Гариф Ахуновка, Миркасыйм Госмановка нисбәтле чып-чын музейлар?!. Шулай ук Башкортстан Республикасында һәм Россиянең башка төбәкләрендә туган күренекле шәхесләребезнең (мәсәлән, Г.Ибраһимов, Н.Исәнбәт, Г.Кутуй, Һ.Такташ, Ә.Еники, Ә.Баян, Х.Сарьян, С.Сөләйманова, И.Юзеев, Р.Мингалим, Р.Миңнуллин, Ф.Зөлкарнәй һ.б.) башкалабызда һичьюгы бер күмәк музее булса, иллә дә шәп булыр иде, кана. Бөтен татар әдәби мохитен колачлаган «Әдәбият музее» ачу турында ничәмә еллар авыз суын корытабыз, тик бернинди дә алга китеш күренми...



Мөхәммәт Мәһдиев музее күренешләре

Музей җитәкчесе Халидә Габидуллина һәм Арча муниципаль районы башлыгы Илшат Нуриев

Мөхәммәт Мәһдиевнең кызы, тәрҗемәче һәм галимә Гәүһәр Мәһдиева

Язучы һәм журналист Вакыйф Нуриев

Быел 6 июльдә татар әдәбияты классигы Мөхәммәт Мәһдиев музее (җитәкчесе – Халидә Габидуллина) ачылганга 20 ел булды. Ошбу музейда ничәмә мәртәбә булсам да, быел да ашкынып бардым. Мөхәммәт Мәһдиевкә мөнәсәбәтле экспонатларны кабат карап йөргән чакта, башыма шундый уй килеп алды: «Фани дөньяда күпме нужа чигеп, әр-ор күреп, кагылып-сугылып яшәсә дә, ахыр чиктә Мөхәммәт Мәһдиев барыбер бәхетле шәхес булган икән бит!»

Әйе, Мөхәммәт абый, чынлап та, бәхетле әдип. Аның туган авылы Гөберчәктәге музее – моңа, минемчә, бер дәлил.

М.Мәһдиев музее мөдире Халидә Габидуллина сөйли:

– Музей ишекләрен ачып кергән һәркемне Мөхәммәт ага үзе каршы ала сыман. Өч залга урнаштырылган экспонатларга күз салсагыз, үзегезне Мөхәммәт Мәһдиев яшәгән вакытларда итеп хис итәрсез. Менә бу фотолар һәм картиналар, әйтерсең лә, Мөхәммәт абый әсәрләреннән алынган күчермәләр: кечкенә Мөхәммәт үскәндәге йорт эче һәм ишегалды күренеше, әти-әнисенең шәхси әйберләре, әдипнең студент чагы, армиядә булган вакытын күзаллау өчен куелган экспонатлар язучының тормы-

Халидә Габидуллина һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон

шын төрле яклап ача. Язучының эшкә йөргән дипломаты, студент чагында кулланган чемоданы, әнисенең документлары сакланган тартмачык, әтисе Сөнгатулланың шәхси тамгасы уелган мәчет таягы, төрледән-төрле кульязмалар, әдипнең шәхси кирәк-яраклары музейга килүчеләрдә зур кызыксыну уята. Музей фонды ел саен язучы белән бәйле экспонатларга баеп тора. Бу эштә Мөхәммәт абыйның кызы Гәүһәр, әдипнең якын туганнары зур булышлык күрсәтә. Биредә төрле чаралар үткәрелә. Быел, Алла теләсә, Мәһдиевкә нисбәтле республикакүләм конференция үткәрергә җыенабыз...

«Кеше, дөрес яшәсә генә, озын гомерле була. Кеше генә түгел, җәмгыять тә шулай», – дигән иде Мөхәммәт ага бервакыт. Тирән мәгънә салынган акыллы сүзләр. Мәһдиевтәй дөрес яшәгән, иманы нык кешеләрне халык онытмый – мәңге хәтерендә тота.

16 август, 2020 ел ■

Мөхәммәт Мәһдиев каберен зиярәт кылу

Гөберчәк авылы имамы Мәүлет Җиһаншин

М.Мәһдиев музеена 20 ел тулу уңаеннан Гөберчәк авылы янындагы урман аланында иҗади очрашу

Безнең мирас №9 сентябрь 2020

Көлке куа килә...

Мөхәммәт Мәһдиев (1929-1995)

Кыйпылчыклар

Чеховның «Белолобый» хикәясен авыл малае укый: «Билал абый...» Шуннан ары аның фантазиясе юк, теге сүзнең мәгънәсен аңламый.

***

Авыл егете, шәһәрдәге кызы белән кинодан чыккач, тәмәке кабыза да: «Ну, ошадымы соң?» – ди. Гел шулай гына була ала.

***

Ике кыз кич чыгар алдыннан (күршедән кергәне) әниләренә әйтә:

– И, апа җаным, сиңа рәхәт, синең кич чыгасың юк, – ди.

Мин дә булдым сугышта

(Ике мәзәк)

Фронттан кайткан берәү сөйли:

– Мин снайпер идем, мине фашистлар әллә каян белә иде. Бервакыт камышлыкка барып кердем, кычкырып җибәрдем: «Ханди хох... майть!» – дип. Тегеләр куркышып калдылар, әйтәләр: «Яруллин, ата күрмә!»

Шулвакыт хатыны сорый: «Алар татарча белә идемени соң?» Ире әйтә: «Тик кенә тор, ирләр сүзенә катышма!» – ди.

***

Икенче берәү сөйли:

– Мин, – ди, – бер эшелон немесне берүзем пленга алдым, сигез йөз кеше иде, шуларга чөгендер чүбе утаттым. Бервакыт маршал Жуков килде. Строй алдыннан узганда мине танып елмайды: «Молодец, Сибагатов!» –диде...

Хатыны сорый:

– Кием-салымы нинди иде?

– Нинди булсын, яхшы инде. Кара кәчтүм-чалбар, аягында ялтыравыклы ботинкалар... (Биектау ягы фольклоры.)

Вакыйф Нуриев

Иң шәп повесть

Вакыйф Нуриев
Йосыф Вәлиәхмәтов рәсеме. 1985 ел

Вакыйф Нуриев, кызып китеп, бер-бер артлы өч повесть язып ташлый. Хикмәти Хода, әсәрләре тиз арада дөнья күрә. «Әбиемә – әфлисун» повесте – «Сабантуй»да, «Җиденче палата» – «Казан утлары»нда, «Карга карагы» «Идел»дә басылып чыга.

– Укыдыңмы? Иң шәбе кайсы? – дип сорый Вакыйф Ләбиб Лероннан.

Ләбиб укырга өлгермәгән әле.

Бервакыт төнге уникедә үзенең иҗат уңышларыннан күңеле булып, рухланып киткән Вакыйф тагын повесть язарга утыра. Утыра, утыра... Сәгатькә күз сала: иртәнге дүрт. Ә алдында яткан кәгазь чип-чиста.

Иртәгесен редакциягә эшкә килгәч, ул әлеге чиста ак кәгазьне Ләбибкә күрсәтә:

– Төнлә дүрт сәгать утырып, бер сүз дә яза алмадым.

Ләбиб ак кәгазьгә текәлеп карап тора да әйтеп куя:

– Синең повестьларыңның иң шәбе, мөгаен, шушыдыр.

Туфан Миңнуллин
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Әдәби хикәя

Язучы Әпкәлиевне Тукай премиясенә тәкъдим иткәннәр иде, бирмәделәр.

– Җыен әтрәк-әләмнәргә бирәләр Тукай премиясен. Ул премиягә лаеклар читтә кала, уртакуллар лауреат булып йөри. Премия өләшүчеләр талымлырак булсыннар иде, – дип сүгенеп йөрде Әпкәлиев.

Икенче тапкыр тәкъдим ителгәч, премия Әпкәлиевкә дә эләкте. Аны алгач, яңа лауреат:

– Премиянең дәрәҗәсен төшермәскә кирәк, иптәшләр! Һәрбер кешегә Тукай премиясе өләшергә димәгән. Вакламыйк Тукайны! – дип сөйләнеп йөрде.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов

Тукай... бик биек булган

(Балалар язганнардан)

***

Габдулла Тукай бик биек булган. Аңа беркемнең дә буе җитмәгән.

***

Габдулла Тукай яшь чагында бик динле булган. Аннан дингә ышанмый башлаган. Хәзерге вакытта Тукай диннән аерылмый, чөнки авылларда бик күп мәчетләр төзелә.

***

Габдулла Тукайның әнисе дә, әтисе дә булмаган. Аны базардан сатып алганнар. Шуңа да ул шигырьләр генә язган. ■

*Сахифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

АВГУСТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Августта «Без – татарлар» дигән әдәби-нәфис басма рус һәм татар телләрендә дөнья күрде. Бөтенроссия халык исәбен алу уңаеннан, Халыкара Язучылар оешмасы ПЕН-клубның Татар-ПЕН үзәге тарафыннан әзерләнгән әлеге басманың идея һәм проект авторы – Разил Вәлиев, төзүчесе – Рәмис Аймәт, дизайнеры – Диләрә Нәүрүзова.

● 2 августта Баулы районының Кызылъяр авыл җирлегенә караган Яңа Баулы авылында «Балкыш» мәчете ачылды. Баулы районының – 90 һәм ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган әлеге тантаналы чарада Баулы районы башлыгы Рамил Гатиятуллин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Болгар ислам академиясе профессоры шәех әл-Асри, Баулы районы имам-мөхтәсибе Әнвәр хәзрәт Хәмитов, Яңа Баулы мәчете имамы Рамил Вәлиәхмәтов һ.б. катнашты.

● 3 августта музыка белгече, профессор, фольклорчы галим, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты, сугыш ветераны Мәхмүт Нигъмәтҗан улы Нигъмәтҗанов туксан яшендә вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде 4 август иртәсендә Осиново бистәсе зиратында җирләнде.

● 14 августта Мытищидагы Федераль хәрби мемориаль зиратында армия генералы Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев каберендә сын ачу тантанасы булды. Әлеге чарада мәрхүмнең туганнары һәм якыннары, Татарстан Премьер-министры урынбасары, Татарстанның Россиядәге Тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, армия генералы Анатолий Гребенюк, генерал-полковник Валерий Баранов, шулай ук Россия Мөфтиләр Шурасы, Мәскәү татарлары автономиясе һәм җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

● Август башында Татарстан Республикасы «Милли китап» нәшрияты тарафыннан нәшер ителә торган «Татар археографиясе» сериясендәге 25 нче китап дөнья күрде. «Бөек Ватан сугышы хатлары, солдат хатирәләре» («Хатлар, хатирәләр») исемле әлеге китап Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган. Материалларны өйрәнеп, китапны төзүче, басмага әзерләүче – археограф, текстолог, филология фәннәре кандидаты, китапханә хезмәткәре Раиф Мәрданов. Әлеге китапта, Татарстан районнарыннан тыш, Башкортстанда, Ульяновск һәм Самара өлкәләрендә туып үскән, Бөек Ватан сугышында катнашып, исән калган яки фронтта һәлак булган 22 милләттәшебезнең 100 данә хат текстлары нәшер ителгән.

● 14 августта Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, прозаик, драматург, «Безнең мирас» журналының элекке хезмәткәре Рәдиф Сәгъдинең әнисе Гөлчирә Зәйнетдин кызы вафат булды. Каләмдәшебезгә Аллаһ сабырлыклар бирсә иде дигән теләктә калабыз.

● 14 августта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бабасы Миңнеханның туган ягында – Мамадыш районының Дусай авылында әтисе Нургали Миңнеханов ярдәмендә төзелгән мәчеттә булды һәм авыл уртасында урнашкан, «Изгеләр кабере» дип атап йөртелгән ике кабергә чәчәкләр салды.

● 15 августта Чуашстан башкаласы Чабаксар шәһәрендә танылган җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның һәм Чуашстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәрит Гыйбатдиновны искә алдылар. Әлеге мәҗлесне Чабаксар шәһәре татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Хәйдәр Сафиуллин оештырды.

● 19-20 һәм 21-22 август көннәрендә Татарстанның Азнакай районында һәм Башкортстанның Туймазы районындагы Төмәнәк авылында Төбәкне өйрәнүчеләр конференциясе булып узды.

● 26 августта Актаныш районының Әнәк авылындагы «Бабайда кунакта» паркында Татарстан Республикасының беренче Президенты, ТР Дәүләт киңәшчесе, Россия Федерациясенең Хезмәт Герое Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә бронза бюст ачылды. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиленең урынбасары Игорь Паньшин һәм республиканың төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләре катнашында узган әлеге тантаналы чарада **М.Ш.Шәймиев**, ахырдан сүз алып, ачылышны тарихи вакыйга дип атады һәм рәхмәтләрен җиткерде: «Матур иттереп саклап, монда мәктәпләр, башка оешмалар белән зур эшләр оештырырга кирәк. Бу кадәр гаҗәп эшләнгән эшләрне башкарган кешеләргә зур рәхмәт!» ■

МИРАСВОРД

Гыйлем ... (татар химигы)

Изге, бөек, хөрмәтле (иск.)

Май язу өчен тар, тирән кисмәк

Үлчәү

Кимлек, җитеш-мәүчәнлек (иск.)

Борынгы грек тарихчысы

Куктәге бушлык, ачыклык (иск.)

Егор ... (керәшен шагыйре)

Марат Кәбиров романы

Турсык, күн савыт (иск.)

... Әдһәмова (татар язучысы, тәрҗемәче)

Төз атучы

Англиядә дворян титулы

Гаскәр башлыгы, командир (иск.)

Тиргәү, ачулану

Мәҗит ...

Грузиядәге елга

Юләр, дивана, ахмак (диал.)

Рөстәм Яхинның Мостафа Ногман сүзләренә язган җыры

XIX гасыр француз компози-торы

... Карнай (башкорт язучысы)

Фәйзи, Дусайлы

Тагын

71 сантиметрга тигез элекке озынлык үлчәве

Токмач (диал.)

Ышаныч, вәгъдәдә торучанлык (иск.)

Френкель, Арлазоров

«... Зәйнәбем» (татар халык җыры)

Мылтык чакмасы

Авторитет, дәрәҗә

Трояның икенче атамасы

Шагыйрь ... Давыдов



Хан мөһере

... Минкина

Кагылышлы, бәйләнешле (иск.)

Винсент ... Гог

Шагыйрә ... Рәхимова

Кадыйр ... (башкорт шагыйре, драматург)

8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Мәрьям, компас, «Ант», Заһитов, атом, им, алафа, таҗ, «Узи», ирән, викинг, әсас, угы, Ает, Мюллер, Лопе, Исаев, «Аҗаган», әзи, Икки, док, наян, ро, Ләйлә.
Өстән аска: Талалихин, Ак, «Һиҗрәт», кяр, «Максим», Ленино, Уваров, Рим, оазис, Павлик, аем, АН, Җәлил, Мостафин, «ЛуАЗ», таргыл, гидай, Геба, Маннур, нөктә.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы / сентябрь

Замандашлары истәлекләрендә Таҗи Гыйззәтнең үзенчәлекле киенүен ассызыклап узалар

450 ел элек (1570)

Күчем хан (Себер ханы) Явыз Иванга ясак түләүдән баш тарта, янәдән илбасарга яу игълан итә.

125 ел элек (1895)

15 сентябрьдә күренекле драматург Таҗи Гыйззәт (1895-1955) дөньяга килә.

115 ел элек (1905)

2 сентябрьдә Санкт-Петербург шәһәрендә татар телендә беренче газета – «Нур»ның тәүге саны (1905-1917) дөнья күрә.

100 ел элек (1920)

19 сентябрьдә «Татарстан хәбәрләре» газетасында Галә Ходаяровның «Нәшрият-әдәбият эшләребез белән мәшгуль иптәшләргә» исемле мәкаләсе басыла. Автор «Татар дәүләт нәшрияты» һәм аның төзелеше турындагы фикерләре белән уртаклаша.

95 ел элек (1925)

2 сентябрьдә Мәҗит Гафури Казанга килә.

65 ел элек (1955)

«Совет әдәбияты» журналында Әмирхан Еникинең «Саз чәчәге» повесте басылып чыга.

20 ел элек (2000)

19 сентябрьдә күренекле милләтпәрвәр галимебез Әбрар Кәримуллин вафат булды.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

Содержание. Сентябрь 2020

И останется в мире слово моё...: Гариф Ахунов.

Историческое наследие: «Махмуд Галяу – друг Тукая». Л.Тябина; «Духовная жизнь деревни Верхняя Курса». Э.Саляхова, Л.Губайдуллин; «Мечеть «Ильдус» в Верхней Курсе; «Возвращение к исламу крещенных татар Апазово». Г.Закиров; «Казанские издательства, выпускавшие татарские книги». Р.Марданов, И.Хадиев; «Надгробный камень Ибрагима Идриса». А.Гайнутдинов.

Татарский мир: Ильшат Нуриев: «В Арске каждый должен жить красиво и богато!»

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Не трогайте мою супругу и моих детей!» Ш.Максудова-Ахунова.

Литературное наследие: «Сын Фатиха». Г.Ахунов; «Тукай и поэт Сирин». А.Шарипов.

И вырвалось из мирской суеты...: «Смерть Магсума Хузина». Л.Лерон.

В глубинах памяти: «Татарские девушки в огне войны...». Т.Биктимирова; «Мы из Арского края». Г.Ахунов; «Воспоминания о Мухаммете Магдиеве». Ш.Максудова.

Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязев; «Татарская государственная филармония в истории 100-летней ТАССР». З.Гильмутдинова; «Музей Мухаммета Магдиева». Л.Лерон.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Мәшһүр язучы Гомәр Бәшировның улы – танылган фотограф Зәфәр Бәширов

- **Кем ул Солтангалиев? Индус Таһиров**
- **Кара тәкъдир. Рабит Батулла**
- **Эстониянең Нарва шәһәрендә ислам җәмгыяте. Ильяс Мифтахов**
- **Мөдәррис Әгъләм вафаты. Ләбиб Лерон**
- **Зөфәр Бәшировның фотомирасы**

ТАССР
ПРАЗДНОВАНИЕ 100-ЛЕТИЯ ТАТАРСКОЙ АССР
ТАТАРСТАН АССР ТӨЗЕЛҮНЕҢ 100 ЕЛЛЫГЫН БӘЙРӘМ ИТҮ
1920-2020

Әдип авылы — фотоларда

Ахуновларның күршеләре – Ибатуллиннар гаиләсе

Сулдан – Наилә Тукаева, Әминә Әсхәдуллина, Сәвидә Идрисова, алда — язучының улы Рәшит Ахунов. 1955 ел

Гариф Ахуновның туган авылы Кечкенә Өчиле дөнья картасында инде күптәннән юк. Әмма төрле елларда төшерелгән фоторәсемнәрдә бу авыл халкы кешеләрен күрергә мөмкин. Фотолар «Казан арты» тарих-этнография музееннан алынды.

Гайшә апа һәм Шәһидә Максудова улы Рәшит белән. 1954 ел



Кечкенә Өчиле авылы. Г.Ахунов рәсеме

АРЧА МУЗЕЕ



Арчаның кантон милициясе бинасы. 1925-1929 нчы елларда биредә булачак язучы Гомәр Бәширов эшләгән

Хәзер бу бинада «Казан арты» тарих-этнография музееның Әдәбият-сәнгать бүлеге урнашкан

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.